МИРКАСЫЙМ
ГОСМАНОВ

ТАУЛАР, ҮЗӘННӘР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

КАЙДА СИН, РОМАНТИКА?

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

ТАУЛАР, ҮЗӘННӘР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

Казан ⊙ Татарстан китап нәшрияты ⊙ 1977

С(Тат)2
Г71

Азиянең үзәге, Тува республикасы. Биек таулар, киң сахралар, зур урманнар, зәңгәр елгалар иле. Монда борынгы чал тарих белән хәзерге тормыш очраша. Тува җирен төрки халыклар тарихының музее дип әйтергә мөмкин. Шул якларга ике мәртәбә сәяхәт ясаган автор белән бергә сез дә бүгенге Тува җирләрен гизәрсез, тарих битләрен актарырсыз.

Художнигы
ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВ

Г $\frac{70803-032}{М132(03)-77}$ 123—77

© Татарстан китап нәшрияты, 1977



Сәфәр ерактан башланды

Гел югары, гел югары үрләгән самолет, болыт пәрдәсен тишеп узып, зәңгәр киңлеккә чыкты. Өч көн, өч төн яуган яңгыры белән Абакан шәһәре, ниһаять, аста, артта калды. Зәңгәр күк һәм күзләрне камаштырган кояш нурыннан күңелләр күтәрелеп китте. Әле, җиде-сигез минут элек кенә, дыңгычлап тутырган рюкзаклар авырлыгыннан бөгелә-сыгыла, трап буенча самолетка күтәрелгән чакта, без бу кояшны, зәңгәр күк диңгезен тиз генә күрербез дип уйламаган идек. Баксаң, болытлар Саян тауларының әле без калдырып киткән ягында гына туктап, биек сыртларга менә алмауларына гарьләнгәндәй, ничә көннән бирле шунда елап торган икән. Зәңгәр океанда тагы биш-алты минут йөзгәч, караңгы чырайлы болытларны әллә кайда калдырып, ямь-яшел таулар өстеннән оча башладык. Карлыгач канатына

охшаган бортпроводница кабина ишеге төбендә бер бөтерелеп алды да кечкенә микрофонга:

— Иптәшләр, самолетыбыз биш мең метр биеклектә оча. Хәзер Автономияле Социалистик Тува республикасы җиренә узабыз,— диде.

Барыбыз да түгәрәк тәрәзәләргә капландык.

Таулар, гел таулар... Бөдрә урманнар белән капланган, иге-чиге күренмәгән таулар. Тау араларында убылып төшкән чокырдай тирән тарлавыклар, кинәт калкып чыккан текә кыялар. Ямь-яшел... юк, гел яшел генә түгел, тора-бара коңгырт таулар да, соргылт сахра-үзәннәр дә күренә башлады. Тау урталарында бормаланган яшел тасмалар — күпереп торган яшел тугайлы елгалар... Кипшенеп сусаган чүл-үзәннәрне әз-мәз генә сугарып, калган төшләрен сугарырга вакыт таба алмагандай ашыгып, ургылып, кабаланып ага торган тау елгалары, атаклы зәңгәр елгалар...

Абакан белән Кызыл шәһәренең арасы самолетта нибары илле минутлык юл, ә шул кадәре кискен географик үзгәреш! Тегендә көне-төне туктамыйча өч көн буе яуган көчле яңгыр, ә монда чалт аяз көн. Тегендә ямь-яшел болыннар, ефәк палас кебек киң басулар, зур-зур авыллар, шәһәрләр, заводлар, тимер юл. Монда исә, менә егерме минут чамасы очып барабыз, рәтле-башлы бер авыл, поселок күренми әле. Анда-санда гына ике-өч йортлы фермалар адашып утыра. Әйләнә-тирәсе буп-буш... Тагы сөзәк таулар, тагы соргылт үзәннәр...

Тува җиренең хикмәтләре һаваның үзгәлеге яки халыкның сирәклеге белән генә чикләнми. Бик борыннан калган кыйммәтле тарихи истәлекләре — зур курганнары, төрле кыяфәттәге таш сыннары, сурәтле, язулы кыялары белән бергә бүгенгесе, хәзерге тормышы белән дә ул бик кызыклы, гыйбрәтле дөнья. Ике сәяхәт нәтиҗәсендә без моңа тулысынча ышандык. Бу ике сәфәр дәвамында Тува җирендә генә биш мең километрдан артык юл узылды. Күп йөргәч күп хәлләрне күрергә туры килде. Хәер, сүзне баштан — безне ерак сәфәрләргә алып чыккан сәбәпләрдән үк башлыйк.

* * *

Татар халкының борынгы бабалары Идел буйларына күптәннән, тарихчылар теле белән әйткәндә, урта гасырлар башында килеп урнашканнар. Бу «урта гасырлар» дигән төшенчәгә килсәк, аның хакында фәндә төрле караш яши: берәүләр бабаларыбыз Идел буена җиденче-сигезенче йөздә килгән дип исәпли, икенчеләр исә дүртенче-бишенче гасырны атый. Төпченә башлагач тагы бер сорау туа: бабаларыбыз элек ниндирәк телдә сөйләштеләр икән? Моңа да төрлечә җавап бирәләр, чөнки тарих белән бергә халык теле дә үзгәргән. Ләкин ничек үзгәргән,— төгәл җавап юк. Дөрес җавапны бары язма истәлекләр генә бирә алыр иде. Андый борынгы язма чыганаклар, кызганычка каршы, безгә җитәрлек дәрәҗәдә мәгълүм түгел әле. Язма истәлекләр дигәч, икенче сорау да калкып чыга: Идел буена килеп утырган бабаларыбызда язу булганмы? «Булмаган» дип кистереп әйтә алмыйбыз, чөнки татар, казакъ, кыргыз, үзбәк, уйгур, хакас, тува, чуваш кебек кардәш, «төрки телле халыклар» дип бер төркемгә кертелгән хәзерге милләтләрнең борынгы бабалары бишенче-алтынчы гасырларда ук, хәтта аннан элегрәк тә, язулы булганнар. Җитмәсә, берничә төр язу булган. Ә Идел буенда аларның ниндие таралды икән? Тагы фаразлар, тагы төрле карашлар...

Язма истәлекләр бөтенләй сакланмаган дип, кырт кистереп әйтергә дә ярамый. Кәгазь ясый башлаганчы кешеләр ташка, металлга, сөяккә уеп, чукып язганнар. Андый язуларның, фәнчә әйткәндә, эпиграфик истәлекләрнең киләчәктә дә табылуы бик ихтимал.

1970 елның ахырында Бакуда Азербайҗан фәннәр академиясенең академигы, «Совет тюркологиясе» журналының баш редакторы профессор Мамед Шыралиев белән әңгәмә вакытында шундый эпиграфик истәлекләр турында сүз чыкты. Мин үземнең моннан берничә ел элек Пермь өлкәсенә бер борынгы язулы ташны эзләп барып та, күңелсез нәтиҗәләр белән кайтуым хакында сүз кузгаттым. Академик, шуны көткәндәй:

— Карагыз әле, сезнең Көньяк Себер, Алтай, Тува җирләрендә булганыгыз бармы? — дип сорады.

— Юк...

— Алайса бик аңлаешлы: җитәрлек тәҗрибәгез булмаган. Иң элек моңарчы табылган, өйрәнелгән истәлекләрнең характерлары, төрләре белән танышырга кирәк иде.— Мамед ага беркадәре уйланып утырды һәм боерык биргәндәй кистереп әйтте: — Иң элек ерак Себергә, борынгы төрки язулар сакланган җирләргә барыгыз. Кыялар, таш баганалардагы язуларны үз күзегез белән күрегез, аларның язылыш формаларын, рәвешләрен, саклану дәрәҗәләрен өйрәнегез. Аннары үзегезнең Идел — Урал буйларына әйләнеп кайтыгыз. Бәлки, шуннан соң сорауларыгызга җавап табылыр.

Казанга кайтып, командировка нәтиҗәләре турында җитәкчеләр алдында исәп-хисап биргән чакта, бу турыда сүз чыккач, факультет деканының карары бер генә булды:

— Бик дөрес, экспедиция оештырырга кирәк. Студентлар өчен дә мондый экспедиция бик кирәк!

Шулай итеп, элек бер дә уйламаган, хыялга да китермәгән Тува җирләренә сәяхәткә чыктык. Хәтта ике мәртәбә сәяхәт ясадык. Беренче тапкыр 1971 елны, Абакан шәһәреннән Кызылга самолетта очып барып, Тувада ике атна чамасы рюкзак күтәреп йөрдек. Икенчесендә, 1972 елның июнь — июль айларында дүрт атнага якын үз машинабыз белән таулар, үзәннәр гиздек. Беренче танышу хәтердә ныграк сакланучан булса да, мин бу язмамны икенче сәяхәтне тасвирлауга багышлыйм. Ул нәтиҗәлерәк тә, гыйбрәтлерәк тә булды.

Саян таулары аша

1972 елны без бишәү — өч студент, художник Тавил һәм мин — поезд белән Абакан шәһәренә килеп төштек. Кечкенә генә яшел «УАЗ»ыбыз платформа белән алданрак киткән иде. Шәһәр музее янында елмаеп торган шоферыбыз — җитен чәчле Володяны очраткач, без алтау булдык. Шулай итеп, Саян тауларының капкасы булган Абаканда кечкенә экспедициябез бергә җыелды. Енисей елгасының тын, салмак ага торган төшендә, биек яр өстенә лагерь корып, ерак юлга әзерләнә башладык: утыргычларны рәтләп, азык-төлек салырга дип махсус

эрҗәләр ясадык. Володя машина тәгәрмәчләрен рәтләде, шөрепләрне, болтларны борды. Ниһаять, 1972 елның 19 нчы июнендә Кызыл шәһәренә карап юлга чыктык. Нәкъ шул көнне пыскак яңгыр башланды...

Башта без Абаканнан чыкканның икенче көнендә үк Кызыл шәһәренә җитәрбез дип уйлаган идек. Ләкин, кичкырын гына кузгалып китә алганга, йөз километрлап ара узгач, туктарга мәҗбүр булдык: салкын яңгырлы караңгы төндә таныш булмаган таулар арасына кереп китү мәслихәт түгел иде. Юлдан читкә чыгып, Уя дигән талгын агымлы елга буенда төн үткәрергә туктадык.

Тып-тын урын. Ләкин су никадәре салмак, әкрен агышлы, табигать нихәтле тын, моңлы булса, безнең төнебез шул кадәре тынычсыз, борчулы узды: әллә нинди әрсез озынборыннар, ябышкак черкиләр дөньясына тап булдык без. Иртән торгач, кабинада, чебенчеркидән аулак җирдә йокысын туйдырган Володя безнең кыяфәтләрдән көлеп йөрде...

Юлыбыз, ниһаять, әкренләп югарыга үрли башлады. Беркадәре вакыт бөдрә урманлы сөзәк калкулыклар өстеннән бардык, аннары шунда ук кинәт үсеп чыккан, түбәсе болытлар эченә кереп киткән тауга килеп төртелдек тә, куе урманлы текә тау бите буйлап югарыга таба үрмәләргә тотындык. Илле-алтмыш метр чамасы баргач, асфальт юл кырт сынып бөтенләй кире якка борылды: тагы шуның кадәре баргач янә артка кайттык. Бер уңга, бер сулга... Югары менгән саен Володяның чырае җитдиләнә барды.

— Мондый юлларда әллә беренче булуыңмы?

— Әйе...— диде ул, чак кына көттереп.

Нәкъ шул мәлне юлыбыз тагы кырт борылды һәм каршыга зур бензовоз килеп чыкты, ике машинаның да тормозлары берьюлы шыгырдап алды. Бензовоз шоферы кабинадан башын сузып, ияк кагып исәнләште.

— Каян киләсез? Машинагызның номеры таныш түгел.

— Казаннан.

Шофер сызгырып куйды.

— Ә үзең?

— Кызылдан. Бензин, керосин ташыйбыз.

— Карале,— диде Володя,— тау сыртына еракмы соң?

— Тагы сигез борылыш бар.

Бу юлы Володя сызгырып җибәрде.

Ниһаять, тауның нәкъ сыртына менеп җиттек. Нибары сигез-тугыз километр ара узганбыз. Агарынган Володя, кулларын салындырып, беравык хәрәкәтсез утырды.

Барыбыз да җиргә төштек. Бер мәлгә сихерләнгән шикелле тын калдык: түбәндә — тау битендә болытлар йөзә. Гел бездән өстә, гел биектә — югары күктә була торган көрпә болытлар!.. Шулай, болытлар белән ярышып, хәтта вакыт-вакыт алардан уздырып, күккә үрелгән биек тауның үткелендә тора идек без. Әнә, түбәндәге тау сыртларында кышкы карлар да эреп бетмәгән әле.

Саян тауларының бу төшләре котырган яшеллектән — агач-урман, үлән-чәчәктән гыйбарәт; ялангач таш кыялар бөтенләй күренми диярлек, гел бөдрә яшеллек, гел күпереп торган йомшак сыртлар. Тирән тарлавык төпләре яшел куаклар, яфраклар белән калын итеп, йомшак итеп түшәлгән сыман. Шул ук вакытта бик биек таулар болар — күкрәкләрендә болыт кисәкләре үрмәләп йөри, җилкәләрендә җәй уртасында да кар ята. Тау үркәчләренең күплегенә дә исең китәр. Әйтерсең лә, синең алда олуг океан ята! Әйтерсең лә, табигатьнең кодрәте белән ул океанның яшел дулкыннары төптән кубарылып, күккә таба күтәрелгән дә, өстендәге күбекләре, чәчрәп чыккан чал тамчылары белән ялтырап, үрә торган килеш катып калган!

Идел буе тигезлекләрендә туып үскән, мондый тауларны киноларда, сурәтләрдә генә күргән, ләкин аларның нәрсә икәнлекләрен әле бер дә тоймаган студент юлдашларым әлеге табигый, бер үк вакытта серле күренештән өнсез калып торалар. Хәтта кәгазь-каләм тотып Памир тауларын гизеп өлгергән Тавил да уйга баткан.

Чынын әйткәндә, минем күңелне дә бу кабатланмас матур биеклек дөньясы төбеннән бер айкап алды, бугазга төер тыгылып, күзләргә яшь килде. «Исәнме, чал башлы тауларым! Күпне күреп, күпне кичергән, гел биеккә, гел биеккә ашкынучы олы тауларым, исәнмесез!» — дидем мин эчтән генә.

Зур тауларда түбән төшүе үр менүгә караганда хәтәррәк: чак кына юлдан чыктың исә, синең туктар җирең тирән тарлавык төбе булачак.

Тау сыртыннан түбән төшкән саен үсемлек дөньясы байый бара. Тәбәнәк, кылчыклы үләннәр зур яфраклы үсемлекләр белән алмашына. Вакыт-вакыт тоташ чәчәк үскән аланнар очрый. Ихтимал, безнең шагыйрьләрнең «чәчәкләр келәме» дигән тәгъбире менә шушындыйлар турындадыр? Ләкин бер генә өстәмә кирәк: мондагы һәр аланның үз келәме, үз төсе бар. Гүяки табигать келәмнәрне кып-кызыл яисә уттай сары, яки зәп-зәңгәр төстән яшел аркауга аерым-аерым тукыган да, «бусы сиңа», «монысы сезгә» дигәндәй, аланнар саен җәйгән дә салган, җәйгән дә салган.

Туктап лагерь корырга бернинди мөмкинлек юк, өзлексез яуган яңгырдан җир сазга әверелә язган. Хәтта яңгыр суларыннан кечкенә чишмәләр барлыкка килеп, чылтырап агалар. Ә мин шушы тауларда кунарбыз, карагай төбенә чатыр корып, кичен учак янында утырырбыз дип хыялланып килә идем. Карагай төбендә... Сезнең наратлардан да уздырган зәңгәрсу-яшькелт йомшак ылыслы, гәрәбәдәй сары кайрылы биек карагайларны күргәнегез бармы? Аның хуш исле чәерен, әчкелтем ылыс исен иснәгәнегез бармы? Бу якларда менә шундый карагайлар үсә. Бөтен тауларны каплап алган иге-чиге юк урманнар гел шундый баһадир карагайлардан тора.

Яңгыр суларыннан җыелган кечкенә чишмә юл белән ярышып ага башлады. Бара-бара ул, юл уңаенда үзенә тагы бер-ике кечкенә чишмәне кушып, зурая төште, җиде-сигез чакрым узгач шактый зур инешкә әверелде. Ниһаять, бер тауны борылып чыгуга, ике үзәннән чыккан ике инеш кушылды да, кечерәк елга барлыкка килде. Юлыбыз инде биек таулар белән кысрыкланган тарлавык төбендәге елга буеннан чаба башлады. Мондый елгадан инде ат белән дә узу мөмкин түгел. Шулай бер сәгать эчендә без кизләү һәм яңгыр суларыннан чишмә, чишмәләрдән инеш, инешләрдән исә зур-зур ташларны тәгәрәтеп ага торган көчле елга тууын күрдек.

Күз алдында барлыкка килгән елганың исеме Буйба иде. Тагы берәр сәгать баргач, ул икенче елгага килеп кушылды. Ус дип атала торган зур елга барлыкка килде. Аның аркылы бетон күпер салынган иде.

Бервакыт тарлавык киңәя башлады һәм без гел агач йортлардан, хәтта урамнарына кадәр такта җәел-

гән бер авылга килеп чыктык. Аның исеме Арадан икән. Караңгы төшеп килә. Табигать кочагында йолдызлар белән серләшеп төн уздырудан бернинди өметебез калмагач, Араданда туктарга булдык.

Менә тормыш дигәнең шулай икән: искитмәле табигать кочагында торган килеш, корып җибәрергә чатырыбыз, кереп ятарга йокы капчыкларыбыз була торып, ремонт бара торган акшарлы мәктәптә куныл ятабыз. Нишләмәк кирәк...

Алтын мөгезләр

Яңгырлы иртә. Томан. Болыт мәктәп ихатасына хәтле төшкән. Җентекләбрәк карасаң, ихата киртәсеннән үк карагай урманы башлануын күрәсең. Ихатаның эче ямь-яшел тыгыз чирәм.

Бүген дежур Рафаэль иде. Ул күз ачып йомганчы корымга да буялып бетте, ботканы да өлгертте. Мондый ашыгыч чакларда башкалар да тик тормый, әлбәттә: берсе табак-савыт юа, икенчесе аш урыны әзерли.

Ус елгасы буйлап тагы утыз километрлар бардык, аннары, сулга борылып, бер кечерәк тау сыртын узып, икенче үзәнгә төштек. Монысы киңрәк тә, иркенрәк тә иде. Вакыт-вакыт кына кыялар юлның өстенә үк киләләр. Әмма бик узынганнарының я «борыннарын» җимергәннәр, яисә итәкләрен кисеп алып, юлдан бераз чигереп куйганнар.

Шулай тау итәге буйлап барабыз да барабыз. Ниһаять, бер юлга таба якынаеп, бер артка чигенгән койма буйлап бара башладык. Нык, таза бүрәнәләрдән биек итеп, авып төшмәсен өчен бүрәнә башлары кушылган саен почмаклап эшләнгән койма. Башы-ахыры юк сыман. Димәк, мал-туар тотар өчен дип эшләнгән гадәти койма түгел бу. Кинәт кабина түбәсен шакый башладылар, Володя тормозга басып, башын сузды:

— Ни булды?

— Боланнар, боланнар! — диделәр өстә утыручы юлдашларыбыз, бер-берсеннән уздырып.— Әнә, ә-әнә!

Юлдан шактый читтә купшы мөгезле, сылу гәүдәле, озын аяклы өч болан басып тора иде.

 — Әһе-һе! Тегендә алар дистәләгән!

Хәзер инде әлеге коймаларның да сере аңлашылды: без марал совхозына килеп җитәбез икән. Әйе, болан түгел, бәлки мараллар иде безнең исне китәргән купшы мөгезле җанварлар.

Мараллар... Бары Көньяк Себер һәм Үзәк Азия, ягъни Саян-Алтай, Тянь-Шань тауларында гына яши торган гаҗәеп киекләр алар. Маралларның сылулыгы турында борынгы скифлар һәм төрки халыкларның сынлы сәнгатендә, авыз иҗатында күп әсәрләр иҗат ителгән. Таш һәм бронза гасыры кешеләре аларның азау тешләрен бөти итеп муеннарына такканнар.

Марал совхозының зоотехнигы, кара кучкыл йөзле, кысык күзле егет Монгуш Чап безне якты чырай белән каршылады:

— Беләсегез килсә, ашыкмагыз, бүген монда кунгыгыз, иртәгә барысын да үз күзегез белән күрерсез. Сорауларыгызга да җавапны шунда бирермен. Менә сезгә бүлмә, менә аш пешерергә казан-учак; киемсалымыгызны да киптереп алырсыз, әнә утын! Йә, килештекме?

Килештек, әлбәттә, чөнки мондый тәкъдимнән баш тарту мәгънәсезлек булыр иде. Чыланган киемнәрне киптерү өстенә бер җылынып алу ни тора!

Без машинадан әйберләр төшергән арада, Монгуш:

— Димәк, Тувага, минем ватанга юл тотасыз? — дип сорап куйды.

— Сез аннанмыни? Кайчан килдең соң монда?

— Унөч ел инде, гел шушында эшлим...

Төштән соң көн ачылды. Кояш нурлары чәчрәп чыгуга дөнья бөтенләй икенче төс алды: яңгырдан соң чистарган яшел үзән нур белән күмелде, һава да җылына төште. Җирдән беленер-беленмәс бу күтәрелә. Әллә кайлардан эре-эре күбәләкләр, бөҗәкләр очып чыга башлады. Күңеле күтәрелеп киткән Тавилнең пумаласыннан өч-дүрт селтәнүгә үк бер гаҗәеп канатлы «кош» очып чыкты: ул машина кузовына кызыллы-сарылы буяулар белән Казан шәһәренең мәгълүм эмблемасын — канатлы, таҗлы аждаһа сурәте ясап куйды. Әйтерсең лә, машинаны күтәреп очарга тели ул...

Әйе, күк йөзе ачылу белән дөньяга бөтенләй башка ямь керде. Бары инеш кенә, әле күптән түгел узган яңгырның күбекле суларын җыеп, каядыр ашыгаашыга ярсып ага. Инешнең икенче ягыннан ук котырып үскән урман башлана. Шунда узасы, урман эчен-

дә рәхәтләнеп йөрисе килә. Тик күпереп ташыган, күбекләнеп гөрләгән инештән үтәрлек түгел. Безнең яктагы урманга да барып булмый: анда марал фермасы.

Иртәгесен эшкә бик иртә тотындылар: кояш нуры белән ярышып атка атланган җайдаклар марал көтүен куып китерделәр. Әлеге зур абзар эчендә кечерәк бер агыл-кура, аның эчендә исә тар аралык бар иде. Монгушның боерыгы белән һай-һулап кычкырып, көтүне кура эченә куып керттеләр, аннары мөгезләре өлгергән маралларны көтүдән аерып алып, ян-яктан кысрыклый-кысрыклый әлеге аралык эченә кертә башладылар.

Икенче якта карлыккан тавышлы ферма мөдире Сергеев җайдакларга төрле күрсәтмәләр бирә. Зур күзләре курку, дәһшәт белән елтыраган сылу мараллар әле бер якка, әле икенче якка өркеп тайпылалар — җайдаклардан котылмак булалар. Тик болары да бик җитезләр: атларын чыбыркылый-чыбыркылый чаптырып, качучыларның алдына ук чыгалар.

Төрле яктан шулай каулап әйди торгач аралыкка җиде-сигез марал керде. Аның капкасы төбендә Чап үзе тора: тиешле марал керүгә капканы ябып алып, тоткынны эчкәрәк өркетеп җибәрә, аннары тагын капканы ачып, үзе яраклы дип тапкан икенче киекне күрсәтә.

Көтүдәге маралларның берсе сыңар мөгезле иде. Сергеевның янынарак барып, икенче мөгезнең кая китүен сорадым.

— Сугышалар, каһәрләр,— диде ул кыска гына, һәм кычкырып та җибәрде: — Әнә, әнә күрәсең, арт аякларына бастылар, тибешәләр хәзер!

Чыннан да, үрә баскан ике зур марал, ал аяклары белән кискен-кискен кизәнеп, үзара кыйнаша башладылар. Сул яктагысына очлы тояклар хәтәр әләкте бугай, ялт борылып читкә тайпылды.

— Һи, ул тояклар! — диде Сергеев дулкынланып.— Ел саен әллә ничә мөгез харап була шулар аркасында. Кеше өчен дә бик хәтәр алар. Әнә өченче елны бер көтүчебезне үтерә язды, ат өстендәге кешене бәреп еккан бит!

Аралыкка ундүрт марал кертелгәч, Монгуш калганнарын курадан чыгарырга кушты. Һәм ирекккә чыккан киекләр, бәладән котылдык бугай дигән төсле,

леп-леп сикереп чабып киттеләр. Ләкин берәр атнадан аларны да әлеге аралык эченә куып кертәчәкләр...

Әйе, марал, дөресрәге бога, ягъни ата марал, мөгезен тиешенчә өлгергән чакта гына кисеп алалар (ана киекләр мөгезсез була), чөнки мөгезләр һәр елны кышын төләп[1] төшәләр дә, яз айларында бер ботак-япька артып тагы үсеп чыгалар. Ел саен шулай. Шуңа күрә мөгез япьләренә карап, аларның яшьләрен дә белергә мөмкин. Көрән төстәге йомшак йон белән капланып үскән мөгезләр, гадәттә, июнь-июль айларында тәмам өлгереп җитәләр. Җитлеккән чакта мөгез эчендәге кимек кан белән тулы була. Август-сентябрь айларында кан азаеп, мөгез кибә, кимек тә сөяккә әверелә башлый. Кара көздә хәтфә йоннары коелып бетеп, алар ап-ак сөяккә әйләнә.

Кеше өчен, әйткәнемчә, тәмам өлгергән, ягъни «пешеп җиткән» мөгезләр кирәк. Өлгергәннәрен исә ярты ай эчендә кисеп алу шарт, бераз соңгарсаң, искерә башлый.

Әлеге ундүрт бога камалган аралыкның бер башында станок-бүлмә бар: эченә киек керү белән аның идәне аска убыла да, әсир марал ике яктан станок арасына кысылып кала. Бер кеше бау белән киекнең муеныннан эләктереп ала, икенчесе мөгезле башны аркылы яткан бүрәнәгә беркетеп куя. Пычкы тоткан Монгуш шуны гына көтеп тора.

Мөгезләрнең киселгән ягын югары каратып куялар.

— Болардан пантокрин дигән бик шифалы дару ясыйлар,— ди Монгуш, икенче киекне көтеп торган арада безгә карап.— Төрле нерв авыруларыннан, хәтта ашказаны асты бизе авыруыннан дәвалый торган бик шифалы дару ул. Аны бары марал-бога һәм тимгелле болан мөгезләреннән генә алалар. Мараллар исә шактый сирәк очрый торган киек. Җитмәсә елданел кими, азая баралар. Кыскасы, бу даруны җитештерү бик кыйбатка төшә. Менә сезнең алда ята торган мөгезләрнең бер килосын без дәүләткә 120 сум бәя белән сатабыз.

Тагы бер марал станокка кысылган иде, Монгуш бер минутка безне онытты.

---

[1] Төләү — мөгез яңарту (гомумән: йон яңарту, ягъни ябага кою, кабык салу).

— Бер богадан уртача җиде ярым кило, ягъни 900 сумлык мөгез алына,— дип дәвам итте Монгуш.— Әлбәттә, бу дәүләт сатып ала торган бәя... Безнең совхозда хәзер 730 баш киек бар, шуларның 190 башы ел саен шифалы мөгез бирә.

Мөгезләрне кисеп алу белән дә эш бетми. Башта ике көн рәттән махсус кайнап торган казанда кырык-илле секунд пешекләп алырга кирәк икән. Моннан соң, җиләсле күләгә җирдә ике көн киптергәч, өченче тапкыр, тик очларын гына пешеклиләр. Тагы күләгәдә тоталар. Ниһаять, озак кына киптергәннән соң, 80—90 градус эсседә тотарга, аннары янә күләгәгә эләргә кирәк икән. Бары шуннан соң гына мөгезләр тәмам консервацияләнәләр. Нәтиҗәдә 62 процент авырлык югала!

Саубуллашып китәр алдыннан Монгуш агай йомгаклап куйды:

— Безнең совхоз дүртәр-бишәр киек асрый торган элекке ялгыз хуҗалыклар нигезендә 1927 елда оешкан. Шуннан бирле безнең көтүгә бернинди кыргый марал каны кушылмады диярлек. Нәселне бераз яшәртеп, яңартып алыр өчен Алтайдан кырык-илле баш бога китерергә исәп. Анда әйбәт совхозлар бар. Гомумән хәзер бөтен Советлар Союзында, хәтерем ялгышмаса, унҗиде махсус марал совхозы бар, бу бик аз, әлбәттә...

Безнең өчен бу совхозда кунуы гаять гыйбрәтле булды: хуҗалык, терлекчелек тарихының узганына бер сәяхәт ясагандай сиздек үзебезне. Элек кыйммәтле мөгезләре өчен кыргый киекләрне атып үтергәннәр, ә хәзер җәй саен, сарык йонын кыркып алгандай, мөгезләрен генә салдыралар. Ихтимал, безнең борынгы бабаларыбыз да хәзерге атларның, сыерларның, кәҗә-сарыкларның кыргыйларын шулай агылкуралар эчендә асрап кулга иярләштергәннәрдер?

Юлыбыз тагын борынгы таулар, борынгы үзәннәрне аралап китте.

Изге курган серләре

Безнең алда тагы бер сырт бар иде. Дөрес, ул әллә ни биек булып чыкмады. Ихтимал, үзебез биек таулардан төшеп җитмәгәнгә шулай тоелгандыр. Менә шушы сырттан Кызыл

шәһәренә 92 километр каларак, Тува җирләре башланды. Элек монда чик булган, кораллы сакчылар торган. Хәзер исә «Рәхим итегез!» дигән сәламләү сүзләре каршылый.

Таудан беркадәре төшкәч яшел төсләр әкренләп коңгырт, соры буяулар белән алмашына башлады. Тагы дүрт-биш чакрымнан ярым чүл-сахрага килеп чыктык. Димәк, Тувага хас, Үзәк Азиягә хас табигатькә җиттек дигән сүз.

Тува республикасының хәзерге культурасы, экономикасы өчен елга буе үзәннәренең әһәмияте гаять зур. Су буйлары искитәрлек яшел тугайлар, ә елгадан берике километр читкә китүгә, каны каткан тузанлы сахра... Борынгы культуралар менә шушы үзәннәрдә барлыкка килгән, хәзер дә республиканың авыл-шәһәрләре шундый үзәннәрдә — ялангач сөзәк таулар арасында урнашкан.

Чиктән егерме километрлап узгач, Туран шәһәренә җиттек. Райбашкарма комитетына кереп, бу төбәкләрнең тарихи истәлекләре турында сораштык. Әллә ни мәгълүмат бирә алмадылар. Шулай да, моннан утыз чакрымда Уюк үзәнендәге Аржаан дигән авыл янында археологларның казу эшләре алып барулары хакында әйттеләр. Безгә шул җиткән иде: бу төбәктә Ленинград профессоры М. П. Грязнов белән тувалы археолог М. Маннай-оолның скиф чорына караган бик кызыклы курган казып ятулары хакында Абаканда ук ишеткән идек.

Ләкин Аржаан авылына җитәрәк көтелмәгән хәл килеп чыкты: киң үзән буйлап авыл өстенә ком бураны — кызыл өермә иярткән кара болыт килә иде. Тиз генә киңәштек тә, бер кечкенә тау артына кереп ышыкландык. Болай эшләвебез бик вакытлы булды: кызыл пәрдә кебек тыгыз ком бураның да, чиләкләп яуган яңгырны да, телевизор караган кешеләрдәй, ашый-ашый күзәтеп утырдык.

Коры-сарыларны ашап өлгергәнче өермә дә, яңгыр да узып китте, һәм без тузаны басылып, һавасы чистарган Аржаанга килеп кердек.

Михаил Петрович Грязнов безне якты чырай белән каршылады.

— Килүегез әйбәт булган, сезгә бик теләп бер лекция укыйм, ләкин караңгы төшүен көтегез: диафильмнар да күрсәтермен,— диде.

Профессор Грязнов Хакасия, Тува җирләрен аркылы-торкылы гизгән тәҗрибәле археолог. Әкрен тавыш белән сабыр гына сөйли торган кеше. Ул лекциясен бик ерактан башлады.

— Археологик материалларга караганда, Тува җирендә моннан 80—90 мең еллар элек үк кешеләр яшәгән. Алар таш балталар, сөяк сөңгеләр ярдәмендә төрле киекләр, мамонтлар аулап көн күргәннәр. Алардан калган кораллар Хемчик елгасы үзәнендә бигрәк тә күп табылган.

Моннан биш мең еллар чамасы элек Тувада бронза гасыры башлана. Бу чор металлдан кораллар эшләү өстенә терлекчелек хуҗалыгы барлыкка килү белән дә характерлы. Ә менә ике ярым мең ел элек икенче дәвер — тимер гасыры башлана; монысы өчен примитив терлекчелектән күчмә тормышка күчү һәм тимердән кораллар, кирәк-яраклар хәзерләү хас. Нәкъ шушы дәвер Тува җирендә бик тирән эз калдырган: бер яулап алучылар китүгә икенчеләре килгән, бигрәк тә төрки телле хуннар озак еллар хөкем сөргән, аннары хакимлекне бераз вакытка сянби дигән халык яулап алган. Өченче-дүртенче гасырларда Европага барып чыккан, Атилла җитәкчелегендә Италиягә кадәр җиткән безгә мәгълүм гуннар әлеге хуннарның бер тармагы гына. Хәзер без казый торган курган хуннарга кадәр яшәгән скифлар чорына карый. Скиф дигән сүзне ишетүгә, гадәттә, безнең күз алдына Кара диңгезнең төньягында яшәгән борынгы халыклар килеп баса. Чынлыкта скифлар Көньяк Себер яисә Үзәк Азиядә формалашып, шуннан башка якларга таралган халык. Димәк, без казый торган истәлек скифларның борынгырак чорына карый. Табылган әйберләргә караганда, бу курган безнең эрага кадәр VII йөздә барлыкка килгән.

Моннан соң профессор үзләре казып ята торган курганны тасвирлый башлады. Курган дигәнебез борыңгыдан калган кабер өеме, ягъни түгәрәк формадагы ясалма калкулык ул. Курганнар, гадәттә, туфрактан өелгән. Әмма борынгы Тувада аларны гел таштан өйгәннәр. Аржаан авылы янындагы курган да шундый. Дөресрәге, авылның үзенә шул курганның исеме бирелгән, чөнки «аржаан» дип тувалылар минераль чыганакка әйтәләр (курган төбеннән чыннан да кечкенә чишмә чыгып торган). Курганның диаметры 12, биеклеге якынча дүрт метр булган. Эреле-

ваклы ташлардан мондый курганны өяр өчен, ничә мең кеше ничә еллар буе бөтен үзәннән таш ташыган булса кирәк.

Курган ташларын археологларга бик озак актарырга туры килә. Аның нәкъ уртасында юан-юан карагай кәүсәләреннән эшләнгән зур бура ачыла. Анда ил-кабилә башлыгы һәм аның хатыны күмелгән. Шул ук үзәк бураның ян-ягына салынган тагы сигез мәет табыла: ике карт кеше, бер хатын, ике яшь егет, калганнары урта яшьләрдәге ирләр. Аларның барысы да бай кием, алтын-көмеш зиннәтләр белән күмелгән. Димәк, гадәти генә ялчылар, яисә коллар түгел алар, бәлки ил башының яраннары яисә якын кардәшләре.

— Ләкин безнең өчен әһәмиятлесе әлеге кеше мәетләре түгел, бәлки гаҗәеп күп ат-елкы сөякләре булды,— ди профессор Грязнов.— Әйе! Әлеге үзәк бураны һәм аның тирәсендәге каберләрне янәшә-янәшә салынган зур-зур буралар әйләндереп алган. Шул бураларның барысында да утыз-кырыклап ат, дөресрәге, карт айгыр сөякләре табылды. Шунысы да әһәмияткә лаек: бер бурага өч-дүрт дистә гел җирән айгырлар күмелгән булса, икенчесендә туры, өченчесендә көрән, дүртенчесендә бүз, бишенчесендә чаптар айгырлар күмелгән, кыскасы, һәр бурага гел бер төстәге атлар салынган булган. Барысы да иярләре, йөгән-нукталары белән күмелгән. Йөгән-нукталар исә бронза кисәкләре, алтын маңгай тәңкәләре белән бизәлгән, кайберләренә марал тешләре, кабан дуңгызы азаулары тагылган. Җыеп әйткәндә, бай итеп дирбияләнгән айгырларны корбан итеп чалганнар. Атларның төсе, җиһазларының сыйфаты турында хәзер ышанып сөйләргә нигез бар: хайван тиреләре, эшкәртелгән каеш әйберләр чагыштырмача әйбәт сакланганнар. Хәтта мәет өстенә киертелгән киемнәрнең дә кайбер кисәкләре сакланган.

Профессор сөйләвеннән туктады, яулыгын алып күзлеген сөртергә кереште. Шул арада Тавил сорап куйды:

— Михаил Петрович, аржаан дип атала торган минераль чыганак хәзер дә бармы?

— Юк,— диде профессор,— ташларны тараткач, чишмә бөтенләй юкка чыкты. Чынлыкта ул бернинди аржаан булмаган, хәтта җир астыннан да чыкмаган; әлеге ташлар арасында барлыкка килгән: кайнар кояшта кызган җылы һава җил белән аскы катлам-

2 Е-665

дагы салкын ташлар арасына керүгә, пар тамчылары хасил булган, тамчылар җыелып су — кечкенә генә чишмә барлыкка килгән. Элгәреге кешеләр, менә шул суны «изге чишмә» дип ышанып, ел саен курган янында бәйрәмнәр, төрле йола туйлары оештыра торган булганнар. Үзем дә эчеп караган идем ул суны, бернинди тәме юк, гап-гади су. Химик анализ нәтиҗәсендә дә һичбер минераль матдәләр, тозлар табылмады.

— Гафу итегез,— диде Тавил,— ул чишмә суы кайсы буралар аркылы агып чыкты икән соң?

— Әлеге башлык күмелгән төп бурада җыелган да, җирән һәм туры айгырлы буралар аркылы чыккан...

— Бигрәк тә «изге су» булган икән!

Без көлеп җибәрүдән тыелып калдык, әлеге суны эчеп караган Михаил Петрович үзе кеткелдәп көлде.

— Ярар, дәвам итик,— диде ул, күзлеген киеп,— бу курганнан байтак әйбер табылды: ат дирбияләре, бакыр балталар, хәнҗәр-кылычлар, алтын-көмештән ясалган бизәнү әйберләре, кием-салым, тукыма кисәкләре. Ләкин болар, кызганычка каршы, курганга күмелгән әйберләрнең бер бәләкәй өлеше генә, чөнки моннан ике мең дә җиде йөз еллар чамасы элек үк аны талап чыккан булганнар. Табылган хәтлесе дә бу курганны төзегән кешеләрнең матди культуралары гореф-гадәтләре, социаль төзелешләре турында шактый мәгълүмат тупларга мөмкинлек бирә.

— Михаил Петрович, ни өчен атларны төсләргә бүлеп күмделәр икән?

— Минемчә, һәр кабиләдән, яисә кабиләләр берләшмәсеннән бер үк төстәге атлар корбан ителгән булса кирәк. Димәк, ат төсләренә карап, ил составы хакында да фикер йөртергә мөмкин дигән сүз. Шулай ук фирүзә ташы, йон, ефәк тукыма әйберләре борынгы Тува кешеләренең Памир, Урта Азия, Иран илләре белән тыгыз экономик мөнәсәбәттә торган булуларын күрсәтә. Кыскасы, борынгы скиф чорында Тува бик зур ил, ә бу Уюк үзәне исә шул илнең үзәге булмады микән дип уйларга урын кала. Шуңа күрә без аны шартлы рәвештә «Патшалар үзәне» дип атадык. Әлбәттә, мондый исем бер курган нигезендә генә бирелми: бары дәрәҗәле кешеләр кабере өстенә генә куела торган курганнар Уюк үзәнендә дистәгә якын. Аларның кайберләрен иртәгә үзегез дә күрерсез.



Кызыл шәһәре музеендагы язулы таш.

Лекция дәвамында профессор Грязнов төсле диафильмнар да күрсәтә барды. Алардан былтыр эшләнгән эшләрне, нәрсәләр табылуын яхшы ук күзалларга мөмкин иде. Табылдык әйберләрдән бер тукыма кисәгендәге орнамент-бизәкләр мине аерата кызыксындырды: нәкъ безнең гасыр башындагы казакъ, кыргыз халык орнаментлары шикелле иде алар. Моннан бик мөһим нәтиҗәләр чыгарырга мөмкин. Мәсәлән, беренчедән, халык көнкүрешендәге практик сәнгать бизәкләренең бик тотрыклы, гаять озын гомерле булуын беләбез; икенчедән, скиф чоры халыкларының материаль, рухи культуралары, кайбер ашыгучан тарихчылар әйткәнчә, бөтенләй юкка чыкмаган, бәлки соңгы дәвер халыкларына, шул исәптән төрки кабиләләргә дә мирас булып калган, алар тарафыннан сакланган, дәвам иттерелгән. «Теге культура юкка чыккан, монысы сүнеп калган» дигән фикерләр гадәттә бер яклы була. Курганнар скиф чоры культурасы белән борынгы хуннар яшәгән дәверләр арасындагы матди, рухи уртаклыкны азмы-күпме дәлилли торган фактларның берсе. Шулай ук таштан кеше сыны ясау гадәте дә скиф чорында таралган булган. Аннан соң бу традиция хуннарда һәм хуннарның нәселе булган борынгы төркиләрдә дәвам иткән, камилләшә барган, ә Европа сахраларында яшәгән кыпчакларда чын сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелгән. Ниһаять, мәет янына ат сөякләрен күмүдә дә скифлар белән хуннар һәм соңгы дәвер төркиләрдә уртаклык зур: Алтайдагы Пазырык, Монголиядәге Ноин-Ула курганнарында табылган төрле чор, ягъни скиф һәм хун әйберләрен чагыштырып карасаң, тарихи дәвамлылык тагы да ачыграк сизелә. Гомумән скиф чоры тарихын яхшы белү илебездәге бик күп халыкларның узганын дөрес аңлау өчен мөһим. Һәрхәлдә төрле халыкларның тарихларын бер бөтен, катлаулы процессның өлешләре итеп карарга кирәк. Чөнки зур илләр бер генә кабилә, бер генә халыктан тормаган.

Иртәгесен иртүк «патша курганы» янына килдек. Безнең исебезне китәргән нәрсә бура агачларының зурлыгы, тазалыгы булды. Һәрберсенең озынлыгы җидесигез метр, юанлыклары исә колач җитмәслек. Менә шундый бүрәнәләрдән кеше буе хәтле биек итеп буралар эшләнгән булган.

Карагай бүрәнәләрнең безнең көннәргә хәтле әйбәт саклануылары тагы да гаҗәбрәк: аларны бүген дә ка-

ралты-кура төзелешләренә кулланып булыр иде сыман. Карагай коры урында күп еллар, ә дымлы җирдә яисә су эчендә дистәләгән гасырлар саклана. Менә бу бүрәнәләр дә кимендә ике мең дә сигез йөз ел бер урында яткан. Бары иң аста ятканнары гына бераз чери башлаган.

Курганның төзелеше, эшлисе эшләр, алдагы планнар белән безне Аржаан экспедициясенең начальнигы, беренче профессиональ тувалы археолог Монгуш Маннай-оол таныштырды. Ул «Скиф чорында Тува» дигән китапның авторы.

Саубуллашкан чакта Монгуш кулларны кысып елмайды:

— Тува җиренә аяк баскан көнне үк аның борынгы тарихы белән таныштыгыз. Сәфәрегезнең калган өлешенә дә уңышлар телим! — диде.

Авыр юлның ахыры

Коры дала буйлап бара-бара бер кичерәк кенә тау сыртына мендек, һәм безнең алда көтелмәгән күренеш ачылды: биек тау борыны янында ике зәңгәр елга кушылып, фирүзәдәй дәрья барлыкка килә. Димәк, Бий-Хем белән Каа-Хем кушылган, ягъни Енисей (Олы Хем) хасил булган җиргә җиткәнбез икән! Әнә нәкъ Енисей туган җирдә яр буенда ук бер шәһәр тора. Ул 1914 елны, Тува җире Россия империясе составына кертелгәч нигезләнгән һәм башта «ак патша хөрмәтенә» Белоцарск дип аталган, Октябрь революциясеннән соң, мөстәкыйль дәүләт — Тува халык республикасы барлыкка килгәч, Кызыл дип исемләнгән. Хәер, тарихи белешмә бирергә тотынгач, сүзне беркадәреерактанрак башлау дөрес булыр.

Алда без Туваның борынгы тарихы белән азмыкүпме танышкан идек инде. Безнең эраның VI—VIII йөзләрендә Тува җире фәндә Төрек каганлыгы [1] дип йөртелгән гаять зур территорияле Төрек иле империясе составына керә. Шул вакытта Тувада төрки каби-

---

[1] Каган — император, каганлык — империя (каганның кул астында ханнар булган, шуңа күрә каганны өлкән хан дип тә аңларга мөмкин).

ләләр күбәйгән. Социаль-иҗтимагый яктан да зур үзгәрешләр булган: сыйнфый тигезсезлек көчәеп, феодаль җәмгыятьнең нигезләре салынган. Нәкъ менә шушы чорда күпләгән курганнар өелеп, алар өстенә таш сыннар куела; кыяларга, таш плитәләргә уеп язу гадәте башлана, соңрак фәндә «төркичә руник алфавит» дип аталган борынгы төрки язу барлыкка килә.

VIII гасырның уртасында, төрки телле уйгур кабиләләре көчәеп, Үзәк Азиядә кодрәтле Уйгур каганлыгы төзелә. Дәүләтнең үзәге хәзерге Монголия территориясендә була. Уйгурлар хөкем сөргән чорда Тувада социаль үсеш тагы бер баскычка күтәрелә; җирле халыкның культура үсеше дә шактый алга китә. Бу чорга караган руник язулы истәлекләр шул турыда сөйли.

Ләкин уйгур дәүләтенең гомере дә әллә ни озын булмый. IX йөз урталарында хәзерге Хакасия территориясендә көчле Кыргыз каганлыгы оешкач, Тува яңа дәүләт составына кертелә, һәм, Чыңгызхан империясе барлыкка килгәнче шул хәлдә кала.

XIII гасырда, күчмә халыкларда феодаль мөнәсәбәтләр ныгый барган чорда, монгол яулап алулары башлана. Тува җире яңа илбасарлар кул астында кала. Бу төбәкләрдәге төрки кабиләләр монгол феодалларына буйсындырыла. Иксез-чиксез монгол империясе җимерелгәч, аерым ханлыклар оеша.

1757 елны, Җонгар-Уйрат ханлыгы яшәүдән туктагач, Тува Кытай-Манчжур империясенең колониясенә әверелә. Яңа хуҗалар «яңа дин» — буддизмның бер төре булган ламаизмны көчләп тараталар. Үз феодаллары һәм яулап алучылар тарафыннан икеләтә изелүгә мәҗбүр ителгән халыкны өченче әрәмтамаклар — руханилар талый башлый.

Халык, әлбәттә, көрәшүдән туктамый. Хезмәт ияләре изүчеләргә каршы еш кына баш күтәрә. Шундый баш күтәрүләрдән, мәсәлән, 1822 елгы кытайларга каршы хәрәкәтне күрсәтергә мөмкин. 1882—85 елны «Алтмыш батыр» восстаниесе бигрәк тә киң колач җәя. Аны бастыруда колонизаторлар белән бергә җирле феодаллар да зур тырышлык күрсәтәләр. Биек тауларда, тирән тарлавыкларда яшеренеп, илбасарларга, феодалларга каршы көрәшкән «алтмыш баһадир» турында халык җырлар, риваятьләр иҗат иткән.

Бары 1911—1912 елларда гына, Кытайда барган буржуаз-демократик революция нәтиҗәсендә, Тува

халкы бәйсезлек яулап ала. Тик күпкә түгел: 1914 елны ул Россия империясе составына кертелә. Шулай итеп, тувалыларга мөстәкыйль рәвештә яшәргә һичнинди мөмкинлек булмый.

Мөстәкыйльлек, азатлык Үзәк Азиягә Октябрь революциясе нәтиҗәсендә генә килә. Яшь Совет хөкүмәте экономик, культура ягыннан гаять артта калган аз санлы тува халкына дуслык кулы суза, аңа яңа дәүләт — Тува халык республикасы оештырырга ярдәм итә. Бу тарихи вакыйга 1921 елда була.

Яңа дәүләт алдына яңа экономика, яңа культура тудыру, гасырлар буе хөкем сөргән милли изүдән мирас калган хәерчелекне, наданлыкны бетерү бурычлары килеп баса. Хәлнең никадәр авыр булуын күрсәтер өчен мондый фактларны искә алу да җитә. Мәсәлән, Тува халык революцион партиясенең 1929 елны чакырылган VIII съездына катнашучы 148 делегатның 100 е бөтенләй хәреф танымый, калганнарының бер өлеше аз-маз монголча укый, икенче өлеше исә көчкә генә иҗек аера.

Тәҗрибә рәвешендә язылган тувача беренче Әлифба 1929 елны Мәскәүдә басыла. Тувача милли язу исә бары 1930 елны гына кабул ителә. Милли тува телендәге беренче әдәби әсәр 1932 елны басылып чыга. Аны хәзерге тува әдәбиятының нигез ташларын салучылардан берсе, дәүләт һәм партия эшлеклесе Салчак Тока яза.

1944 елда Тува СССР составына керә, 1961 елга хәтле автономияле өлкә хокукы белән тора, аннары автономияле республика булып үзгәрә.

Хәзер тува балаларының 100 проценты да мәктәпкә йөри. Бу исә һәр дүртенче тувалы укый дигән сүз! Егерме өч ел мөстәкыйль дәүләт чорында халык хуҗалыгы якынча ун мәртәбә арткан булса, соңгы 25 елда ул 30 тапкырга үсә.

Олы Енисей буендагы шәһәрне күзәткән хәлдә бу ил, бу халык башыннан узган тарихны күңелдән кичердем. Озын юл узылган. Авыр булган ул юл...

— Кузгалабызмы соң? — диде Володя.

Енисей аркылы салынган күпергә җитәрәк сул якка борылдык һәм, елга буйлап, югарырак барып, лагерь өчен урын сайладык. Зәп-зәңгәр сулы елганың ары өстендә ак чатыр кордык. Егетләр чишенеп ташлап йөгерешергә, көрәшергә тотындылар.

Көн аяз, җылы, ә елга гаҗәеп серле иде. Күңелләрдә иркенлек хисе... Чыннан да, мондагы шикелле иркен җирләр дөньяда бик сирәктер инде хәзер: республиканың территориясе Бельгия, Голландия, Дания, Люксембург, Швейцарияләрнең тулаем территориясеннән зуррак. Шул ук вакытта бөтен Тувада 230 мең чамасы кеше яши, моның да 80—90 меңе шәһәрләрдә, мәсәлән, Кызылның үзендә генә 55 мең чамасы... Димәк, шәһәрләрдән тыш бер квадрат километрга бер генә кеше туры килә дигән сүз!

Шәһәрдә кайбер кешеләрне күрәсе, иртәгә үк эшкә башлар өчен музейда шартлар әзерлисе бар.

Енисей аркылы салынган озын күпердән уздык. Тимер-бетоннан эшләнгән менә дигән күпер. Кызылга барасы озын юлның шушы күпер белән тәмамлануы да тирән мәгънәгә ия кебек иде.

Азия үзәгендә очрашу

Кызыл шәһәрендә урамнарның ике ягында да яшь карагайлар үсеп утыра. Урам түгел, әйтерсең лә, яшел аллея. Бер чат башында Володя нәрсәгәдер текәлеп карый башлады.

— Ни күрдең?

— Әллә нинди бер һәйкәл...

— Әйдә, бор машинаңны шул якка.

Кеше буе кадәре бетон шакмак, аның өстендә җир шары, ә шардан исә озын «сөңге башы» үсеп чыккан. Шәһәргә караган ягында тувача «Азиянең төвү», ягъни «Азиянең үзәге» дип язылган. Русча, инглизчә дә шул ук сүзләр кабатланган. Володяның ышанасы килми:

— Димәк, без Азиянең үзәгендә торабыз?

— Күрәсең ич...

Гыйльми тикшеренү институтында директор Юрий Аранчин янына кердем. Нишләп йөрүебезне белүгә үк телефон трубкасын алды һәм кемгәдер тувачалап: «Александр Чайбарович, минем янга кереп чык әле»,— дип әйтте. Салмак кына тавыш белән борынгы язма истәлекләр хакында сөйли башлады:

— Алар бездә күп, хәзер илледән артык эрелеваклы төрки телле истәлек мәгълүм. Сан ягыннан безнең республика беренче урында тора. Сыйфат мәсь-

өлəсендə исə, əлбəттə, Монголия алда, чөнки андагы Билгə каган, Күлтəгин, Төнйокук бəкнең каберлəрендə зур-зур текстлы язулы ташлар сакланган. Бездəге язма истəлеклəрне өйрəнүгə килгəндə, моннан җидесигез ел элек Кыргызстан Фəннəр академиясеннəн профессор Батманов белəн безнең галимебез Кунаа текстларның бер өлешен бастырып чыгарган иде. Кызганычка каршы, Батманов вафат булгач, эшлəр бераз туктап калды. Əлбəттə, аерым кечкенə мəкалəлəр чыга торалар, лəкин бөтен истəлеклəрнең тулы җыентыгын чыгармыйча торып, эш беткəн дип исəплəргə ярамый. Дөресен əйткəндə, көч тə, вакыт та җитми əле. Галимнəребезнең күпчелеге яңа дəреслеклəр язу, искелəрен яңарту, рус теленнəн тəрҗемə итү кебек ашыгыч эшлəр белəн мəшгуль. Кунаа да хəзер тува теленең гыйльми синтаксисы өстендə эшли. Əнə үзе дə килə.

Чандыр гəүдəле мөлаем чырайлы кеше икəн ул.

— Александр Чайбарович Кунаа,— дип тəкъдим итте директор,— безнең беренче телче докторыбыз!

Мин Кунаа белəн исəнлəшүгə, Аранчин өстəп:

— Бездə чакта «беренче язучы», «беренче врач», «беренче артист» дигəн сүзлəрне еш ишетсəгез, гаҗəплəнмəгез: кичə бөтенлəй наданлыкта яшəгəн халык өчен бик табигый хəл бу,— диде һəм Кунаага карап əйтте,— иптəш Казаннан килгəн, Туваның хəзерге тормышы, борынгы тарихы, бигрəк тə язма истəлеклəр, таш сыннар, кыя сурəтлəре белəн кызыксына. Практика уза торган студентлары да бар. Борынгы чор белəн яхшылап таныштыруны сезгə тапшырам.

— Алайса безнең бүлмəгə чыгыйк.

Лəкин Александр Кунаа белəн бүлмəдə озак утырмадык, сөйлəшə-сөйлəшə музейга юнəлдек.

— Казанга бер барасым килə,— диде юлда Кунаа.— Казан университеты алдында бер баш иясе килə. Анда бит Николай Федорович Катанов эшлəгəн. Хəзерге язуыбыз кагыйдəлəрен билгелəүдə, əдəби тел нормаларын эшлəүдə иң элек без Катановның хезмəтлəренə таяндык.

Əйе, безнең якташыбыз, Казан университетының профессоры Николай Федорович Катанов XIX йөзнең 90 нчы елларында бу якларга берничə сəяхəт ясап, җирле халыкның телен өйрəнгəн. Аңарчы тува теленең нинди төркемгə керүе дə фəндə тəгаен билгеле булмый, аны монгол теленең бер тармагы дип тə атаганнар. Н. Ф. Катанов кайчак атта, кайчакларын сал-

да гизеп, җәяү дә йөреп, күп төбәкләрдә була, гаять бай материал туплый һәм 1903 елда Казанда «Урянхай телен өйрәнү буенча тәҗрибә» [1] дигән исемдә зур күләмле хезмәтен бастырып чыгара. Бу китап бүген дә тюркология өлкәсендә капиталь хезмәтләрдән санала. Н. Ф. Катанов бер телнең хосусиятләрен күзәтү белән генә чикләнми, утызга якын төрле теллардән мәгълүматлар китереп, тува теленең гомум төрки телләр системасындагы урынын билгели, аның тарихи үсү юлын ачыклый.

Музейга килгәч тә беренче сүз шул ук Катанов хакында булды. Гыйльми бүлектә утыручы көмеш чәчле агай, әкрен генә өстәл янынннан торып, ике куллап күреште:

— Казан университетыннан дисезме? Кыз-зык! Катанов, Теплоухов! Сәлам! Сәлам!

Бу көмеш чәчле кеше тува язучысы Монгуш Кенин-Лопсан булып чыкты. Тува телендә иҗат ителгән беренче зур романның авторы ул. Монгуш телгә алган Теплоуховка килсәк, ул чыннан да безнең якташыбыз.

1913 елны биология факультетын уңышлы тәмамлаган яшь галим С. А. Теплоуховны Казан университеты ерак Саян тауларына экспедициягә җибәрә. Биология буенча бай мәгълүмат җыю өстенә, галим бу якларның борынгы тарихы, археологиясе белән дә кызыксына һәм тора-бара, биологияне ташлап, бөтенләе белән тарихчы булып китә. Октябрь революциясеннән соң да ул Тува тарихын өйрәнү буенча эшли һәм үз гомерендә ике йөзгә якын курган казып, дистәләгән мөһим ачышлар ясый.

— Әйдәгез әле,— диде Кенин-Лопсан,— залга керик, якташларыгызның үзләре белән очрашырсыз.

Ул безне эчке бүлмәләрнең берсенә алып керде дә стенд каршына килеп басты. Анда мәшһүр тюркологлардан В. В. Радлов, Н. Ф. Катанов, С. Е. Малов, А. А. Пальмбахларның рәсемнәре белән янәшә мәрхүм Фазыл ага Исхаковның да сурәте тора иде. Ул тюркология фәнендә мәгълүм кеше. Хәзерге тува язуын фәнни нигезгә салуда, яңа формалашкан әдәби телнең гыйльми грамматикасын язуда зур эшчәнлек күрсәткән галим. Ерак Белоруссиядә туып үскән, бөтен гомерен яңа Туваның язу-әдәбиятын үстерүгә ба-

[1] Тувалыларны элек урянхай дип тә атаганнар.

гышлаган Александр Арнольдович Пальмбах белән кулга-кул тотышып эшләгән ул; «Тува теленең грамматикасы» дигән мөһим хезмәтне алар икесе бергә язганнар. Гомумән, хәзерге һәр тува телчесе, әдәбиятчысы үзләрен Катанов, Малов, Пальмбах, Исхаковның укучылары, шәкертләре дип исәплиләр.

Кенин-Лопсан белән сөйләшеп торган арада Абакан шәһәрендәге бер очрашу исемә төште. Хакас әдәбиятының аксакалларыннан күренекле шагыйрь, прозаик, галим Николай Георгиевич Доможаков әңгәмә вакытында Фазыл Исхаковны кат-кат телгә алып, аның белән бергә Абаканда гыйльми-тикшеренү институтын оештырып йөргән чакларын сагынып сөйләгән иде. Минем: «Тува теле белгече Исхаковны әйтәсезме?» — дип соравыма каршы Доможаков: «Әйе, ләкин Фазыл Гарифович иң элек хакас теле белгече!» — дип җавап биргән иде.

Хәзер югары квалификацияле җирле галимнәр дә үсеп җитлеккәннәр инде. Күптән түгел Мәскәүдә Әдһәм Тенишев редакциясендә зур күләмле «Тувача-русча сүзлек» басылып чыкты, аны төзүчеләрнең барысы да тувалы галимнәр. Хәзер инде дистәгә якын телче, әдәбиятчы филология фәннәре кандидаты дигән дәрәҗәгә ия. Бер-ике доктор да бар. Яшь культура өчен бу, һичшиксез, зур казаныш. Әмма шул культураның «бишеге» янында үз якташларыбызның да булуы миндә Казан, бигрәк тә чал университет өчен горурлык хисен арттырды.

* * *

Енисей барлыкка килгән җирдә көннәрне бик матур уздырдык. Күктә бер болыт әсәре юк, шул ук вакытта, күптән түгел яңгырлар узганга, артык эссе дә түгел. Кереп йоклый торган капчыкларыбыздан иртәнге нурлар белән бергә суырылып чыгабыз да, тонык салкын суга чумабыз... Тешләр тешкә тимичә калтырап, яр буендагы ташлар өстендә йөгерәбез, сөлге белән ышкынабыз, физзарядка ясыйбыз. Рәхәт!!

Ак чатыр янына чирәмгә җәйгән табында кайнар ботка, хуш исле чәй көтә. «Ашарга әзер!» дип дежур да елмаеп тора. Хәер, мин бераз арттырам да бугай, чынлыкта дежурлыктан туя башлаган «шеф поварла-

рыбыз» ашның берәр килешмәгән җире хакында әйтсәң, «ашамасагыз тагы...» дип кенә җавап бирә башлаганнар иде инде. Нишләмәк кирәк, ашыйсың... Бары Тавил генә принципиаль рәвештә контроль эшен дәвам итә: көл-күмергә, корымга артык пычранган дежурга карикатуралар ясый.

Сәгать уннарда музейда эш башлана. Залдагы экспонатлар белән танышкач, ишек алдындагы таш сыннар, язулы плитәләр белән шөгыльләнә башладык. Сыннарны төрле яктан үлчәп чыгабыз, рәссам аларны сурәткә төшерә.

Музейдагы эшнең катлаулысы язулы ташларның копияләрен күчереп алу иде. Шул ук вакытта бу копияләрне без бары практика узу максаты белән эшлибез, чөнки аларның һәммәсе дә фәнгә мәгълүм, матбугатка чыккан истәлекләр.

Беркөнне шулай тырыша-тырыша беленер-беленмәс хәрефләрнең күчермәләрен ясап утырган чакта, Александр Кунаа килеп чыкты.

— Я, хәлләрегез ничек, күзләрегез күнегәме бу сурәтләргә? — диде ул күңелле елмаеп.

— Авыр бара,— диде Фәрит көрсенеп, аннары үз-үзенә әйткәндәй өстәп куйды.— Бу язуларны беренче булып укыган кешеләргә рәхмәт инде!

— Анысы да хак,— диде Кунаа,— ләкин мин рәхмәтнең иң зурын бу язуларның, дөресрәге фәнгә иң беренче мәгълүм руник истәлекләрнең серен ачкан, онытылган язуга «ачкыч» тапкан кешеләргә әйтер идем!

Чыннан да, борынгы төрки язуның фән дөньясына мәгълүм булуы, мең-мең ярым ел элек гамәлдә булып, аннары бөтенләй онытылган язуның яңадан «телгә килүе» үзе бер зур тарих бит! Беренчеләрдән булып төркичә руник истәлекләр турында фәнгә Иоганн Страленберг дигән швед офицеры хәбәр итә. Ул Полтава сугышында русларга әсир төшә һәм озак вакытлар Себердә сөргендә яши; соңрак ерак илләрдә күргән-белгәннәре хакында китап язып, аны 1730 елда Стокгольмда бастырып чыгара. 1793 елда мәшһүр сәяхәтче П. С. Паллас үзенең язмаларында әлеге «серле» язуларның берничә үрнәген урнаштыра. Рус журналисты Г. И. Спасский исә 1818 елда тагы берничә истәлекнең сурәтен бастыра. Шулай итеп, гыйльми дөньяга «Себер могҗизалары» хакында киңрәк мәгълүм була. Ләкин нибары XIX йөзнең ахырын-

да гына, ягъни 1889—1891 елларда рус сәяхәтчесе Н. М. Ядринцев, фин галиме А. Гейкель Монголиягә барып кайткач кына, телчеләргә ышанычлы копияләр белән эш итү мөмкинлеге туа.

Музейда эш сәгатьләре бетеп килә иде.

— Александр Чайбарович,— дидем мин,— әйдәгез, безнең лагерьга киттек, әңгәмәне шунда дәвам итәрбез!

Кич тын. Беленер-беленмәс кенә җиләс җил исә. Кояш офыкка якынайган саен күкнең төсе үзгәрә, түбе исә тирәнәя бара. Елга әллә ничә төскә кереп җемелди: бер җире яшькелт, икенче төше зәп-зәңгәр, дулкын очлары алтын-сары.

— Борынгы аңлаешсыз язулар өстендә бер үк вакытта ике галим бергә эшли. Берсе — Вильгельм Томсен — Даниянең башкаласы Копенгагенда яши, икенчесе — тюрколог Василий Васильевич Радлов Петербург шәһәрендә,— дип дәвам итте чәй янында Александр Кунаа.— Томсен үзе ирешкән нәтиҗәләр хакында 1893 елның 15 декабрендә Дания Академиясенең гыйльми утырышында хәбәр итә. Нәкъ бер айдан соң, ягъни 1894 елның 14 гыйнварында Радлов та Россия Академиясе каршында махсус доклад ясый. Менә шуннан башлап борынгы руник язулы төркичә истәлекләр сер булудан туктый, телгә килеп сөйләшә башлый.

Онытылган язуларны уку, ягъни сүз билгесе яисә хәрефләрнең эчтәлекләрен ачыклау гаять катлаулы эш. Мондый авыр мәсьәләне чишәр өчен күп телләрнең фонетик, грамматик законнарын, төрле системадагы язуларны, алфавитларны белергә, аларны үзара чагыштыра алырга кирәк. В. Томсен белән В. В. Радлов нәкъ менә шундый тирән белемле, күпкырлы галим булалар. Боларның беренчесе гомум тел белеме өлкәсендә эшли, барлык Европа телләреннән тыш әллә ничә көнчыгыш телен белә; ә Радлов исә бөтен гомерен төрки телләрнең тарихын, хәзерге халәтен өйрәнүгә багышлый, дөньякүләм әһәмиятле нәтиҗәләргә ирешә.

Борынгы билгесез язуны яңадан укыганда иң элек аның нинди системадагы язу икәнлеген ачыкларга кирәк. Бер билге бер мәгънәне, әйтик, бер сүзне аңлата торган иероглифмы, яисә сүзнең аерым өлешләрен белдерүче «иҗек язумы», яки бер авазга бер хәреф

туры килә торган фонетик системамы? Руник язулы истәлекләрдәге билгеләрне берәм-берәм чүпләп, охшашлыгы буенча төркемләп чыккач, барлыгы 38 билге булуы ачыклана. Димәк, бу бер авазга бер хәреф туры килгән фонетик язу. Моннан соң Томсен хәрефләрнең позицияләрен тикшерә, аларның үзара янәшә килү һәм килә алмау закончалыкларын ачыклый; нәтиҗәдә сузык авазларны белдергән хәрефләрне тартыклардан аеру мөмкинлеге туа. Томсен, мәсәлән, иң элек «о-ө» һәм «у-ү» сузыкларын белдергән хәрефләрне ачыклый. Аннары кайбер билгеләрнең бары тартык хәрефләр була алуы гына аңлашыла. Менә шулай «энә белән кое казый торгач», галим текстларда еш очрый торган бер сүзне — «тәңре» сүзен дөрес укый ала. Ә бу бик мәгълүм сүз — төрки телләрдә дә, монгол телләрендә дә ул «күк» һәм «ходай» дигән мәгънәне аңлата. «Тәңре»дән соң тагын еш кабатлана торган «түрк» сүзе укыла. Аннары «күлтәгин», «билгә» дигән аңлаешсыз сүзләр таныла. Нәкъ шушы моментта кытайча язулар ярдәмгә килә, чөнки әлеге текстлар чукып язылган ташларның икенче кырыйларында кытайча язулар да була. Ә боларны укуы, аңлавы кыен түгел: соңгы ике-өч мең ел дәвамында кытай иероглифларының мәгънәләре үзгәрмәгән. Аларда да «киү тигин», «бигә» һәм «түкүе» дигән сүзләр еш кабатлана икән. Кытайча тексттан аңлашылганча, беренче ике сүз Күлтәгин һәм Билгә дигән кеше исемнәрен, ә өченчесе халыкны, ягъни төрекне белдерә.

Менә шулай итеп тугыз хәрефне ачыклаган Вильгельм Томсен калган 29 билгенең дә хәреф эчтәлекләрен таба.

Төрки телләрне яхшы белгән В. Радлов исә, тагы бер адым алга китеп, әлеге текстларны укып та чыга, истәлекнең үзенчәлекләрен аңлатып, борынгы телнең сыйфатын билгели.

— Менә шушы Томсен белән Радлов шикелле галимнәргә без бурычлы,— ди Кунаа, баягы фикеренә кайтып.— Бары аларның казанышлары нәтиҗәсендә генә без бу текстларны укып аңлау, шуның белән борынгы бабаларыбызның телен, гореф-гадәтләрен, катлаулы тарихларын белү мөмкинлегенә ирештек!

Рафаэль сүз сораган төсле бер бармагын күтәрде:

— Томсен белән Радлов укыган текстлар хәзер кайда саклана?

— Монголиядә, чөнки ул борында Төрек каганлыгы составына кергән. Текстлар исә сигезенче гасырның утызынчы елларында үлгән Билгә каган белән аның энесе Күлтәгиннең кабере өстендәге һәйкәлгә чукып язылганнар. Тел, стиль күзлегеннән караганда, истәлекләр бик югары бәягә ия. Күренекле рус галиме П. Мелиоранский фикеренчә, калын-нечкә авазларны төгәл чагылдыра алуы ягыннан бу язу соңрак кабул ителгән гарәп язуыннан да өстенрәк торган.

Төрки эпитафик истәлекләрнең тагы бер үзенчәлеге шунда, алардагы сүзләр үлгән кеше, ягъни кабердә ятучы мәрхүм исеменнән әйтелә. Мәсәлән, әле генә Кунаа телгә алган Күлтәгин ташындагы язу болай башлана: «Тәңре тәг тәңредә булмыш төрек билгә каган бу үдкә ултыртым. Сабымын төкәте әсетгел, улайу эне-йигүнем, угланым, береке угышым, будуным!..» (Мәгънәсе: «Күк кебек, күктә яралган, белекле төрек каганы бу [тәхеткә] утырдым, сүземне төгәл ишетегез: миңа ияргән энеләрем, угылым, туганнарым, илем-халкым!..»)

Болай беренче заттан сөйләү очраклы хәл түгел, әлбәттә; борынгы төрек каганнары эпитафик истәлекләрне үлгәнгә хөрмәт йөзеннән генә куймаган, бәлки «изгегә» әверелгән («күккә ашкан») мәрхүм исеменнән халыкка үзләре мөрәҗәгать иткән. Үлгән ханны мактау, аның «игелекле» эшләрен күккә чөю, каган властеның «тәңредән булуын» кат-кат туку юлы белән алар халык массаларыннан тәртип, буйсыну таләп иткәннәр. Гади халык үзенең бәкләренә буйсынсын, бәкләр исә ханга хезмәт итсен. «Төрек халкы,— дип «мөрәҗәгать итә» әлеге Күлтәгин,— син ач калсаң да, тук булсаң да (алдагы хәлне) уйламыйсың. Бер туйдың исә, иртәгә нәрсә ашарыңны кайгыртмыйсың. Син, шулай үз каганыңны тыңламавың аркасында, төрле якка таралып киттең, көчсезләндең, хәлсезләндең; төрле җиргә сибелеп, ач-ялангач каңгырап йөрдең. Тәңренең ярлыкавы буенча, үземнең котлы (бәхетле) булуым хакына мин каган булдым. Каган булгач, сине — мескен халыкны аякка бастырдым, сине — ярлы халыкны бай иттем, сине — аз халыкны күп иттем! Әллә бу сүзләремдә минем ялган бармы?! Төрек бәкләре, төрек халкы, тыңлаңыз моны!..»

Дөрес, Кытай императорларының эзлекле агрессиясенә каршы көрәшүдә, егылган Төрек каганлыгының мөстәкыйльлеген торгызуда Билгә һәм аның энесе ба-

тыр сугышчы Күлтәгиннең дәүләт интересы өчен хезмәте бик зур була. Әмма мәрхүм каганның халыкка әйткән шелтәсендә тәхеттәге тере каганның кисәтүе, политик программасы, сыйнфый таләбе яңгырый: «Төрек халкы,— дип дәвам итә тере каган үлгән кеше исеменнән,— сезне ничек җыеп бер ил төзүемне монда уеп яздым. Ялгышсагыз, ничек таралачагыгызны да монда уеп яздым. Нинди сүзем булса, барысын да мәңге ташына уеп яздым мин. Аңа карап барысын да белеп торыгыз, әй төрек бәкләре!» Каган мөрәҗәгатендә шелтәнең гомум халыкка, ә киңәшнең исә бәкләргә адресланган булуы да бик характерлы. Монда аның сыйнфый позициясе тәгәл ачыла.

Күлтәгиннең батыр сугышчы булуын, ил-дәүләткә зур хезмәт күрсәтүен ул үлгәч агасы Билгә кат-кат искә ала; аның вакытсыз үлемен үзе өчен дә, иле өчен дә зур фаҗига итеп кабул кыла; үзе дә иңрәп елый, башкаларны да сыкрарга мәҗбүр итә: «Күлтәгин юк әрсәр, күп үлтәче әртегез! Энем Күлтәгин кәргәк булты, үзем сакынтым, күрер күзем күрмәз тәг, белер белегем белмәз тәг булты, үзем сакынтым. Үд тәңре йасар, кесе угылы күп үлгәле түремес. Анча сакынтым: күздә яшь кәлсәр, әте дә күңелдә сыгыт кәлсәр, янтуру сакынтым, катыг ды сакынтым!..» (Әгәр Күлтәгин булмаса, барыгыз да кырылып бетәр идегез. Энем Күлтәгин вафат булды, мин сыкрадым, күрер күзем күрмәстәй, белер акылым белмәстәй булып сыкрадым мин! Вакытны тәңре бирә, адәм балалары үләр өчен туалар. Шул хәтле сыкрадым мин, күзләремнән яшь акты, күкрәгемнән аһ-зарлар чыкты — тагы сыкрадым, гел сыкрадым мин!..)

Мондый сәнгатьчә югарылыкта язылган юллар Күлтәгин һәм Билгә истәлекләрендә аз түгел. Мондый юлларны чын әдип, чын шагыйрь, чын сүз остасы гына бай тәҗрибәгә таянып яза алган, әлбәттә.

Әйе, төркичә руник истәлекләр тел тарихын, борынгы халыкларның, дәүләтләрнең политик тарихларын, иҗтимагый фикерләрен белү, дөрес яктырту өчен дә гаять бай мәгълүмат бирә икән.

Шактый соң иде. Кунагыбыз шәһәргә кайтып китте.

Төнге Енисей серле, шомлы иде. Әллә ничек йомылып-йомылып ага ул. Гадәти зәңгәр елга түгел, гүяки узган чорларның сере ага... Аның төсе дә үзгә: куе яшел дә түгел, кара-күк тә сыман. Кургашын кебек

авыр дулкыннар елганың төбендә чагылган йолдыз шәүләләрен күмеп-күмеп китә, әйтерсең лә аларның нурларын сүндерергә тели. Нәрсәне яшерергә тели? Бәлки, үзе белән тарихның серләрен алып китәргә, аларны ерак-ерак төпсез диңгезләргә илтергә телидер? Ә серләре аның бик күп. Бик күп вакыйгаларны баштан кичергән бу олы елга!..

Хәзер борынгы төрки язма истәлекләр Байкал күле һәм Лена елгасы буйларында, Алтайда, Көнчыгыш Казагстанда һәм Урта Азиядә күп табыла, аннары алар төньяк Кавказ белән Урал якларында, Түбән Идел буенда, Донда, ниһаять, Дунай якларында да мәгълүм. Күптән түгел Урта Идел буенда да язулы бер таш табылды. Ләкин ни генә булмасын, төркичә язуның төп ватаны шушы Үзәк Азия, шушы Саян-Алтай таулары. Бу табигый: гасырлар буена «халыклар казаны» булып кайнаган Үзәк Азиядә халыклар белән халыклар, телләр белән телләр очрашкан, нәтиҗәдә «тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашынган», яңа культуралар барлыкка килгән. Әле генә олылап сөйләгән төркичә язу да шулай төрле культуралар кушылуыннан барлыкка килгән. Төркиләр аны Урта Азиядәге иран телле согдлардан иҗади үзгәртеп, үз телләренә яраклаштырып алганнар. Ә согдларга исә ул Урта диңгез буендагы арамейлардан күчкән. Төрек каганлыгы барлыкка килгән чорда туган ул язу соңрак төрле якларга тарала, әле генә әйтелгәнчә, ерак Европага, Дунай буйларына хәтле барып чыга. Кызык хәл: бер карасаң, тел-язу төрле халыкларны үзара аерып тора, шул ук вакытта, җентекләбрәк тикшерсәң, әлеге тел-язу төрле зур культураларның нигезен бергә куша!

Таштагы язуларны укыган саен төзек тел, нык эшкәртелгән бай традицияле әдәби стиль белән генә түгел, бәлки йөзләгән еллар элек халыклар башыннан кичкән вакыйгалар, авыр фаҗигаләр белән дә очрашасың...

Хикмәтле ил бу Үзәк Азия. Монда төрле халыклар, культуралар, чорлар, тарихлар очрашкан һәм очраша тора. Гыйбрәтле очрашулар, гаҗәеп хатирәләр иле бу. Ачылмаган бик күп серләр иле дә ул!.. Ә Енисей шул серләрне үзенә иярткән кебек йомылып ага. Хәрәкәттән туктамаган, һич кире кайтмый торган тарих кебек ага да ага...

3* Е-665

Ике Миша, яки итек тотып аюга каршы

Шәһәрдән утыз-кырык километр китүгә асфальт бетеп, үрле-чокырлы, тузанлы кыр юлы башланды. Ул бер түбән төшеп ерымнар төбеннән кичә, бер күтәрелеп калкулык өстенә менә.

Авыллар сирәк очрый: кырык-илле километрга бер авыл әллә күренә, әллә юк. Үсемлек дөньясын да бай дип әйтеп булмый, үләннәр кибә, саргая башлаган. Бары тыз-быз чапкан йомраннар гына хөкем сөрә бу далада. Берсе качып бара, икенчесе өне авызында чүгәләп утырган.

Юл начар булганга әллә ни ерак китеп булмады. Балгазын дигән поселокка җиткәндә, кояш байый башлаган иде инде. Балгазынга революциягә кадәр үк күчеп килгән руслар нигез салган. Гомумән Тувада элек-электән үк руслар шактый булган. Бирегә рәсми православие чиркәвенә буйсынмаган, шулай ук патша хөкүмәте эзәрлекләвеннән качкан сектантлар күченеп килгән.

Башка рус авыллары кебек, Балгазында да хәзер күчмә тормышны ташлаган тувалыларны очратырга мөмкин. Шундый бер тувалы абзыйны туктатып, кунар өчен яраклы урын хакында сораштык. Ул күп уйлап тормыйча авыл очына күрсәтте:

— Иң яхшысы әнә теге яр өстенә туктагыз.

Ләкин авыл төбендә, терлек абзарлары янында кунасыбыз килмәде безнең. «Ярар, бер әйбәт урын очрар әле» дидек тә, китеп бардык. Шулай да әлеге абзый бик дөрес әйткән икән: башта гел лычкылдаган селкенчәк саз аркылы салынган юлдан бардык, аннары тау итәге буйлап чаба башладык. Саздан котылдык, әмма сусыз сахрага килеп чыктык.

Бераздан гөрләп үскән бик матур карагай урманына кереп киттек. Юл туп-туры бара, әйтерсең, киң яшел коридор бу. Юк, яшел түгел, бәлки тыгыз үскән кәүсәләрдән сары стена хасил булган яшел кәрнизле, фирүзә күкле хикмәт коридор! Юл аркылы йөгереп узган тиеннәр күзгә чалына; берәүләре, без узып китүне көтәргә теләгәндәй, торган урыннарында җиргә сеңеп хәрәкәтсез кала, икенчеләре тыз-быз чабып, озын койрыкларын өстерәп агач башларына менеп китә. Шактый вакыт могҗизалы «коридор» эченнән

баргач киң тау итәгенә килеп чыктык; күренеш тагы да ямьләнде. Юл читендә генә бәэлдәшеп сарык көтүләре йөри. Әнә берничә киез өй, аларның гөмбәзләреннән төтен күтәрелә.

Ниһаять, караңгы төшүгә, юл аркылы чылтырап аккан кечкенә инешкә җиттек. Су буйлап беленер-беленмәс юл белән кечкенә үзән-тарлавыкка кереп киттек. Берничә җирдә тау битендәге кыек юлдан аватүнә көчкә генә уздык. Менә көч-хәлгә тарлавык-үзән эчендәге бер кечкенә аланга җиттек. Ни булса да туктыйбыз шушында, бер төнгә ярар әле...

Машина туктап та өлгерми, чатыр калкып чыга, беребез учак кабыза, икенчебез кесә фонаре белән су эзләп китә. Менә чәй дә кайнап чыга, бер кичкә ашсыз да ярар.

Сарыклар кычкырган тавышка уянып киттем. Чатыр эчендә әле караңгы. Димәк, әле кояш чыгып җитмәгән. Куй-сарык көтүләренең таң-иртән көр тавыш белән кычкырышып, ашыгып-ярышып тау битендәге көтүлекләргә таба ашкынуларын күптән күрмәгән идем. Хәтта сагынган идем мин ул иртәнге көтүнең күңелле гөрләвен!.. Төнлә ачыккан сарыкларның үлән башларын чеметә-чеметә гел алга, гел алга йөгерүләрен, аларның артыннан бөдрә йонлы кыска танаулы бәрәннәрнең чабуларын, әниләре туктап калуга, тезләнеп имиләргә ябышуларын күргәнегез бармы? Терлекчеләр тормышындагы искитмәле матур күренешләрнең берсе бу. Төрле төштән сузып кына кычкырган сарык тавышлары белән әниләрен эзләп бәэлдәгән бәрәннәр авазы бөтен дөньяны күмгән булыр. Берсе калын, берсе нечкә, икенчесе әкрен, өченчесе моңлы. Үзенә күрә бер җыр, үзенә күрә бер табигый симфония.

Бу хәрәкәттән, бу шау-шудан иләсләнеп, үзем дә сизмичә, шактый җир көтү артыннан ияреп барам. Кулым җиткән сарыкларның сыртларыннан сыйпыйм, бер бәрәнне тотып алам:

— Исәнме, бөдрә бәрәнем, көрпә бәрәнем, исәнме, сыбызгы танау бала чакларым!..

Шул вакыт якында гына:

— Эки! — дигән тавыш яңгырады.

Сискәнеп киттем, минем артта тәбәнәк кенә атка менгән урта яшьләрдәге бер агай тора икән. «Эки» дигәне тувача «исәнме» була.



Хемчик буе, Эзир-оя кыяларындагы сурәтләр.

— Эки, эки! — дидем елмаеп.

Ул да елмаеп куйды. Өч бөртек мыек, дүрт кенә төкле бөдрә сакал, ялтырап торган кара-кучкыл түгәрәк йөз.

— Сән кымсың? — диде ул һәм шуны ук русча кабатлады,— ти кыто?

— Экспедиция без,— дидем кыска итеп һәм аңлаешлырак булсын өчен тувача өстәдем,— хорум, таш көҗә...

Ул аңладым дигәндәй баш какты, чөнки «хорум» дип тува телендә курганнарга әйтәләр, «таш көҗә», яисә «көҗә таш» борынгы һәйкәлләрне — таш сыннарны белдерә. Җайдак үзе килгән якка борылып карады. Тар сукмактан кулына озын таяк тоткан бер кеше килә иде. Билендә бүлтәйгән капчыгы бар, димәк, көтүче ул. Минем яндагысы күзәтче булырга тиеш; таудагы көтүчеләр терлекне төнлә дә бүреләрдән саклыйлар, һәм күзәтче, гадәттә, иртә белән көтүне беркадәр җир озата бара.

Җәяүле кеше башын бер селкеп исәнләште дә узып китте. Җайдак исә җиргә төшеп, чаптар алашасының тезгененнән тарта-тарта, миңа ияреп чатыр янына

килде. Беркадәре вакыт машина тирәли әйләнеп, кузовтагы әкәмәт сурәтләрдән көлеп йөрде. Аннары чатыр ишеге төбенә килеп чүгәләп утырды да, кесәсеннән янчык чыгарып, озын челеменә тәмәке тутырды.

— Аатың кем? — дип, мин исемен сорадым.

— Миша,— диде ул, бер көлтә төтен бөркетеп.

— Тувача ничек?

— Мәкайыл,— диде ул җитди генә.

Курганнар, таш сыннар турында сораша башладым, бармы соң алар бу төбәкләрдә, булса кайда?

— Бар,— диде ул һәм әллә кая таба күрсәтте,— алыс-алыс...

Димәк, ерак икән; артык сорашуның файдасы юк, шуңа күрә сүзне икенче якка борып, урман һәм киекләр хакында сораша башладым. Марал, илек (урман кәҗәсе), адыг (аю) сүзләре чыгуга Михаилның күзләре елтырый башлады.

— Бар, бар, күп! — диде ул һәм үз күкрәгенә төртте.— Мин охота!

— Хәзер ауга йөрмисеңдер бит?

— Ник йөрмим, йөрим, узган көнне генә булдым.

— Аттыңмы соң?

— Юк, күренмәде... Бүген дә барам. Кочеш итти охота? [1]

— Әлбәттә телим! Тик кайчан барабыз соң?

Михаил, ишарәләп, кояш төшлектән авышкан чакны күрсәтте.

— Ә-ә, юк,— дидем мин,— соң була, безнең китәсе бар.

— Алайса хәзер киттек,— диде ул, артык уйлап тормыйча.

— Ярый!

Михаил шунда ук алашасына сикереп менде дә, «ун минут, кәләм», дип китеп тә барды.

Мин, Михаил киткәч кенә, әйләнә-тирәгә карадым. Төнлә адашып кына килгән булсак та, менә дигән шәп урынга туктаган икәнбез! Ике яктагы тау битен урман каплаган тыгыз чирәмле яшел үзән. Ә чәчәкләр... Аларның төсләрен атап чыгар өчен дә унике төсле акварельнең мөмкинлеге җитмәс иде. Әле генә сарык көтүе узып киткән дип уйламассың — чирәмнең яшеллеге, сафлыгы бөтенләй аяк басмаган шикелле. Тау битендәге аланда әлеге көтү, бөдрә бәрәннәр...

---

[1] Ауга барырга телисеңме?

3 К-665

Чатырыбыз коелып түбән төшкән үзәннең чак кына турайган җирендә тора. Зур-зур дүрт карагай утыра; берсенә ике кешенең колачы җитмәс, ябалдашлары бергә кушылып үскән. Чак кына арырак ниндидер сәер зур нәрсә ята. Кар түгелме соң ул? Әйе, әйе, кар. Зур карагайлар күләгәсендә яшеренеп яткан кар кисәге! Янында ук шау чәчәкләр симфониясе... Менә ни өчен рәхәт салкынча икән монда!

— Җәннәт бу, валлаһи, җәннәт!

Бу Тавил икән, канәгать чырай белән күзләрен кыса төшеп, кулларын уа-уа, әйләнә-тирәсен карап тора.

— Ауга бармакчы буласыңмы? — диде ул, көлемсерәп.— Барыгыз, берәр сукыр тычкан туры килер, бәлкем.

— Миңа димәгәе бөтенләй очрамасын, киек сукмакларында бер йөреп кайтуы ни тора!

— Әнә килә дә бугай үзе.

Әйе, иңенә мылтык аскан Михаил килә иде.

Үзән буйлап киттек. Әле кояш тәмам күтәрелеп җитмәгән, шуңа күрә, көнбатыш тарафындагы тау очлары алтын сыман балкый башласалар да, үзәндә караңгы, дымсу.

Урман эченә кергәч бил тиңентен эре-эре сабаклы куе яшел, сусыл куаклар, юан көпшәле балтырганнар арасыннан бара башладык. Әледән-әле, ачыграк җиргә чыгуга, көлтә-көлтә нурдан караңгы урман эче яктырып китә. Бәләкәй аланнарда уч төбе хәтле шәмәхәкызыл чәчәкләр очрый. Аның татарча исеме ничектер, белмим, казакълар шөгылык диләр; уйгурлар исә «чогылык» дип кыз балаларга исем кушалар. Яз ахырында тау урманнарында күпереп ачыла торган, күз явын алып балкый торган йодрык хәтле чәчәкләр. Тувача исеме ничек дип, чәчәккә ишарәләп, Мишадан сораган идем, ул пышылдап кына: «чәчәк» дип җавап бирде һәм, «шаулама!» дигәндәй имән бармагы белән авызын басып, алга таба узып китте.

Мин үземнең ауда икәнлегемне искә төшердем. Әмма биек үлән арасындагы беленер-беленмәс сукмактан тавыш-тынсыз баруы гаҗәп кыен булып чыкты: табаннарың җиргә тиеп тә өлгерми, үлән астында яшеренеп яткан ботаклар шартлап сына. Миша нәкъ мәче сыман җирне капшап кына атлый.

Ярышып, котырып үскән карагай урманы куера, тыгызлана барды. Агачлар шәм кебек төп-төз, кайры-

лары гәрәбәдәй сап-сары, озын йомшак ылыслары әллә нинди әйтеп бетергесез беленер-беленмәс хуш ис бөркеп тора. Мондый табигатьтә яшәп, шушындый урманнарда гомер кичергән аучылардан да бәхетлерәк кеше юктыр дип уйладым мин. Чыннан да, кабатланмас табигый гүзәллек, сафлык, пакьлек дөньясы бит бу!

Бу тауларда, бу урманнарда киек-җәнлекләрнең исәбе-хисабы юк. Монда мараллар, аюлар, урман кәҗәләре, бүре һәм төлкеләр, шулай ук суер, олар[1] кебек киек кошлар күп. Биек ялангач тауларга менсәң, таш кыяларда сикереп йөрүче тау тәкәләрен очратасың; ялангач сыртларда архарлар чабып йөри; чүлсахраларда исә кешене күрүгә бераз тырагайлап чабып, аннары кап-кара чуклы койрыгын селкетә-селкетә сиңа карап торучы кыр кәҗәләрен — җәйрәннәрне күрәсең. Тиен, кама, кондыз, көзән, бигрәк тә кеш кебек асыл җәнлекләр бөтен Саян-Алтай тауларының горурлыгы. Гомумән, бу яклар элек-электән киеккә, төрле кыргый җәнлекләргә бай булган. Ләкин соңгы илле-алтмыш ел эчендә, ягъни халык арасына мылтык тарала башлаганнан бирле, алар сизелеп кимиләр. Әйе, мылтык... Әнә Михаилның җилкәсендә дә бер мылтык селкенеп бара.

Юлдашым кинәт туктап калды. Утыр дигәндәй кулы белән кисәк ишарәләп, үзе дә лып итеп җиргә чүкте. Нәрсә күрде ул, белмим. Үләннәр арасыннан башын сузып нәрсәгәдер җентекләп карый. Мылтыгын алга суза. Мин ирексездән елмаям: хан заманында булмаса да, патшалар чорында ук искереп өлгергән берданка иде ул. Түтәсе дә бит үзенеке түгел: балта белән аннан-моннан юнып ясалган. Михаил минем бөеремә төртеп, күрәсеңме дигәндәй әллә кая ишарәләп күрсәтә. Ләкин әллә ни күрмим — гел агач кәүсәләре, куак, биек үләннәр. Әнә-әнә дигәндәй, ул бармагы белән ике юан агач арасына төртеп күрсәтә. Әһә! Алдарак, биек үлән арасында ике колак тырпаеп тора. Димәк, илек, ягъни урман кәҗәсе бу!

— Атасыңмы?

— Юк, алысрак...— ди Миша, һәм, мине утырган җирдә калдырып, үзе алга таба үрмәләп китә. Чак кына баргач туктый, кесәсеннән шырпы чыгарып кабыза да, җилнең кай тарафтан исүен аныклый. Дөрес

---

[1] Тау күркәсе.

бара икән, туры үрмәләвен дәвам итә. Мин, башымны кузгатмыйча, аның һәр хәрәкәтен күзәтәм, кәҗә дә гел сагаеп тора: сизә хәтәрне! Кинәт нидер шарт итте — кәҗә бер сикереп читкә тыйпылды, якында авып яткан кәүсә өстенә менде һәм, үрмәләп килүче кешене күрде бугай, сикереп-сикереп чабып та китте. Артыннан үлән арасыннан күренер-күренмәс бәтие дә бергә чапты.

Качтылар. Мин җиңел суладым; бая гына тезләнеп, койрыгын селкетә-селкетә, әнисен имгән бәрән күз алдыма килде.

Михаил тураеп басты да, әйдә дигәндәй, кулы белән изәде. Чак кына җитә алмавына, атып өлгермәвенә аның кәефе кырылган иде, мыгырдап тагы алга китте.

Ул вакыт-вакыт туктап, тыңлаштырып тора, текәлеп-текәлеп карый, тагы алга атлый. Шактый вакыт шулай баргач, кинәт туктап калып, текәлә-текәлә җиргә карый башлады: мин килеп җиткәч, егылган үләннәргә төртеп күрсәтте. Күрәм: әле күптән түгел генә нәрсәдер үләннәрне таптап, үзенә юл салып узган. Әнә аяклар тигән җирдә чык тамчылары сытылып, сыланып, юеш таплар барлыкка килгән. Михаил да шул яңа «сукмак» буйлап атлый. Кинәт ул пышылдап кына:

— Мишка! Адыг! — диде.

— Аю?!

Михаил елмаеп баш какты һәм бер куак төбендәге тизәк өеменә күрсәтте. Әйе, бары аюлар гына шулай өеп калдыралар. Аяк эзләре дә аюныкы. Беркадәре кеше аягын хәтерләткән, очлы тырнаклары җиргә тирән баткан зур-зур эзләр.

— Әйдә барабыз,— диде юлдашым, сукмакка ишарәләп.

— Әйдә! — дидем мин.

Ләкин аның артыннан бара-бара, тагын мылтыгына күзем төште: бу «бүкән» түтәле мылтык белән ничек итеп аю ауламак кирәк дип шомланып куйдым.

Янә бераз баргач Михаил туздырылган кырмыска оясына төртеп күрсәтте:

— Мишка!

Аюның шулай кырмыска оясын туздырып, аларның йомыркаларын ашавы хакында элек тә белә идем, ләкин ояның әле генә, без килер алдыннан гына туздырылганын күреп, эсселе-суыклы булып киттем:

димәк, кодрәтле урман хуҗасы якында гына дигән сүз! Аучы Мишаның кыяфәтенә карап тагын шикләнеп куйдым.

— Әйдә тизрәк, хәзер куып җитәбез аны! — диде ул, дәртләнеп.

Мин сер бирмәскә тырыштым. Ни генә булмасын, ул бүген генә ауга чыккан кеше түгел бит дип, үземне юатам һәм леп-леп басып аның артыннан барам. Михаил кинәт убылып төшкәндәй җиргә сеңә. Мин дә чүгәм. Теге чак кына калкып нәрсәгәдер карый башлый. Яңадан башын яшерә. Күзләре әйтеп бетергесез куаныч, сөенеч, дәрт белән ялтырый; бармагы белән ишарәләп, пышылдап куя:

— Мишка бар!

Мин исә иң элек аның мылтыгына карыйм. Ә ул «тегендә, тегендә» дигәндәй бармагын сузып тора. Карыйм. Әһә, әнә икән!.. Йөз илле метр чамасы алда биек үлән арасыннан аюның көрән сырты күренеп тора. Нидер казый бугай. Менә башын күтәрә, як-ягына карана, тагы түбән иелә.

— Нишлисең соң?

— Атам!

Элек ул, мине сәерсендереп, итекләрен сала башлады, йон оектан гына калды. Итекләрен миңа тоттырды да, кесәсеннән шырпы чыгарып, тагын җилнең кайдан исүен ачыклады.

— Утыр, юк, җиргә үк ят! — дип боерды һәм үзе, әкрен генә шуып, биек үләннәр арасына кереп югалды.

Башымны калкытып юлдашым киткән якка карыйм. Әнә ул, үлән башларын селкетеп, шуышып бара. Бик әкрен кыймылдый. Туктый, башын күтәрә. Минем якка борылып карый һәм кулын кисәк селтәп ятарга куша. Тагын ятам. Вакыт бик әкрен үтә... Әгәр аю яраланып кына калып, дулай башласа, нишләргә соң? Бу итекләрне күтәреп чабаргамы? Маңгаема салкын тир бәреп чыкты. Шулчак шартлап, колакларны тондырып, мылтык атылды. Мин җиргә сеңдем; торыргамы, юкмы? Ни булды икән? Ни өчен бернинди тавыш юк? Тукта, агач ботаклары шартлап сына түгелме соң?

— Ә-әй! — дигән тавыш ишетелде.

Михаил кычкыра! Сикереп тордым. Әнә ул, мылтыгын түбән каратып тора, ә мишкасы кая икән?.. Кулын изәп мине чакыра. Кирза итекләрне ике кулы-

ма тотып түбән төшәм. «Хәзер киекне тунарга туры килер, мәшәкать...— дип уйлыйм мин.— Тиз генә кайтып булмас, ахрысы». Кызурак атлыйм. Менә аның «үлде» дигән сүзен ишетәчәкмен, итекләрне югары чөеп: «Ура!» — дип кычкырачакмын.

Һәм мин чыннан да урманны яңгыратып:

— Урра, урра! — дип акырдым.

Мишаның моңа бик исе китте, чөнки ул «үлде» дип түгел, «качты» дип әйткән иде.

Кәефе кырылган Михаил бер-ике сүз белән генә ни булуын аңлатты: менә тагы бераз алга шугач, аюның нәкъ башына атам дигәндә абынып киткән дә, мылтык түтәсе нәрсәгәдер эләгеп, тауларны яңгыратып шартлаган.

— Ә мишка кая китте?

— Тегендә,— дип, аучы каршы як урманга күрсәтте.

Без кайтыр юлга борылдык. Беркадәре баргач кына мин кулымдагы итекләргә гаҗәпләнеп карадым:

— Карале, дус, боларны киярсең, бәлки?

Ул шунда ук чүгәләп утырып киенде һәм, челем кабызып бер-ике суыргач, минем «ура» кычкыруымның сәбәбен сорады.

— Ник шатланмаска,— дидем мин көлеп,— күсәгең белән син дә исән, итекләрне тоткан мин дә исән, аюның да тиресе үзендә калды.

Михаил көлеп җуйды. Көтелмәгәндә уңышсызлыкка очрап кырылган кәефе челемнән соң бераз рәтләнә төште бугай, җай гына сөйләшеп бара башлады.

— Михаил,— дидем мин,— киекне күп аттыңмы соң?

— Ниндиен?

— Илекне, мәсәлән?

— Түртун булыр...

Кырыкланны аткан икән. Тува телендә дистәләр шулай берәмлек саннарына «ун» сүзе кушылып ясала: өчун — утыз, бишун — илле, алдыун — алтмыш...

— Ә аюның ничәсен?

— Алтыны,— диде ул бик гади генә.

— Шушы мылтыгың беләнме?!

— Әйе,— диде һәм, соравымнан гаҗәпләнеп, көпшәсе әйләнә торган мылтыгына карады.— Ә нигә исең китә?

Мин җавап бирмәдем, чөнки ис китү генә түгел, сокланырлык, шаккатырлык хәл иде бу.

Дәүләт чиге аша

Үзәндә терлек көтүләре, каплап куйган чынаяклардай ап-ак тирмәләр. Аратирә авыл араларында җайдаклар күренә. Алар шушы иркенлек, бу матурлыкны ташлап китәргә теләмәгәндәй әкрен генә юырталар. Бөтенләй ваемсыз, ашыкмаган бер дөнья...

Бер тау борынын әйләнеп чыгуга алдыбызда көтелмәгән күренеш ачылды: котырып үскән урман белән капланган ике зур тау бер-берсенә каршы килә дә чак кына бәрелешмичә туктап кала. Нәкъ шул җирдә олы юлга сакчы төсле бер гаҗәеп матур поселок утыра. Исеме дә аның ничектер серле, романтик яңгырый — Шуурмак. Бәлки таулар үзләре аны җил-давылдан, хәтәрдән шулай саклап торалардыр?..

Ләкин поселокта артык юанырга вакыт юк иде, чөнки бүген үк Самагалтай шәһәренә җитеп, эш вакыты беткәнче тиешле документларны рәтләп алырга кирәк. Болай ашыгуның сәбәбе бар. Кызылда чакта, егетләр музейдагы сыннар, язулы ташлар белән шөгыльләнгән арада, миңа кайбер рәсми кешеләр белән очрашып сөйләшергә туры килгән иде. Министрлар Советы председателе М. К. Мендуме белән сөйләшү аерата файдалы булды.

— Максатыгыз гел тарихи истәлекләрме, әллә гомумән Тува җире, халык тормышы белән дә кызыксынасызмы? — дип сорады ул.

— Безнең өчен һәр икесе дә мөһим.

— Аңлашыла. Кая таба юл тотарга ниятлисез?

— Кызылдан Чадан шәһәренә китәргә, аннары Хемчик үзәненә.

— Юк, алай кирәкмәс,— диде Михаил Клаевич,— сез элек республиканың нәкъ көньягына таба юл тотыгыз, Самагалтай шәһәренә барыгыз, аннары, Монголия чиге буйлап, көнбатыштагы Овюр районы үзәге Хандагайтыга җитәрсез, юл уңаенда Монголиядә дә булып, аннары үзегез теләгән Хемчик үзәненә килерсез.

— Гафу итегез, Михаил Клаевич, чик аркылы чыгар өчен бернинди махсус документыбыз юк безнең!

— Паспортларыгыз да юкмыни?

— Анысы гына бар...

— Җиткән, Самагалтайда сезне тиешле пропусклар белән тәэмин итәрләр. Шуны да истә тотыгыз: юлыгызның күп өлеше чүл-сахра буйлап барыр, димәк, үзегез белән су, бензин, мул итеп азык-төлек алырга онытмагыз.

Минем икеләнеп торуымны күргәч, иптәш Мендуме нилектән шундый маршрут тәкъдим итүен аңлатты:

— Көньяк Тувадагы Танну-Ола тауларының аргы якларын белми торып, бөтен Туваны, Үзәк Азияне күрдек дип әйтеп булмый. Аннары Овюр районында курганнар, таш сыннар күбрәк очрар. Шулай ук безнең терлекчеләр белән дә танышырсыз.

Бу тәкъдимне кабул итмичә мөмкин түгел иде, әлбәттә. Менә шуңа күрә дә ашыгабыз.

Кечкенә генә инеш буйлап капка-тарлавык эченә кереп киттек. Сикереп-сикереп аккан инештән энҗеләр чәчри. Район үзәгендә эшләрне тиз-тиз бетереп, шундый бер су буена туктарбыз да төшке аш ашап, бераз ял итәрбез дип уйладым мин. Әмма Шуурмактан ун-унбиш километр да китеп өлгермәдек, кибеп, катып калган чүл-сахрага килеп чыктык. Менә шунда, коңгырт-соры далада тузанлы Самагалтай шәһәре утыра иде.

Район башкарма комитетында озак тоткарланмадык. Рәис урынбасары иптәш Шулумаадыр сүзне бик кыска тотты:

— Димәк, сезгә чик аркылы чыгарга пропуск кирәк?

— Әйе.

— Ярар, була ул,— дип звонокка басты.

— Ә юллар ничек? — дип сорадым мин.— Ничек барасы?

— Юл әйбәт, төп-төз, ялгышып әллә кая китү куркынычы юк, гел чик буйлап барасы.

Мин елмаеп куйдым:

— Адашып-нитеп чик аркылы чыгып китсәк?

— Бер нәрсә дә булмас: тотып алырлар да кире чыгарырлар.

— Заставага хәтле ничә километр соң?

— Туры юл белән барганда ике йөз илле километр чамасы.

— Димәк, «туры булмаган» юллар да бар?

— Әлбәттә, терлекче кышлакларына борылган сукмаклар шактый. Әгәр шулай буш кышлакларның берничәсенә кагыла-сугыла барсагыз, өч йөз километр чамасы булыр.

Барлы-юклы чәчләремнең бөтенесе дә үрә торды.

— Алайса бүген заставага җитә алмыйбыз дигән сүз!

— Әлбәттә. Сезгә бүген ике йөз километр чамасы узып, берәр сулы кышлакта туктау, заставага исә иртәгә җитү хәерле.

Мәсьәлә шулай катлаулана төште, чөнки йөзләгән чакрымнарны дәүләт чиге буйлап бару, аннары чик буенда ук учак кабызып куныл яту ихтималы безнең ише зур дәүләтнең үзәгендә яшәүчеләр өчен ничектер сәер, серле... шиклерәк иде. Ләкин башка ни чара бар?

Самагалтайдан чыгуга бер инеш буенда туктап тамак ялгап алырга булдык. Инеш суы чисталыкка чиста, ләкин кояшта җылынган, тәмсезләнгән иде. Шулай коры-сары белән тамак ялгап утырганда, шалтыр-шолтыр иткән, таралырга гына торган бер йөк машинасы килеп туктады. Шофер, баш кагып исәнләшеп, якынрак килде.

— Әйдә, безнең белән ашарга утыр!

— Четтирдим! (Янәсе, «рәхмәт».)

Форсаттан файдаланып, юл турында сорашабыз: ничек, әйбәтме, кайда кая таба борыласы? Ләкин канәгатьләнерлек җавап бирә алмады ул: русчаны да, тувачаны да рәтләп белми, монголчага безнең теш үтми.

Көнбатышка таба карап юнәлдек. Уң ягыбызда коңгырт-кызыл кыялар, бихисап таш түмгәкләр белән чуарланган агач-урманнан бөтенләй мәхрүм ялангач таулар. Барабыз, барабыз, бернинди яшеллек, су, үсемлек әсәре күренми.

Бу якларның кичләре дә үзенчәле, искитмәле кызык икән: җиргә сыек кына караңгылык җәелде, ә күк исә әйтеп бетергесез ачык зәңгәр, андагы төркем-төркем ак болытлар алтын нурлар белән кабынып, югары күтәрелгән саен төрләнеп, салават күпере шикелле балкыйлар иде... Дәфтәрен ачкан Тавил зәп-зәңгәр күккә карый, нурлар уйнатып балкыган болытларга соклана; сыза, буйый, тагын карый, ләкин секунд саен төрле төсмер алып яңарган, үзгәргән тизлеккә иярә алмый...

Ниһаять, күз талдырып карап бара торгач, тау арасыннан сузылып чыккан бер яшел тасма күреп алдым. Таудан агып төшкән инеш буендагы куаклар иде бу.

— Әйдә, бор машинаңны шул таба!

— Була ул,— диде Володя.— Ичмасам, бер юынып, чистарып алырбыз!

Ләкин юыну, су керү түгел, тынычлап ашарга да, онытылып йокларга да насыйп булмаган икән безгә... Башта әлеге яшел тасмага җитүе бер бәлагә әверелде. Юлсыз җирдән, эреле-ваклы ташлар өстеннән селкенеп, сикереп, кабина түбәсен тәртә-тәртә барырга туры килде. Ниһаять, баш түбәләребез ләпшәеп тигезләнер хәлгә җиткәндә, куаклы су буена барып чыктык. Дөреслектә бу тирән ермак төбендәге таллык икән. Ерактан бик матур күренсә дә, ермакның төбе кунар өчен бөтенләй җайсыз иде. Түмгәк ташларны читкә тәгәрәтеп, егетләрнең берсе шаярып әйтмешли, «яшәү мәйданы яулап алып», чатырны кордык. Ләкин нәкъ шул мәлне көтелмәгән афәт — озынборыннар һөҗүме башланды. Йорт чебене кебек эре, салам төсле сапсары, әллә нинди кибеп беткән коры озынборыннар иде болар. «Без-з-з-з» итеп килеп куна да, әллә нинди зур боравы белән тәнеңне боргычлап ала... Җәйге кыска төн узып, таң атканчы күзләребез дүрт булды; кояш чыкканчы ук ычкындык моннан.

Һаман ялангач таулар итәгеннән барабыз. Гел кипкән сахра, гел чүл. Иртәдән үк кыздыра, киптерә башлады. Кинәт Володя кычкырып җибәрде:

— Карагыз, күл!

Көзгедәй ялтырап яшькелт-зәңгәр фирүзә күл җәйрәп ята. Бу — Монголия җирендәге зур күлләрнең берсе, үзенә күрә чүл диңгезе Убсу-Нур иде. Икенче як кырые күренми, су белән күк бергә тоташкан. Димәк, дәүләт чиген узарга күп калмаган икән.

Әмма ике-өч көннән бирле күңелне борчыган бу чикне узу кызык кына булып чыкты. Иң элек сукаланган тасма аркылы уздык. Әнә кызыл, ак төскә буялган тәбәнәк чик баганалары. Бернинди сакчы-мазар күренми. Шулай да туктап, сакчылар күренмәсме дип, беркадәре көтеп торабыз. Менә Монголия җире буйлап барабыз. Уң якта биек таулар. Танну-Ола итәгенең нәкъ шул төшендә Монголия җире чөй сыман булып сузыла да тауның башына ук үрмәләп менеп китә. Безгә аны аркылы кисеп чыгарга кирәк икән.

«Чөйнең» киңлеге әллә ни зур түгел — нибары унике-унөч километр. Чик капкасы ябык. Машина шунда җитүгә автомат тоткан ике солдат капканы ачты, дөресрәге, ала-кола киртәне бер читкә каерып куйды. Машинадан төштек.

Документлар тикшерү, тиешле кенәгәгә теркәү эше биш-алты минутта бетте.

— Сау булыгыз!

— Туган якларга сәлам!

Чик аркылы узуыбыз шулай тәмамланды: гап-гади, бик җиңел. Әлбәттә, мондый җиңеллекнең нигезе бар: ике дәүләт арасындагы дуслык, татулык ул.

Балбаллар үзәне

Овюр районының үзәге. Вак-вак чәнечкеле куаклар белән капланган тау итәгендә утырган Хандагайты авылы. Агач йортлардан торган киң урамлы матур авыл. Ул нибары 1942 елны гына нигезләнгән. Берничә зур-зур таш бина да бар. Иң зурысында район партия һәм башкарма комитетлары урнашкан. Башкарма комитет рәисе иптәш Безги аз сүзле, ләкин бик практик кеше булып чыкты. Безнең максатны белүгә үк бер бит кәгазь алып, без барасы юлның, эзләп табасы төбәкләрнең план-схемасын төзи башлады.

— Менә бу Бура-Шай үзәнендә хорумнарны, таш көҗәләрне теләгәнчә табарсыз. Аннары Саглы авылына барып, тувалылар белән якыннан таныша аласыз. Иренмәгез, җәйләвенә хәтле барыгыз, мәңгелек бозларны да күрерсез.

Чик буенда, чебен-черкиләр белән әрләшеп, юлсыз җирләрдә селкенеп-тирбәлеп ике көн килүдән шактый арылган, машинаның да кайбер шөрепләре бушап өлгергән иде. Моннан соң юлыбыз тагы биек тау сыртлары аша узасы булганга, бер көнгә сөзәк тау итәкләре арасыннан аккан инеш буена ялга туктадык. Ләкин кинәт башланган яңгыр кәефләрне дә кырды, планнарның да бер өлешен җимерде. Иртәгесен юлга чыккач, яңгыр узып китүен көтеп тагы берәр көнгә калмавыбызга үкенеп бетә алмадык. Изрәгән сары балчыклы, вак-вак ташлы кыек юлда машинабыз әледән-әле таеп, шуып китә иде. Упкынга бер күз салуга машинадан төшеп каласы килә башлый.

Соңгы үткелгә менгәч бер мәлгә туктап ял иттек. Тува җирендә табигатьнең кискен, кинәт үзгәрүчән булуы моннан аерата ачык күренде: әле без килгән якларда таулар ялангач, соргылт иде, ә алда яшеллек.

Үзән буйлап берәр чакрым да китмәдек, кечкенә генә өч курган, ягъни борынгы кабер янына килеп чыктык. Берсенең өстендә схематик рәвештә ясалган таш сыны бар. Дүрт кырлы таш плитәнең баш өлешенә кеше йөзенең билгеләре сызылган — күз, каш, борын, мыек, авыз һәм ияк. Шуның янында ук көнчыгыш тарафка таба тезеп, эшкәртелмәгән сигез таш багана утыртылган. Болары — балбаллар.

Борынгы төрки халыкларда кабилә-ыру, ил башлыгы бәкләрнең, ханнарның, яисә атаклы сугышчыларның каберләре өстенә курган өеп, шул курган янына таш сыннар утырту гадәте булган. Андый һәйкәлләр мәрхүмнәрнең кыяфәтләрен гәүдәләндереп, шуларның образы, истәлеге булып хезмәт иткән. Әгәр мәрхүм исән чакта яуга йөргән, дошманны үтергән булса, кабердән көнчыгышка таба эшкәртелмәгән таш баганалар утыртып чыга торган булганнар. Һәр үтерелгән дошманга бер багана. Символ итеп куелган менә шундый баганага «балбал» дип әйткәннәр. Дөрес, фәнни әдәбиятта үлгән кешене гәүдәләндергән таш сынның үзен дә балбал дип атау очраклары шактый, ләкин борынгылыкта аның үз исеме булган — сын таш яисә таш сын. Хәзерге тувалыларның «көҗә» дигәннәре менә шул таш сын инде.

Тагы беркадәре баргач зур-зур курганнар арасына килеп чыктык. Берәүләренең диаметры җиде-сигез метр булса, икенчеләренеке егерме метрга җитәрлек иде. Берсе аерата зур, хәзерге биеклеге дә ике метр чамасы, гел таштан өелгән. Курганның тышкы ягы махсус алка — кеше башы кадәре ташлардан төзелгән «чылбыр» белән уратып алынган. Ләкин безнең исне китәргән нәрсә дәү кабернең үзе дә, аның янындагы алкасы да түгел, бәлки балбаллары иде. Көнчыгышка таба метр-метр ярымнан утыртыла барган ике рәт баганалар ике йөз илле метрга хәтле дәвам итә иде! Без шул баганалы «коридорның» бер башында торабыз, икенче очтагы балбаллар исә бәләкәй генә казыклар сыман күренә... Димәк, бер атаклы гаскәр башлыгы, яисә күп сугышлар кичергән ил агасы бәк кабере янында торабыз икән. Ләкин, кызганыч, кабер

өстендәге таш сынның үзе юк иде, әллә аны алып киткәннәр, әллә кемнәрдер җимерең, ватып ташлаган. Әлек андый хәлләр еш булган, кайберәүләр дошманнарыннан, алар үлгәч, каберләрен туздырып, таш сыннарын җимереп үч алган; икенче төркем истәлекләр соңрак дәверләрдә, дини фанатизм көчәйгәч харап ителгән. Шуңа күрә, борынгы төрки, уйгур, кыргыз каганлыклары чорына караган курганнарның саны күп булуга карамастан, безнең көннәргә хәтле һәйкәлләрнең бик аз өлеше генә килеп җитә алган.

Борынгы сыннарны соңгы чорларда «изге» дип исәпләү гадәте киң таралган булган. Башларына купшы бүрек кидереп, билләренә зиннәтле билбаулар бәйләнгән һәйкәлләрнең кулларына күп очракта нечкә билле савыт — кымыз эчә торган касә тоттырганнар. Болай эшләүнең үзенчә мәгънәсе бар: мәрхүмнең якыннары вакыт-вакыт кабер янына килеп, төрле йолалар уздырганнар, бергә-бергә ашап, кымыз эчкәннәр, бабаларының рухларына табынганнар. Кабердә ятучы да туганнары белән йола табынына «утырган», «ашаган», «эчкән»,— әлеге савыт шуңа ишарә. Болай кабер өстенә килеп табынулар, элгәреге эчтәлеген һәм формасын үзгәрткән рәвештә, тувалылар арасында ламаизм дине киң таралганчы дәвам иткән.

Дөрес, ата-бабалар каберен олылау, кабер өстенә истәлек ташы кую гадәте Идел буендагы болгарларда да киң таралган. Ул традиция соңгы дәвердә татарларда дәвам иткән. Бу хәл, һичшиксез, болгарлар белән борынгы төркиләр арасындагы тарихи якынлык турында сөйли.

Яңгыр чак кына туктап, юл кибә төште. Юлның ике ягында эреле-ваклы курганнар үтеп тора. Кайбер төшләрдә дүртәр, бишәрдән утыралар. Җыеп әйткәндә, Бура-Шай үзәнен Курганнар, яисә Балбаллар үзәне дип атарга ярый икән. Әгәр Уюкта скиф чорына караган берничә генә дистә курган сакланса, монда нигездә гел Төрек каганлыгы дәвере курганнары, һәм аларның саны йөзәрләп булыр. Әллә соң бу үзән элгәреге заманнарда бер халыкның дәүләт үзәге, яисә шул илнең махсус зиратлыгы булды микән? Кистереп җавап бирүе кыен. Курганнарның күбесе хәзер «телгә килмәячәк»: аларны борынгы заманнарда ук хәзинә эзләүчеләр талап өлгергән. Әнә, барысының өстендә диярлек аска убылып төшкән чокыр бар: хәзинә эз-

ләүчеләрнең «юлы» ул. Бәлки, таланмыйча калганнары да бардыр әле?..

Мондый бихисап күп курганнарны без Хакасиядә күргән идек. Анда аларны, табигый шартларның таләбеннән чыгып, күбрәк туфрактан эшләгәннәр. Шул ук вакытта Хакасиядәгеләрнең үзләренә генә хас хосусиятләре бар: диаметры дүрт-биш метр итеп туфрак өйгәч, тирәли зур-зур таш плитәләр яки кеше буе кадәре гранит баганалар утыртып чыкканнар. Мондый традиция борынгы скиф чорыннан башланып, урта гасыр тәрки дәверләргәчә, ягъни мең елдан артык дәвам иткән. Әмма безнең исне китәргән нәрсә аларның формасы, кыяфәте түгел, бәлки күплеге иде. Мәсәлән, Таштып дигән бер авылдан алып Абакан шәһәренә җиткәнче, чама белән 60—70 километрга сузылган юлның ике ягында таш плитәле, гранит баганалы вак калкулыклар тезелгән иде. Кайберләре юлның читенә үк киләләр, икенчеләре басу урталарында утрау-утрау булып калкып торалар, өченчеләре авыл читендә үк. Курганнар, гел курганнар, йөзләгән, меңләгән курганнар! Әллә бу Абакан суы үзәнендә элекке заманнарда гел курган ясаучылар гына яшәгән инде?! Ихтимал, бу бәрәкәтле җирләр дистәләгән гасырлар буена зур дәүләтләрнең үзәге булгандыр. Дәверләр артыннан дәверләр узган, буыннар артыннан буыннар килгән, үлгәннәрнең рухларына табынган кешеләр мәрхүмнәрнең өстенә зур-зур итеп җир өеп, түмгәкләр тирәсенә гранит баганалар кадый барган... Гасырлар артыннан гасырлар узып, әлеге серле кешеләр дә әллә кая китеп, дөресрәге, тарих казанында «эреп», үзгәреп беткәннәр. Бары бихисап курганнары, таш баганалары гына калган. Бер уйласаң, бик кызык, хәтта сәеррәк тә: хәзерге буыннар борынгы бабалары белән шушы каберләр ярдәмендә таныша. Икенче яктан бик гади: кешеләрне үстергән, туендырган җир-әнкә үз куенында аларның истәлекләрен дә саклый.

Хакасия турында сөйли башлагач, шуны да әйтергә кирәк: курганнар бары Абакан суы буенда гына түгел иде, алар илнең төньягында да йөзәрләп-йөзәрләп сакланган; галимнәрнең әйтүләренә караганда, бик күп истәлекләр Красноярск диңгезе астында калган...

Тувада курганнарның иң күбен без шушы Бура-Шай үзәнендә күрдек. Үзән хәзер буп-буш, терлек көтүләре дә бик сирәк күренә, малчыларның күпчелеге

Бура-Шай үзәне,
таш сын.



хәзер җәйләүләрдә — биек тау сыртларында. Аулак җир булгангадыр, очраткан бердәнбер кешебез безне күрүгә, җирән байталын чыбыркылый-чыбыркылый, китеп бару ягын карады. Аны көчкә генә туктатып юл турында, таш сыннар хакында сораштык.

— Көҗә?.. Бар, бар,— дип, безнең барасы якка ишарәләде, башка ачылып сөйләшмәде.

Район башкарма комитеты председателе сызган карта-схема буенча билгеләнгән җиргә җиттек. Караган дип атала торган кеше буе кадәре чәнечкеле куаклар арасында шактый вакыт эзләнеп йөрдек. Ләкин бер-ике әһәмиятсез кабердән башка бернәрсә дә күрә алмадык. Алга таба китәргә булдык. Машинага утырып, йөз метр да узмадык, Володя кычкырып җибәрде:

— Әнә ул, әнә!
— Кайда?
— Әнә бит, уң якта!

Юлдан дүрт-биш метр читтәге бер куак янында, әллә нәрсәләрне күзәткән төсле ерак-еракларга төбәлеп, таш сын — көҗә басып тора. Соры граниттан уелган, кешенең бөтен бит-кыяфәтен, гәүдәсен, кулларын ярыйсы гына төгәл чагылдырган сын иде бу. Моңарчы без күргәннәрнең барысыннан да пөхтәрәк, төгәлрәк итеп эшләнгән. Әллә кайларга төбәлгән шул һәйкәлгә сокланып, без шактый вакыт сүзсез тордык...

Тынлыкны беренче булып Хәлим бозды:
— Кем булды икән бу, ә?!
— Билгеле инде,— диде Рафаэль,— ярлы көтүче түгел, берәр зур бәк яисә батыр сугышчы булган.
— Кайбер галимнәр мондый таш сыннарны кабердә ятучының иң явыз дошманына куелган һәйкәл дип уйлыйлар,— дидем мин.— Минемчә, аны кабер иясенең үзе дип исәпләүчеләр хаклырак.
— Ә ни өчен? — диде Тавил.— Нинди дәлил бар ул карашны кире кагарга?
— Беренчедән, Монголиядәге Илтириш, Билгә, Күлтәгин каберләре өстендәге сыннарның шул кабердә ятучыларның үзләре булуы фәндә бәхәс тудырмый. Димәк, әлеге карашны кабул итсәк, аларның «явыз дошманнары» булмаган булып чыга. Икенчедән, Россия сахраларындагы төрки таш сыннарның күпчелеге хатын-кызларны гәүдәләндергән. Шуңа күрә борынгы кыпчак сахраларындагы бәкләрнең, батыр сугышчыларның иң явыз дошманнары хатыннар булды микәнни дигән сорау туа. Өченчедән, кайбер таш сыннарның кием-салымнарындагы төркичә булмаган элементларга гына карап, аларны төрки бәкләрнең «дошманнары» дип уйлау бәхәсле. Кием-салымда читтән кергән моданың чагылуы бик ихтимал. Аннары төрки дәүләт составына чыгышлары буенча башка этник группаларга караган кабиләләрнең дә керүе бик табигый бит. Бер дәүләтне дә этник, ягъни милли яктан «саф» итеп карарга ярамый. Һәрхәлдә таш сыннар кабердә ятучыларның үзләрен гәүдәләндерә дигән караш күбрәк ышандыра.

Тагы коеп яңгыр ява башлады. Караңгы да төште, кунарга урын эзләргә, таш сын янына исә иртәгә килергә кирәк... Күп тә узмый, берничә агач йорт, каралты-кура янына — хуҗасыз калган кышлакка ки-

леп җиттек. Шул йортларның берсенә тукталуны хәерле таптык. Өйнең эчендә плитә-мичләре дә бар икән: димәк, чыланган киемнәребезне киптерергә мөмкин. Бүлмәләрне җыештырдык. Әрем төтәтеп өй эчен ысладык; аннары ишек-тәрәзәләрне ачып җилләттек...

Көҗә таш белән очрашу тәэсиреннән һаман айный алмаган егетләрнең берсе аны Казанга алып китү турында сүз башлады.

— Бик дөрес! — диде Володя.— Мин күптән уйлап утырам инде, күп итеп печән җыябыз да, яхшылап төреп, кузовның алгы ягына аркылы салабыз аны!

Рафаэльне башка нәрсә борчый икән:

— Университетта кайда сакларбыз икән үзен?

— Китапханә бинасына куярга мөмкин.

— Минемчә,— диде Тавил,— сәнгать музеена тапшырырга кирәк аны.

— Юк,— диде Хәлим моңа каршы,— экспедиция университетныкы, һәйкәл дә анда булырга тиеш!

— Анда аны кем күрә соң?

— Ә күрмәсәни?!

Мин дәшмичә утырдым, чөнки, дөресен әйткәндә, нәфес белән хокук арасында туган конфликттан аптырый идем: бик шәп булыр иде дә алып китсәк, тик...

— Егетләр, алай эшләргә хакыбыз юк бит.

— Ник булмасын?

— Җаваплылыкны үз өстемә алам! Машина минеке, мин салып киттем, вәссәләм!

— Кем тикшерсен аның юкка чыгуын?

Кыскасы, егетләр тәмам кызды. Ятарга вакыт иде. Бәхәскә чик куярга кирәк булды:

— Һәйкәлне алып китү турында уйларга да ярамый, моңа безнең бернинди хакыбыз юк, без бары практика узар өчен генә килгән кешеләр. Хәерле йокы.

Кемдер төрткәләгәнгә уянып киттем. Тавил икән.

— Иртә бит әле,— дим,— сәгать бишенче яртысы гына.

— Йоклап булмый.

— Нигә?

— Күз алдымнан әлеге таш сынның кыяфәте китми. Әйтерсең, чәнечкеле куаклар арасыннан кеше сыны түгел, ә борынгы заманның үзе карап утыра!

Әйдә, кузгалыйк әле, тизрәк рәсемен ясыйсы килә. Күз алдыңа китер әле: тау, болытлар, тырпаеп торган чәнечкеле куаклар һәм... ерак-ераклардан безгә карап торучы таш сын.

Көн кояшлы иде. Ачык һавада үзән аерата матур икән. Күтәренке күңел белән таш сыныбыз янына килдек. Ул һаман ерак-еракка карап утыра. Бүген кичәге кебек соклану, гаҗәпләнү белән артык мавыкмадык. Һәйкәлне төрле яклап үлчәп, тасвирлап, кирәкле саннарын язып, сызымын алдык. Сынның җир өстендәге өлеше 115, җилкә киңлеге 30, гәүдә калынлыгы 20 сантиметр икән.

Һәйкәлдән дүрт-биш адым читтә җыелмалы кечкенә урындыкта Тавил утыра. Аның карандашы күз иярмәслек тизлек белән йөгерә-йөгерә дә туктап кала, аннары тагы җитез хәрәкәтләнә башлый. Рәсем ясаган чакта кеше карап торуны яратмый ул. Шуңа күрә, Рафаэль белән таш сынны төрле яктан үлчәп бетергәч, мин куаклар арасына кереп киттем. Чәнечкеле, усал иде бу куаклар. Шактый йөреп, тәмам тырналып беткәч кенә өч курган күрдем. Берсенең схематик рәвештә эшләнгән таш сыны сакланган. Янында балбаллары авып ята.

Кояш мәрхәмәтсез кыздыра башлады. Мин егетләр янына юнәлдем. Тавил һаман ясап утыра, баш өстенә зонтын корып куйган, ул текәлеп-текәлеп таш сынга карый, әйтерсең лә борынгы кешенең уй-хыялын, эч серләрен белергә тырыша.

Мондый истәлекләр тарихчы өчен борынгы кешеләрнең гореф-гадәтләрен, йолаларын, кием-салымын, көнкүреш сәнгатен өйрәнүгә чыганак булып хезмәт итә. Менә бүреге. Мондыйларны без колакчын дип атыйбыз. Нәкъ шушы формадагы колакчыннарны тувалылар соңгы вакытларга хәтле кигәннәр. 87 сантиметр озынлыктагы билбавында исә төрле бизәкләр бар: дүртпочмаклылары, йөрәксыманнары, түгәрәкләре. Купшы билбаудан 12 һәм 16 сантиметр озынлыкта каеш чуклар салынып төшкән, һәрберсенең өстенә, очына металл (мөгаен, көмеш) бизәкләр сурәте төшерелгән. Әгәр шул каештагы, аннары билгә тагылган хәнҗәр кынысындагы орнамент-бизәкләрне бер тәртипкә салып, аларның үз ишеләре белән чагыштырып карасаң, борынгы төркиләрнең көнкүреш сәнгате, зәвыклары турында фикер йөртергә мөмкин.

Таш сында гәүдәләнгән сугышчының озын чәчле булуы да игътибарга лаек: һәйкәлнең җилкәсенә озын-озын толымнар салынып төшкән. Ләкин бу көньяк Россия далаларында очрый торган, фәндә «таш-хатын» (каменная баба) исеме белән мәгълүм борынгы кыпчак төркиләреннән калган хатын-кыз, ягъни ана сыны түгел, бәлки купшы мыеклы ир кешенең һәйкәле. Чыннан да, борынгы төркиләрдә ирләр озын толым йөрткәннәр. Өстәвенә ул чорларда ирләр арасында алка кию гадәте дә булган. Менә ул, түгәрәк алка!

Мондый һәйкәлләрнең битен-йөзен, күз-кабак сызыкларын җентекләп тикшерсәң, нинди расага караган булуын ачыкларга мөмкин. Беренчедән, ул һәйкәлләрне мәрхүмнәрнең кыяфәтләренә охшатып ясарга тырышканнар; икенчедән, мәгълүм булганча, төрле халык яки кабилә вәкиле үзе ясаган кеше сурәтендә бары үз халкына гына хас милли хосусиятләрне чагылдыра. Мәсәлән, кытай рәссамы ясаган рус кешесенең сурәтендә һәрвакытта диярлек әзме-күпме «кытайлык» галәмәтләре табып була. Борынгы кешеләрнең расаларын билгеләү фән өчен гаять мөһим: нинди халыкларның кайлардан чыгуын, кай тарафларга күченүен, бер милләтнең нинди төр кабиләләрдән оешуын ачыкларга мөмкинлек туа.

Азия һәм Европа сахраларында очрый торган истәлекләрнең бер өлешендә таш сын кулына, әйткәнемчә, озынча савыт тоттырылган булса, икенчеләренең кулында кош (шоңкар, лачын) сурәтен күрергә мөмкин. Галимнәрнең уйлавынча, бу кош үлгән кешенең рухын, җанын гәүдәләндергән. Бик кызык, әһәмиятле факт бу, күрәсең безнең телдәге «күңел кошы» дигән серле гыйбарә менә шундый ышануларга барып тоташадыр. Борынгы чор шагыйребез Колгали Ягкубның үлеме турында язып болай ди:

«Шәриф тәндин аерылды газиз җаны,
Коша биңзәп оҗмах таба очар имди».

Ягъни «...җан кошка охшап оҗмахка таба оча» икән. XIV гасырда Идел буенда яшәгән Котби: «Бу күңелемнең кошы кем тапты хуш баг», ди. 1522 елда кабер өстенә куелган татарча язуда шундый сүзләр бар: «Үлем куанчысы йитте, безем куанчымыз китте, мәгәр шоңкар булып очты, табылмас эстәгәнемез...»

«Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы...»

Монысы — Тукай сүзләре. Шулай итеп, серле тарих җебенең бер очында Тукай шигыре, икенче башында борынгы таш сыннар. Бүгенге сорауга җавапны узганнан эзлә... Әйе, бу таш сыннарны борынгы кешеләрдән безнең көннәргә килеп җитә алган илчеләр, хәбәрчеләр дияргә мөмкин. Бары аларны сөйләтә белергә генә кирәк. Моның өчен фактларны күп итеп җыю, ягъни күп санлы истәлекләрне үзара чагыштыру, җентекләп тикшерү таләп ителә. Әгәр Монголия, Тува, Алтайдагы көҗәләрне Казагстан җирендә, Урта Азиядә табылган һәйкәлләр, шулай ук Түбән Идел буе һәм көньяк Россия далаларында сакланган мәһабәт таш сыннар белән эзлекле рәвештә чагыштырсаң, борынгы күчмә кабиләләр, аларның чыгышлары, уртаклык һәм аерымлыклары хакында гаять бай мәгълүмат тупланыр иде. Тарихи фактларны шулай киң планда чагыштырып тикшергәндә генә чынбарлыкны төгәл чагылдыра торган гадел гыйльми нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин.

Шундый уйларга бирелеп утыра торгач мин узган көнне Хандагайтыда булган бер очрашуны искә төшердем. Безги янында утырган чакта кәтелмәгән кунаклар — Монголиядән килгән ике кеше керде. Берсе монгол колхозының җитәкчесе икән. Форсаттан файдаланып, мин аңардан:

— Чикнең теге ягында таш һәйкәлләр бармы? — дип сорадым.

— Таш сыннармы? — диде иптәш Эренҗин.— Таш сыннар бездә бик күп. Минем колхоз территориясендә генә илледән артык көҗә саклана. Күрше колхозда тагы да күбрәк диләр.

— Аларны тикшерүчеләр, өйрәнүчеләр бармы соң?

— Юк,— диде яңа танышым,— моннан җиде-сигез ел элек Улан-Батордан берәү килгән иде. Башка хәтерләмим.

Мин артык сорашмауны хәерлерәк таптым: кыйммәтле тарихи истәлекләрнең гыйльми игътибардан читтә калуларын ишетүе күңелле түгел иде. «Хәер,— дидем мин эчемнән генә.— Монголиядә иясез калган төрки истәлекләрнең санын да, чамасын да белмибез бит. Каган булып каган курганнары һаман казылмаган, гадиләренә ни үпкә?..»

Ниһаять, рәссам үз эшен тәмамлады. «Гасырлар илчесе» белән бергәләп сурәткә төштек.

Соңгы мәртәбә таш сын тирәли әйләнеп чыктым. Тип-тигез җирдә, бер кечкенә куак янәшәсендә утыра ул. Янында балбаллары юк. Бәлки алар ватылгандыр, бәлки аларны җыештырып, бер читкә илтеп ташлаганнардыр: әйләнә-тирәне сукалап иген чәчкәннәр. Шулай, узган заманнарның истәлекләре көнкүреш ыгы-зыгысында кими тора, юкка чыга бара. Үзләре генә түгел, эзләре дә бетә бара.

Саглыда танышу

Янтая-янтая тау битендәге юлдан барабыз. Бөтен тау итәген вак кына куаклар каплаган. Вакыт-вакыт җиргә сеңеп киткәндәй ерымнар төбенә төшәбез һәм шунда ук калкып тагы күтәреләбез. Бер кечкенә генә үткелдән төшкән чакта, юл кырыендагы әрәмәлектән уктай атылып илек — урман кәҗәсе чыгып качты. Володя, юлның начар булуына карамастан, таштан ташка сикереп кәҗә артыннан куа башлады. Ләкин кая аның артыннан җитү... Без ике-өч түмгәктән узганчы, ул әллә кайдагы куаклар арасында юк та булды.

Бер сыртка менүгә алдыбызда ачылган күренештән бөтен җәфалар онытылды: ике зур үзән кушылган җирдә, тау борынының тигезләнә төшкән итәгендә киң урамлы зур авыл утыра иде. Урамының ике ягы буйлап чыршы-карагайлар тезелгән. Авыл яныннан таштан ташка сикерә-сикерә көмеш сулы инеш ага. Бу Саглы авылы иде.

Һәр урамнан диярлек тау елгасыннан ерып кертелгән чиста, тонык сулы арыклар уза.

«Кызыл туг» [1] колхозы рәисе Санаа Оорҗак колхозчыларның көнкүреше, авыл культурасының үзгәреше хакында тәфсилләп сөйләде. Мәсәлән, сигезьеллык мәктәптә эшләүче югары белемле укытучыларның барысы да шушы авыл кешеләре икән. Зоотехник, агроном, ветврач, баш экономистлар да шунда туып-үскән, колхоз стипендиясенә укып кайткан белгечләр. Тиздән зур культура йорты да өлгерәчәк.

— Карагыз әле,— ди Санаа җанланып,— бүген бездә Кызылдан килгән артистлар концерт бирәчәк, бәлки килерсез?

---

[1] Кызыл байрак.

Яшь карагайлар арасында яшел аланга урнашкан лагерьда Рафаэль безне аш әзерләп көтеп тора икән. Аштан торып өлгермәдек, әллә кайдан бер кисәк кара болыт чыкты да, зур кыялар ишелеп, таулар җимерелгәндәй, күк күкрәргә тотынды, чатнап, чәчрәп яшен яшьни башлады һәм шунда ук чиләкләп яңгыр коярга кереште. Әйтерсең лә, күктә меңләгән тимер мичкәләрне тәгәрәтәләр, әйтерсең лә, анда утлы еланнар ажгырып сикерешә... Тау яңгыры ничек капыл ява башлаган булса, шундый ук тизлек белән ачылды да: чәчрәп кояшның кыек нурлары төште, меңләгән, миллионлаган алмаз тамчылар күзләрне камаштырып җемелдәргә тотынды. Ул арада биек тауның нәкъ үркәче өстенә төшкән кояш, әзгә генә туктап, гөлт итеп бер яктырды да, аскы ягыннан кителә-кителә, түбәнгә төшеп китте...

Концертка барасы бар иде. Кем дежур булып кала? Рафаэльме? Теләми! Фәритме? Юк... Җирәбә салабыз. Иң «бәхетле кеше» Хәлим икән...

Клуб ишегенә кирәклек түгел иде. Шәһәр артистларын күрү шатлыгы, уен-тамаша сагыну бик ачык сизелеп тора. Кунаклык әдәбен саклап, бер читтә генә сөйләшеп торганда, яныбызга шәһәрчә киенгән, кыяфәте әллә ничек бик таныш агай килде:

— Гафу итегез, сез Казан кунаклары бугай?!

— Әйе.

— Алайса рәхим итегез.

Ул безне сәхнә артындагы бүлмәгә алып керде һәм шунда гына кулын сузып:

— Таныш булыйк, Максим Мунзук,— диде.

Аның кыяфәте каян таныш булуын мин шунда ук аңладым.

— Мин сезне кайда күрдем соң дип торам! «Зәңгәр елгалар хуҗасы», «Шаһитның юкка чыгуы» дигән фильмнарда күргән икәнмен үзегезне!

— Ихтимал,— диде ул, елмаеп.— Минем Казанда бер мәртәбә булганым бар, 1935 елны, Мәскәүдән курс бетереп кайтышлый.

Клуб халык белән шыгрым тулы. Сәхнәгә конферансье чыгуга, зал шып тынды. Тува, монгол халык җырлары, шаян такмаклар яңгырый башлады. Үзем тыңлыйм, үзем Максим Мунзук турында уйлыйм. Биографиясе бик бай, язмышы гаять гыйбрәтле кеше. 1912 елны ярлы арат — терлекче гаиләсендә туган. Яшьли үк тамак өчен байларның терлеген көтәргә ял-

ланган. Кучмә халыкларда ялчы баланың күргәне эт көне: бусага төбендә йоклау, туяр-туймас тамагына кушып хуҗа камчысын ашау... Шуңа күрә 1921 елны халык власте урнашу малайлыкта иза чиккән Максим өчен коллыктан котылу була. 1929 елны ул Тува революцион яшьләр союзына керә. 18 яшьлек егет байгуралар фетнәсен бастыруда катнаша. Аннан соң Мәскәүдә укый, офицерлыкка әзерләнә. Ләкин юлы икенче якка борыла — җыр, мәзәк сүз ярата торган, көр күңелле, бер елмаюы белән тамашачының игътибарын җәлеп итә торган сөйкемле Максим Мунзук күп еллардан бирле Тува театрларының сәхнәсен бизәп килә.

Тува халык көйләрен беренче мәртәбә без шулай Монголия чигендәге Саглы дигән авылда тыңладык. Бик таныш, якын моңнар... Бер ара онытылып китеп, үземне Татарстандагы бер кечкенә авыл клубында утырган кебек хис итә башладым; шаян җыр үзенең көе, аһәңе белән нәкъ безнең күңелле такмаклар шикелле яңгырый иде. Бары сүзләре генә төгәл аңлашылып җитми, шулай да «кара-кара караклар» дигән гыйбарәдән сүзнең бер чибәрнең кап-кара күзләре, шул күзләрнең бер егетне «акылдан яздыруы» турында икәнлеге аңлашыла. Икенче егет салмак кына бер сылуга булган мәхәббәте, аны өзелеп сагынуы хакында җырлый башлады. Бусы да таныш моң, бусы да безнең җырларыбыз кебек якын. Сүзләренең ритмы да татарча: «Бик саргайдым, бик сагындым, әле дә ничек үлмәдем», дигән җыр кебек яңгырый.

Борынгы монгол моңы яңгыраганда залда тирән тынлык урнашты. Халык бу көйне үз итеп, онытылып, яратып, аңлап тыңлый. Ничә гасырлардан бирле монголлар белән аралашып яшәүнең, дус-тату яшәүнең билгесе бу. Сәхнәгә курайчы чыга. Курае аның безнең татар курае кебек, ә көендә озын башкорт җырларының, Ашказар һәм Дим буйларының моңы яңгырый. Бу да әлеге бер тарихи сер: төрле шартларда яшәгән, күптән культура-экономик мөнәсәбәттә тормаган халыкларның музыкасындагы бу уртаклык каян килә? «Бер төрки телле кардәш халыклар бит!» — дип кенә котылып булмый бу сораудан. Тел, гореф-гадәтләре белән тувалыларга караганда безгә якынрак, таныштрак булган үзбәк, кара-калпак һәм төркмәннәрнең музыкалары татарныкына бер дә охшамый. Ә тува һәм монгол моңнарын без, бигрәк тә курайда уйнаганнарын, кайчакларны үз көебез, үз мо-

ңыбыз итеп тыңлыйбыз. Моны дөрес чишәр өчен музыка белгечләренең зур тырышлыгы өстенә, тарихны да тирән белүләре таләп ителә.

Чатыр эче кап-караңгы. Егетләр күптән йокыга талган. Инешнең чылтырап агуы ишетелә. Күз алдында һаман клуб сәхнәсе... Максим Мунзук — кәтүче малай... Республиканың халык артисты... Колак төбендә исә әллә кайлардан ишетелгән курай моңы яңгырый; шунда ук кап-кара күзләр турындагы таныш шаян җырның көр аһәңе ишетелә... Туып, формалашып килә торган яшь халыкның, дөресрәге, яңа тарихи шартларда нигездән яшәргән халыкның сәнгате... Чишмә чылтырап ага. Ул зуррак инешләргә коя. Шулай зур елгалар, дәрьялар барлыкка килә.

* * *

Иртәнге якта авылда төрле кешеләр белән очрашып, сөйләшеп йөрдек; хәзерге тувалыларның көнкүреше, гореф-гадәте белән дә беркадәре танышырга кирәк иде. Рафаэльгә бигрәк тә агач йортлы ихаталар эчендә утырган киез өйләр ошады, берсеннән чыгып икенчесенә кереп йөрде. Фәрит әкрен генә сөйләшеп, тува теле буенча материал җыя.

Татар, башкорт, казакъ, үзбәк һәм башка төрки телләр системасында тува теле аерым урын тота. Әгәр татар кешесе казакъ яисә кара-калпак белән тиз генә аңлаша алса, тувалылар белән сөйләшү өчен шактый тырышлык һәм белем кирәк. Беренчедән, тува телендә архаик, ягъни борынгы төрки элементлар күп сакланган. Икенчедән, татар, башкорт, үзбәк телләрендә гарәп, фарсы сүзләре күп булса, тува телендә монгол, тибет, хәтта кытай элементлары зур урын ала. Шуңа күрә, монгол теленнән хәбәрдар булмыйча торып, тувача китапларны аңлавы бик читен. Дөрес, гади халык сөйләме җиңелрәк аңлашыла. Ләкин уртак сүзләрне аңлар өчен дә беркадәре тәҗрибә, күнекмә кирәк. Моның шулай икәнлеген түбәндәге мәкальләрдән күрергә мөмкин: «Куш — уялык, кижи чурттуг», ягъни: «Кош — оялы, кеше йортлы (булыр)»; «йорт» биредә ил мәгънәсендә. «Аат өлүр,— баглаажы ар-

тар, ада өлүр — оглу артар», ягъни: «Ат үләр — багана агачы калыр, ата үләр — улы калыр» (баглаажы — ат бәйли торган махсус багана). «Баштай үнгән кулакты соңнай үнгән мыйыс эртәр» — «Башта үскән колактан соңрак үскән мөгез узар». «Ат болуру кулунундан, кижи болуру чажындан» — «Ат булыры колын чагыннан (билгеле), кеше буласы — яшеннән». «Оолдуг кижи оя сөглэр, кыстыг кижи кыя сөглэр», янәсе «Уллы кеше уеп (турыдан ярып) сөйләр, кызлы кеше кыеклап (киная белән) сөйләр».

Берничә җыр да китерик:

Ырлап бэрейн, дыңнаар сэн бе,
Хөрээң човаа дээр сэн бе?
Ыглап бэрэйн, кээргээр сэн бе,
Караaң чорваа дээр сэн бе?

Мәгънәсе:

Җырлап бирәем — тыңларсыңмы?
Күкрәгең моңлы (сагышлы) диярсеңме?
Җылап бирәем, кызганырсыңмы,
Күзләрең моңлы (яшьле) диярсеңме?

Тагы бер җыр:

Хандагайты ажып кэлдим,
Карам, сэңээ чэдип кэлдим;
Бура-Шайлап атып кэлдим,
Борбаам, сэңээ чэдип кэлдим.

Мәгънәсе:

Хандагайты аркылы (кичеп) килдем,
Кара күзем, сиңа җитеп килдем;
Бура-Шайлар аркылы (ашып) килдем,
Җанкисәгем, сиңа җитеп килдем.

Мин монда аңлаешлырак, татарча җиңелрәк тәрҗемә ителә торган мисалларны сайладым. Бик күп сүзләрне, мәкаль-җырларны кат-кат әйтеп, кабат-кабат укып та сүзлексез аңлап булмый. Бигрәк тә культура, дәүләт-административ төшенчәләрен белдергән атамаларның барысы да диярлек монгол, тибет телләреннән алынган.

Кеше исемнәренең күпчелеге дә (мәсәлән, Дуржы, Чайбар, Эренҗин кебекләр) тибет, монгол тамырына кайтып кала. Чын тувача, ягъни төрки тамырлы исемнәр дә шактый: Алдын-оол (Алтын угыл), Кызыл-оол

(Кызыл угыл), Кара-кыс (Кара кыз), Семиз-кыс (Симез кыз) һәм башкалар. Егерменче гасыр башыннан алып русча, аннары европача исемнәр керә башлый.

Саглы авылы нәкъ чик буенда. Авыл кырыеннан узган тирән ерымның икенче ягында тимер чыбыклы баганалар тезелеп киткән. Тагы биш-алты километрда яшел урман белән капланган биек тау. Чайбар карт, бу төбәкләрнең атаклы аучысы, күрсәтеп куя:

— Анда марал бик күп. Хәзер дә... Элек без шунда ауга йөри идек. Берьюлы җиде марал атып кайткан идем!..

Элек, Тува халык республикасы чорында, Монголия белән арадагы чикнең нәкъ кайдан узганлыгын да яхшы белмәгәннәр, имеш.

Әллә кайдан мотоциклына бер бәләкәй картны утырткан авыл советы председателе килеп чыкты:

— Менә сезгә җәйләүгә юл күрсәтүче,— диде ул елмаеп.— Тик русча бернәрсә дә белми, аңлашырсыз әле шунда!..

Кызыл чырайлы, мыеклары тырпайган, бәләкәй гәүдәле карт сөйкемле елмаеп тора.

— Аатың кым? — дип сорыйм.

— Һо! — ди ул, үз телендә мөрәҗәгать итүгә сөенеп.— Аатым Сэдэн, памилам Ооржак!

Ләкин иркенләп сөйләшер өчен барыбер минем сүзлегем ярлы иде, шуңа күрә юл буе күбрәк бармак ярдәмендә аңлашып барырга туры килде. Ун бармакны да эшкә җигеп, һәр бармактан соң бер-ике төркичә уртак сүзне кыстырып куйсаң, ярыйсы гына килеп чыга икән. Ара-тирә карандаш белән кәгазьгә мөрәҗәгать итәбез, чөнки язылган сүзләрнең мәгънәсенә җитүе минем өчен җиңелрәк иде. Күрәсең, башка телләр белән күбрәк китап аркылы танышу нәтиҗәседер бу... Шулай да, ни генә булмасын, бертуктаусыз мыкылдып-тыкылдап, бер-беребезне яхшы ук аңлап бардык. Мәсәлән, мин Сэдэннең ике улы, бер кызы, дүрт оныгы барлыгын, карчыгының гаять усал булуын белдем; үзе яшь чакта байлар көтүен көткән, аннары дәүләт секторы хуҗалыгында эшләгән, хәзер каравылчы икән; монголчаны бераз сукалый, язуга исә утыз яшендә генә өйрәнгән. Минем дә кайда яшәвемне, нәрсә эшләвемне, ничә бала үстереп, хатыным кем булуын, аена күпме хезмәт хакы алуыбызны тәфсилләп сорашты ул. Мин бу яклар турында аңардан нәр-

сәләр сорашып белүемә караганда, ул Казан турында күбрәк мәгълүмат туплады бугай.

Саглы үзәне буйлап югары күтәрелгән саен табигать сизелеп яшәрә, җанлана барды. Терлек көтүләре, ап-ак тирмәләр очрый. Ак башлы тауларның сулышыннан һава салкынча, рәхәт. Бөтен юл буена эрелеваклы курганнар сибелгән; формалары буенча, VII—XII йөзләргә, ягъни төрле төрки дәүләтләр (борынгы төркиләр, уйгурлар, кыргызлар) хөкем сөргән чорларга карый булыр. Ләкин, ни гаҗәптер, таш сыннары, балбаллары юк. Андыйлар хакында Сәдән дә бернәрсә хәтерләми.

Үзән буйлап шактый югары күтәрелгәч, юл күрсәтүчебез якындагы ике тирмәгә таба борылырга кушты. Өй янында паласка кибәр өчен эремчек җәйгәннәр иде. Аны араластырып утыручы орчык кебек бәләкәй генә киленчәк, безне күрүгә сикереп торып, тирмә ишеген ачты. Түргә узабыз. Тыштан караганда чын күчмә халыклар тирмәсе булса да, эчтән ул яхшы ук үзгәреп өлгергән икән. Өй уртасында морҗасы чаңрактан, ягъни тирмә түбәсендәге төнлектән, тышка чыккан зур тимер мич тора. Элекке заманнарда утучак идәндә янган. Ике якта йомшак сиртмәле, ак башлы караватлар; түрдә кечкенә генә комод, аның бер башында «Рекорд» радиоалгычы, икенче кырыенда сәгать, уртада исә аяклы көзге. Идәнгә киез җәелгән, киез өстендә кечкенә генә төркмән келәме ята...

Киленчәкнең ире көтүгә киткән булып чыкты. Сәдән ашыгуыбыз турында әйтте. Безнең бу яклар өчен бөтенләй ят кыяфәтләребездән киленчәк беркадәре аптырап калды бугай, туры карарга кыюлыгы җитми; хәрәкәтләрендә каударлану, каушау сизелә. Ул алдыбызга бер табак сөтле ризык, җиде-сигез касә китереп куйды. Бу тувалыларның хойтпак дигән эчемлеге иде. Бездәге эче әйрәнне, беркадәре кымызны да хәтерләтә торган, эсседә искитмәле шәп эчемлек. Хойтпакны мактый-мактый эчүебездән канатланган киленчәк бер тәлинкә эремчек, икенчесе белән майда йөздереп пешергән чәлпәкләр (күзикмәкләр) китерде. Ләкин озак сыйланырга вакыт аз иде, бераз авыз иткәч, рәхмәтләр әйтеп тышка чыктык.

Һаман үргә, һаман югарыга менеп барабыз. Сизелеп салкынайды. Терлекләр төре дә үзгәрде: гадәти сыерлар, сарыклар урынына безнең өчен ят сарлыклар күренә башлады. Бер тирмә янында шуларның

бер төркеме тора иде. Машина килеп туктауга алар кереп читкә тайпылдылар. Бәйдәге бозаулары янында торганнар икән. Бозау дигәннән аларның сыер нәселеннән булуы аңлашылса кирәк. Әйе, сарлык дигәнебез (гомум төркичә — «кутас», русча — як), гади итеп әйткәндә, тау сыеры була. Нәкъ безнең сыерлар кебек кабак танаулы, дәү мөгезле, аеры тояклы. Тик йоннары гына озын — җәйгә хәтле кыркылмаган кәҗә тәкәләре сыман: койрыклары да урталай киселгән ат койрыгын хәтерләтә. Өстәвенә тавышлары да башка: дуңгыз кебек мырк-мырк итәләр. Холыклары да үзгә — өркәк, кыргый, хәтта усал. Әнә йөнтәс бозаулары да безгә, дошманнарын күргәндәй, усал итеп төксәеп карыйлар.

Тирмәдән озын зәңгәр чапан кигән, шоколад изеп сылагандай коңгырт-кара битле бер карт чыкты.

— Эки!

— Эки! Эки! — диде ул ачык чырай белән.— Өгкә кер!

Ягъни: «Сәлам, сәлам, өйгә керегез»,— ди иде ул.

Без өйгә кереп җайлап утырырга да өлгермәдек, ире кебек үк кара-кучкыл чырайлы чандыр әби бер савыт май белән зур табак тулы бавырсак китереп куйды. Сэдэн майга таба ишарә итте:

— Сарлык сөтеннән.

Сарлык сөтенең безнең өчен ят нәрсә булуын ишетеп, әби бер кәстрүл яңа сауган сөт китерде. Бик куе икән. Тувалыларда, башка күчмә халыклардагы кебек үк, өйгә кергән юлчыга тәгам бирмәү зур кимчелек санала: тәкъдим ителгән аштан баш тарту исә бөтенләй килешмәгән эш.

Бер-берсенә бик тә охшаган әби белән бабай икесе дә милли киемнән иде: озын итеп сырып теккән, чабулары киң, якасыз чапан, чүпрәк билбау, табан очы өскә караган кәкре борынлы итекләр. Түрдә утыручы оныклары исә нәкъ безнең малайлар шикелле фабрикада тегелгән чалбар, бизәкле йон свитер кигән. Шулай, кием-салымнарда да борынгылык белән хәзерге дәвер янәшә яши.

Берәр касә чәй эчкәч кенә хуҗа безнең кем булуыбыз, кайдан килүебез, нишләп йөрүебез хакында сораша башлады. Аңлашырга безгә аның армиядән кайткан улы ярдәм итте.

Киткән чакта без татарчалатып: «Хушыгыз!» — дип кычкырдык, алар исә үз телләрендә:

— Байырлык, байырлык! — дип кул болгап калдылар.

Көн кичкә таба авышкан иде. Димәк, Саглыга таба борылырга вакыт. Ләкин Сэдэн карт безне икенчерәк юл белән алып китте, шактый баргач, шоферга тау битенә таба үрмәләргә кушты.

— Кая барабыз соң?

— Анда аржаан бар, аржаан! — дип ул, чабып китәргә җыенгандай, утырган җирендә бер омтылып куйды.

Аржаан дип җирдән чыккан минераль су чыганаклары аталуы хакында бер әйткән идем инде. Тау күкрәгеннән чыгып торган бу аржаанны да җирле халык изге дип саный икән. Чишмә янындагы куакларга төрле төстәге чүпрәкләр бәйләнгән булуы шуны күрсәтә. Болай олылауның нигезе дә бар: боздай салкын чишмә суы, тикшерүчеләр әйтүенә караганда, ашказаны авыруларына шифалы икән. Ләкин, кызганычка каршы, шифалы су бушка гына агып, җиргә сеңеп ята... Хәер, Тува җирендә файдаланылмыйча яткан минераль чыганаклар бик күп әле. Димәк, киләчәктә саф һавалы Тува тауларында, аның яшел үзәннәрендә курортлар, санаторийлар салыначак.

Кыядагы могҗиза

Саглыдан Чаданга карап юнәлгән чакта Танну-Ола сыртына мендек. Артта — әлеге Монголия чиге буйлап барганда күргән ялангач кыялар, алда исә тау, үзәннәр иксез-чиксез бөдрә урман белән капланган. Әйтерсең лә синең алда гадәти таулар түгел, ә ярсып күккә үрелгән яшел дулкыннар дөньясы. Кечкенә ерым белән башланган, аннары тирәнәйгән, киңәйгән үзән буйлап түбәнгә төшеп киттек. Гадәти бер үзәннән түгел, бәлки әкиятләрдә сурәтләнә торган гүзәллектән төшеп киттек... узып киттек. Тәгәрәп-аунап ятардай яшел аланнар, мүкәләп йөрердәй иркен болыннар, зөбәрҗәт үзәннәрдә алмаз каш кебек утырган ап-ак тирмәләр артта кала бардылар. Шушы иркенлектә рәхәтләнеп ял итәсе, аланнарда аунап, болыннарда җиләк чүпләп йөрисе иде дә бит!..

«Вакыт, вакыт...— дип уйладым мин.— Атларда, дөяләрдә генә йөргән элгәреге сәяхәтчеләргә ул вакыт

ничек җитте икән?.. Ә бәлки шулай атларда, дөяләрдә йөрүе кызыклырактыр? Һәр җирнең һавасын күбрәк иснәп, сулышын озаграк тоясың, рәхәтен дә, михнәтен дә туйганчы күрәсең...»

Уйларым нәкъ шул төшкә җиткәндә Володя машинасын туктатты да, тәрәзәдән башын сузып, нидер карый башлады.

— Нәрсә таптың?

— Тапмадым, югалттым,— диде ул күңелсез генә. Мин сагаеп калдым.

— Вакытны югалттым,— диде ул көрсенеп.— Көпчәкнең тыны чыккан, ә Чаданга хәтле тагы утыз чакырым...

— Әзер көпчәгең бардыр бит.

— Барын бар, ләкин ышанычлы түгел.

— Ник соң элек кайгыртмадың?

— Вакыт булдымыни?

Телемне тешләдем... Вакыт...

Тавил үпкәсен белдерергә ашыкты:

— Шундый матур урманнардан җил кебек узып киттек, чак кына туктап эскизлар сызарга мөмкинлек бирмисез бит! Машинасы да, ичмасам, урынын, вакытын белеп ватылмый...

— Менә хәзер вакыт бар, әйдә сызгала!

— Нәрсәне ясарга? Шушы шәрә тауларнымы?

— Әйе! — дидем мин, аны үчекләргә теләп.— Ялангач кешеләрне бик яратып ясыйсыз бит!

Рәссам дустым миңа текәлеп карап торды да, җүләр син дигәндәй, үз маңгаена бер-ике төртеп, читкә китте.

Әйе, без тагы түбәнгә, чүл-сахрага төшкән идек. Нибары унбиш-егерме чакрым ара узылган, дөнья бөтенләй үзгәргән.

Чадан шәһәрендә район башкарма комитеты председателе Борис Чюдюк безне күргәч ачылып китте.

— Һо, менә бу кызык! — диде ул күрешеп.— Казан хәтле Казаннан тагы килеп чыккач, безнең кыя сурәтләрендә хикмәт бар дигән сүз!

Әйе, Хемчик елгасы буендагы кыяларда сакланган язулар, сурәтләр фән өчен зур әһәмияткә ия. Яңадан килүебезнең максаты шул былтыр күргән язулар, сурәтләрне эшкәртү иде. Шуңа күрә, Чюдюк яныннан чыгуга, елга буйлап туп-туры Хая ужы, ягъни Кыя очы дигән төбәккә юнәлдек.

Хемчик буе, кыядагы мараллар.

Юлның уң ягында комлы сөзәк таулар, тыз-быз чапкан йомраннар дөньясы; сул якта ямь-яшел тугайлы елга үзәне. Анда, ике-өч төркемгә бүленеп, тирмәләр утыра.

Менә Хая ужы — елга буйлап өч-дүрт чакрымга хәтле сузылган коңгырт, хәтта куе кызыл ташлы текә, биек кыялар. Ара-тирә алар күгелҗем-яшькелт төскә керә, аннары тагы кызара башлый.

Алдан атлаучы егетләр, ташларның төрләнеп торган төсләре, кыяларның текәлеге, үткен кырлары, очлы почмаклары белән мавыгып, сурәтләрне күрмичә узып китә яздылар. Былтыр бу тирәләрдә бер мәртәбә булган Фәрит моны абайлап алып кире борылды һәм, сурәтле кыя төбенә килеп, борынгы рәссам әсәренә сүзсез генә карап тора башлады. Башкалар да беренче күрүгә: «У-у, ах!.. менә бу сурәт, ичмасам!» — дип сокланышып алдылар, аннары бер мәлгә өнсез калдылар.

Шаккатарлык та иде шул. Кыяның җирдән өч-дүрт метр биеклектәге тип-тигез төшендә өч марал, бер поши сурәте. Мараллар өстәрәк, алар сул якка карап чабып баралар. Әйтерсең лә җиргә бер тибүдә

көчле аяклар, пружина сыман сыгылып, гәүдәне алга чөеп җибәргән дә, ук кебек атылып артка сузылган, һәм шул хәтле көчле тибенгән ки, менә хәзер дә һава ярып очып бара сыман. Башлар алга сузылган, күзләр еракка төбәлгән; тармак-тармак купшы мөгезләр бер карасаң, хикмәтле таҗ сыман, бер карасаң, әкияттәге толпар атның тузгыган ялларын хәтерләтә. Бу җиңеллек, бу тигезлек, бу мәңгелек хәрәкәтне — динамиканы борынгы рәссам ничек итеп шул хәтле төгәл, шул кадәре сиздереп бирә алган? Аны аңлатуы мөмкин түгел, бары күреп кенә, тоеп кына була ул хәрәкәтне. Баксаң, артык сызыклар да юк: гәүдә, сын кыяфәтен билгеләгән гадәти контур сызыклары гына. Ләкин киек түшенә бирелгән җилне син үз күкрәгеңдә тоясың, һаваны марал түгел, әйтерсең лә син ярып очасың. Йөгереп китәсе, чабасы, сикерәсе, очасы килә...

Рәссам ирешкән хәрәкәт, динамика менә шулай искитәрлек иде. Ләкин сурәтнең мәгънәсе бу тизлектән генә гыйбарәт түгел. Әнә, бер маралның аркасына ук кадалган, димәк, аучылык күренеше... Алайса аучылар кайда? Гомумән, ни өчен ясалган бу аучылык күренеше? Бер уңышлы ауның истәлеген мәңгеләштерү өченме? Әллә тәңредән шундый эре киекләр, зур уңышлар теләпме? Ниһаять, моны кемнәр ясаган? Кайчан?

Чак кына астарак икенче тарафка карап бер поши чабып бара. Ул авыр гәүдәле, киң күкрәкле, гүяки, түшләре белән куе куакларны ерып бара. Аның хәрәкәте салмак, көчле.

Сурәтләрне күрүгә ук Тавил альбомын, карандашын алды. Ләкин маралларга беркадәре текәлеп торгач, карандашын кире кесәсенә салып, альбомын култыгына кыстырды һәм читкәрәк китеп, бер таш өстенә чүгәләде дә, ияклэренә таянган хәлдә, рәсемгә текәлеп утыра башлады.

Саян-Алтай тауларында очрый торган петроглифларның, ягъни ташларга уеп ясалган сурәтләрнең күпчелегеннән үзгә буларак, бу мараллар эре-эре итеп зур планда ясалган иде. Мәсәлән, гадәти петроглифларның күбесе нигездә 15—20 сантиметр зурлыкта булса, мондагы бер маралның гәүдә озынлыгы (арт аяк очыннан танауга хәтле) 75 сантиметр иде.

Һәр сурәтне аерым-аерым үлчәп, композициянең гомуми планын да алгач, фотоаппаратларны эшкә

җиктек. Моннан соң сызык контурлары әйбәтрәк күренсен өчен, кыя битенә акшар сөртеп чыгабыз. Мамык һәм йомшак чүпрәк белән җиңелчә генә төртептөртеп, ташның кырылмаган тигез төшләрен агартабыз. Чак кына уентык, чокырлы җирләргә буяу тимәскә тиеш. Шулай иткәндә таштагы һәр сызык, һәр ярык ак фонда ак кәгазьдәге сызымнар кебек аермачык күренә башлый. Дөрес, фәндә таштагы сызыклар өстеннән гади акбур белән сызып чыгу ысулы киңрәк таралган. Әмма бу ысул белән кирәкле пөхтәлеккә ирешеп булмый.

Борынгы петроглифларның һәм кыя язуларының күчермәләрен алуда фоторәсемнәр белән генә чикләнмиләр, әлбәттә. Төгәл копия алуның да әллә ничә төре бар. Ләкин без иң гади ысул белән файдаланабыз: сурәт өстенә куелган йомшак кәгазьгә сусыл үлән белән ышкыйбыз — шактый төгәл контур сызыклары беленә.

Марал сурәтеннән унбиш-егерме адым җирдә, кыяның түбәнрәк төшендә, канатларын җәеп торган бөркет рәсеме бар иде. Бер карауга ул бик гадәти, хәтта примитиврак кебек: бәтен кош гәүдәсе уеп, чукып ясалган; канатлары җәелеп торса да, хәрәкәт, динамика чагылмый. Үзәк Азия һәм Себердә, мәсәлән, Якутия белән Бурятиядә, Алтай белән Монголиядә мондый бөркет сурәтләре шактый еш очрый. Безгә таныш Күлтәгиннең һәйкәлендә, бүрегенең алгы ягында, канатын җәеп торган бөркет сурәте бар. Күрәсең, борынгы төркиләрдә бөркет рәсеме зур власть, көч символы булган. Этнограф галимнәрнең әйтүләренә караганда, бу якларда яшәгән борынгы кешеләр бөркеткә табынган, имеш. Иртән ялтырап чыккан кояшны күккә бөркет күтәреп менгерә дип инанганнар; баласыз хатын шул бөркеттән бала сораган, әгәр, теләге «кабул булып», угыл тапса, аңа «бөркет биргән» дип исем кушкан. Бу ышанычның калдык галәмәтләре якутларда, бурятларда соңгы дәверләргә кадәр сакланган. Димәк, моннан мең, хәтта ике мең ел элек кыяларга ясалган сурәтләр белән хәзерге кайбер халыкларның йолалары арасында тыгыз мөнәсәбәт бар булып чыга.

— Бире килегез әле,— дип кычкырды Рафаэль,— монда да сурәт бар!

— Нинди сурәт?

— Кәҗә бугай.

— Юк, зур койрыклы эт! — диде Хәлим.

— Рафаэль хаклы,— дидем мин таныш рәсемне күргә.— Зур мөгезле тау тәкәсенең сурәте бу. Алтай, Саян, Монголия кыяларында күп очрый ул. Моның өстенә бу сурәт гасырлардан гасырларга күчкән. Шуңа күрә аның кайсы чорга караган булуын ачыклау бәхәс тудыра. Бары безнең көннәрдә генә бер төркем тәкәләрнең скиф чорында ук иҗат ителгәне, икенчеләренең Төрек каганлыгы дәверенә каравы исбат ителде. Хәтта схематик формада ясалган зур мөгезле тәкә сурәте каганнарга махсус билге — тамга булып хезмәт иткән. Мәсәлән, җиденче гасырның ахырында үлгән Илтириш каганның каберендәге язулы ташта тәкә-тамга бар.

— Димәк,— диде Тавил,— скифлар борынгы төркиләрнең бабалары булып чыга алайса?

— Алай ук дип әйтмәдем...

— Ашыкма. Курган өстенә таш сын кую гадәте скифларда да, борынгы төркиләрдә дә булган. Шулай бит? Шулай. Скиф орнаментларының хуннарда, хәтта соңгы дәвер төрки халыкларда дәвам итүен үзең әйттеңме? Үзең! Хәзер менә тәкәләрнең дә уртак образ булуын белдек, йә?!

— Бер яктан, дөресрәге материаль культураның, ягъни көнкүреш әйберләрнең, корал-ядракларның кайбер элементларын исәпкә алсаң, шулайрак килеп чыга. Ләкин скифлар, төгәлрәк әйткәндә, борынгы грек язучылары яхшы белгән скифлар иран телле халык булган. Фәндә шундый караш хөкем сөрә.

— Минемчә, Көньяк Себердә, Үзәк Азиядә яшәгән скиф чоры халыклары этник яктан бик чуар булган дигән караш дөресрәк. Борынгы төркиләрнең бабалары да, һичшиксез, шул халыклар белән аралашып яшәгән. Бер тел бер кабиләнең үзенә генә хас булса, материаль культура элементлары төрле кабиләләр, төрле халыклар арасына тарала алган.

Куллары акшарланып беткән Фәрит килде. Ул баядан бирле шушы Хая уҗындагы бер кечкенә рунник текстның күчермәсен алу белән мәшгуль иде. Күчермәле кәгазьләребезне рәтләп торганда, яныбызга кечкенә буйлы бер карт килеп туктады. Ябык гәүдәсе алга таба иелеп торган бабай иде бу. Исәнләштек, хәлэхвәл сораштык. Хемчик елгасына коя торган Ишкин исемле инеш буендагы авылдан икән ул. Исеме Дурҗы. Безнең кыя сурәтләре белән кызыксынуыбызны

күргәч, теге яктагы тау битендә мондыйларның тагы да күбрәк икәнлеген әйтте. Ләкин тау битендә кыялар да бик күп, аларның кайсысына барып карарга? Дуржы карт үзе юл күрсәтергә ризалык бирде.

Тау итәгендәге ерым-ерымлы, сикәлтәле юлдан бик озак баргач кына, Дуржы карт бер борын өстендәге зур кыяларга ишарәләп күрсәтте:

— Әнә шунда, аны Эзир[1] оя дип атыйлар.

Чыннан да, бөркетләр оя ясарлык биек иде ул кыялар.

Җәяүләп кенә тау битенә үрмәли башладык. Юлдан өч-дүрт йөз метр күтәрелгәч дәү-дәү таш түмгәкләр арасына килеп кердек. Дуржы карт беркадәр вакыт эзләгән нәрсәләрен таба алмыйча йөрде.

— Малай чакта, кәтү көтеп йөргәндә күргән идем. Ашыкма, хәзер табабыз аны...— диде ул, безне тынычландырырга теләп.

Без дә һәр түмгәкне, һәр кыяны җентекләп карый башладык. Менә алар! Беравык күзләремә ышанмыйча тордым... Безнең алда бер галерея иде. Менә зур-зур мөгезле тау тәкәләре, әнә купшы «таҗларын» горур күтәреп йөрүче зифа мараллар, шунда ук кабан дуңгызлары, бүреләр, төлкеләр... юк, этләр бугай... Бер ташта ау күренеше сурәтләнгән: ике җайдак киек куып бара, берсе җәядән атып җибәргән, угы менә-менә киек җилкәсенә кадалачак.

Егетләр сурәтләрдән эстамп-копия алыр өчен әзерләнгән арада, мин әйләнә-тирәдәге башка ташларны да карап чыктым. Тагы өч-дүрт түмгәктә сурәтләр бар икән.

Стиленә, ташны чукып ую техникасына карагандa, бу сурәтләр бик күптән — скиф дәвере, яисә аннан да элегрәк ясалган булырга тиеш. Кыя очындагы мараллар белән чагыштырганда, бу яңаларында гадилек, хәтта бераз схематизм сизелеп тора. Күпчелегенә динамика җитми, сәнгать әсәреннән бигрәк символларны күбрәк хәтерләтә. Кыскасы, соңгырак дәвергә тартым әлеге очып баручы маралларга караганда элгәрерәк ясалуы шик тудырмый. Тарихи күзлектән карагандa, мондыйлары тагы да әһәмиятлерәк, чөнки алар ярдәмендә хәзерге фән өчен караңгырак булган бронза һәм таш гасырлары чорына узып кереп, шул дәверләрдә яшәгән кешеләрнең гореф-гадәтләре, хуҗа-

[1] Эзир — бөркет.

лык, көнкүреш шартлары хакында өстәмә мәгълүмат алырга мөмкин.

Бер тәкә сурәте шактый җитди, оста эшләнгән иде: артык бер сызык та юк, киекнең бөтен рәвеше төгәл чагылган.

— Моны сезнеңчә ничек атыйлар? — дип сорадым Дурҗыдан.

— Тәә,— диде челемен пыскытып утыручы карт.

— Бу тирәдә тәәләр күп очрыймы?

— Монда юк алар,— диде ул, кечкенә башын чайкап.— Моннан сиксән километрда гына бар диләр.

Димәк, элек нәкъ менә шушы төбәкләрдә дә тау тәкәләре, кабан дуңгызлары киң таралган булырга тиеш. Хәтта хәзер нәселе бөтен Азиядә кырылып беткән зур мөгезле кыргый үгезләр дә яшәгән биредә. Әнә ул үгез сурәте. Юк, гадәти генә йорт сыеры, яисә сарлык түгел, бәлки чын буйвол! Димәк, борынгы кешеләр шуларны аулап көн күргәннәр, ау уңышлы булсын дип, менә бу сурәт-догаларны ташка уеп ясаганнар. Кыскасы, без борынгы кешеләрнең гыйбадәтханәләрендә торабыз.

Петроглифлар өлкәсе гаять бай, бик катлаулы өлкә. Әгәр кешелек тарихындагы иң борынгы язма истәлекләрдә дүрт-биш мең ел элекке вакыйгалар чагылса, кайбер кыя сурәтләре моннан унбиш-егерме мең ел элек булып узган хәлләрне белергә ярдәм итә. Алар кайбер мөһим географик үзгәрешләр хакында да хәбәр итә. Мәсәлән, Монголиядәге Гоби чүленең үзәгендәге бер кыяда — күл, инешләрнең әсәре дә булмаган дип уйлаган җирдә — очып барган үрдәк сурәтләре табыла. Димәк, кайчандыр Үзәк Азиядә дымлырак, йомшаграк һава хөкем сөргән икән. Ихтимал, нәкъ шул чорларда Үзәк Азиядә зур цивилизацияләр барлыкка килгәндер.

Кайбер өлкәләрнең борынгы фаунасы, ягъни җанварлар дөньясы хакында да петроглифлар кызыклы мәгълүматләр бирә. Мәсәлән, Африкада Сахара чүле дөньядагы иң зур, иң кырыс чүл. Аның күп өлешендә хәзер бернинди яшеллек, хәтта тереклек юк. Моннан биш-алты мең еллар элек шул «үле чүлдә» елгалар гөрләп аккан, урманнар шаулап торган. Моның шулай булуы хакында Үзәк Сахарада табылган кыя «елъязмасы» — фил, антилопа һәм башка сурәтләр сөйли.

Кыя сурәтләре кайчакларда фән алдына бик авыр мәсьәләләр куя. Әйтик, әле генә телгә алынган Сахарада скафандрлы космонавтларны хәтерләткән сәер рәсемнәр бар. Аларның кайберләре гадәти җир кешеләренә охшамый. Чит галәмнәрдән килүчеләрнең сурәте түгел микән бу?! Галимнәрнең бер төркеме мондый карашны кире кага. Ә кайберләре өстәмә дәлилләр китерә... Бәхәс әле дә хәл ителмәгән.

Кыя рәссамнары әсәрләреннән бары иҗтимагый-социаль тарих өчен генә информация эзләү аларның кыйммәтен бер яклы гына яктырту булыр иде. Чынлыкта кыяларда сакланган әлеге сурәтләр иң элек сәнгать әсәрләре бит! Арада мәңге кабатланмас шедеврлар бар. Борынгы кешеләрнең дөньяны, матурлыкны бик нечкә тоя белүләрен, образның төп сыйфатын калку итеп, тиешле хәрәкәтне дә төгәл бирә алуларын күрәбез. Таш гасыры чорында ук ирешкән конкретлык, төгәллек һәм хәрәкәтне соңрак без Борынгы Мисыр белән Грециядә, Һиндстан һәм Византиядә күрәбез. Ул сыйфатлар Яңарыш чорында, соңгы гасырларда тагы да үстерелә. Шуңа күрә чын сәнгатьлелекне аерым бер халыкка, яки конкрет культурага гына кайтарырга ярамый. Әнә очып баручы мараллар... Аларны кемнәр, нинди телдә сөйләшүче кешеләр ясаган булуга карамыйча, чын сәнгать әсәрләре булып кала бирәләр. Бу сәнгать барыбыз өчен дә уртак, барлык халыклар өчен якын, газиз.

Ламалардан калган эз

Арып-талып мөлдерәмә сулы Ишкин буена кайткач, әлбәттә, иң элек салкын суга бер-ике чумып алдык. Күтәренке күңел, якты чырай белән гөрләшә-гөрләшә зур тирәк күләгәсендәге табын янына чүгәләдек; шулай утырган чакта кунагыбыз Дурҗы карт икенче бер яңалык ычкындырып куйды: әгәр шушы инеш буйлап сигез-тугыз километр барсаң, аннары, уң яктагы кечерәк тарлавыкка борылып, тагы шуның хәтле юл узсаң, Биҗикти хая дигән җиргә җитәсең икән. Биҗикти хая — бичикле, ягъни язулы кыя?!

— Дурҗы ага, язуы чыннан да бармы?

— Булмаса, алай атамаслар иде.

— Ә машина бара аламы соң анда?

— Бара, бик әйбәт бара!

Минем болай җилкенеп китүем юкка түгел иде: кайда нинди тарихи истәлекләр, язулы ташлар булуы хакында Кызыл шәһәрендә сүз булганда, бу Ишкин тарлавыгы бөтенләй телгә алынмаган иде. Дөрес, Тувада бер Биҗикти хая барын беләм, ләкин ул бөтенләй башка якта. Димәк, монысы башка булып чыга! Әгәр бу беркем белмәгән таш булса?

— Барасыңмы иртәгә безнең белән?

— Юк, иртәгә Чаданга китәм.

Без үзебез генә барырга булдык.

Кыя битен кисеп ясаган тар юлдан көч-хәлгә генә барган чакта, Володя Дурҗы картны әрләп бетерә алмады. Шулай да, алга киткән саен юллар хәтәрләнә төшсә дә, артка борылу хакында уйламады: мөһим ачыш ясау мөмкинлеге аны да канатландырган иде.

Ләкин язулы кыяның кайда булуын да төгаен белмибез. Шулай шикләнеп, шөбһәләнеп барганда, көтмәгәндә, бер тирмә янына килеп чыктык. Өй янында күләгәдә кул тегермәне белән он тартып утырган хатын аптырап ирене карый, агач киледә тары төеп торучы ире исә безнең ала-кола машинабызга төбәлеп сәерсенеп калган.

Хуҗадан язулы кыя турында сорыйм. Ул, тарлавыкның икенче ягына ишарәләп, зур-зур кызыл кыялар төркеменә күрсәтә.

— Ә биҗиге, язуы кайсы төштә соң?

— Белмим...

— Бу якта Биҗикти хая дип аталган башка кыялар тагы бармы?

— Юк.

— Димәк, Биҗикти хая дип шуңа гына әйтәләр?

— Әйе.

Шәрә, очлы ташлар белән капланган тау битенә менүе шактый авыр булды. Җитмәсә көн бик эссе, кояшта ташлар кызудан һава коры мунча кебек бөркү. Маңгайдан аккан тир күзләргә керә, күлмәкләр тәнгә сылана. Моның өстенә һәр адымны абайлап атларга кирәк, бер ташка ялгыш бассаң, я үзең мәтәлеп төшәсең, яки әлеге таш текә тау битеннән аска тәгәрәп, түбәндә атлаучы юлдашыңа барып тиячәк.

Шактый җирне карап чыктык. Язу-мазар күренми. Сурәтләр дә юк. Ләкин бер кыяны карап бетерүгә

Кызыл шәһәре музеендагы таш сын.

сүнә башлаган өметләребез яңадан кабына: алда тагы кыялар бар, бәлки шулардадыр ул язулар?!

Менә шулай тегесендәдер, монысындадыр дип, кыядан кыяга, түмгәктән түмгәккә күчә-күчә, ниһаять, бөтен тауны айкап чыктык.

Тирмә янына тәмам арып, бөтенләй хәлдән таеп кайттык. Хуҗа хатын кыяфәтләребезгә беравык кызганып карап торды да тирмәгә кереп китте һәм бер табак хойтпак алып чыкты. Салкын иде, искитмәле тәмле иде ул!

Шифалы эчемлектән соң рәхәт израп, маңгайга бәреп чыккан салкын тирләрне сөртә-сөртә, карт карагай күләгәсендә озак кына утырдык. Бераз хәл җыйгач тагын сорашырга, русча начар белүче, гомумән йомык табигатьле хуҗаны сораулар белән тагы газапларга дипниятли идем. Көтмәгәндә бер җайдак килеп чыкты. Элек хуҗа белән сөйләште, аннары безнең

янга килде һәм тувачалап исәнләшкәч, авыз кырыен ерып, төзек кенә русчалап сорады:

— Табып булмадымыни язуны, егетләр?

— Булмады шул...

— Булмагач ничек табылсын ди ул?

— Алайса ни өчен Язулы кыя дип атала?

— Чөнки элек булган ул язулар, ә хәзер юк инде.

— Кая киткәннәр?

— Усал ламалар, ягъни безнең элекке монахлар җимереп бетергәннәр, чөнки халык хурәгә — будда йортына бармыйча, шул таш янына килеп табына торган булган. Бабам шулай сөйләгән иде.

Менә шул. Бөтен тырышулар юкка чыкты. Фәнгә җиңел генә бер өлеш кертербез дигән садә өметләребез дә әлеге маңгай тирләре кебек очты да бетте.

Ләкин бу үкенеч безнең башка гына төшкән нәрсә түгел. Мондый югалтулар бик күп булган тарихта. Балбаллар үзәнен гизгән чакта борынгы таш һәйкәлләрнең соңгы дәверләрдә юри юк ителү очракларын әйтеп узган идем. Шулай, кешеләр үлгән дошманнарының каберен туздырып, һәйкәлләрен җимереп үч алганнар. Яңа яулап алучылар элгәреге хуҗаларның эзләрен бетерергә, җир йөзеннән генә түгел, халык аңыннан да аларның истәлекләрен кырып, себерең ташларга теләгәннәр. Чөнки һәр яулап алучы үзен шушы җирнең, шушында яшәгән халыкның мәңгелек хуҗасы дип игълан итәргә, бу дәгъвасын исбат итәргә тырышкан. Шул максатка ирешү өчен элгәрегедән калган истәлекләр белән дә көрәшкән. Монголиягә сәяхәт ясаган археолог галимнәр андагы борынгы истәлекләрнең никадәр мәһабәт булуын күрсәтү белән, аларның бик нык имгәтелүен, хәтта бөтенләй җимерелүен сыкрап язалар. Мәсәлән, Үзәк Азиядә туган сынлы сәнгатьнең иң гүзәл үрнәкләре булып саналырлык каган һәйкәлләренең берсе дә хәзер сакланмаган: я аларның гәүдәләре генә калган, яки өзелгән башлары гына җирдә аунап ята. Башсыз һәйкәлләр Тувада да очраштыргалый. Элек күпме балбал куелган, хәзер аларның нинди өлеше генә сакланган — моны беркем дә белми. Безнең Бижикти хая шулай харап ителгән язма истәлекләрнең ничәнчесе булгандыр.

Бу тарихи истәлекләрнең күпчелеге дин-идеология алмашынган чорда харап булган. Яңа динне күбрәк һәм тизрәк таратырга тырышкан руханилар искедән калган «изге» истәлекләрне рәхимсез рәвештә җимер-

гәннәр, үзләренең шушы кыргыйлыкларын «яңалык өчен көрәш» зарурилыгы, ягъни прогрессив эш дип игълан иткәннәр. Каршылык күрсәткән кешеләр дә корбан булган. Буддизм динен таратырга тырышкан ламалар да кайбер мәҗүси тувалылар табынган таш сыннарны, борынгы язуларны юк итәргә ашыккан.

— Мондый кыргыйлык башка бер җирдә дә булмагандыр! — дип куя Хәлим.

— Алай ук түгел шул! — дидем мин, учакка берике чыбык ташлап.— Мәсәлән, безнең Урта Идел буена кайтыйк. Болгар чорында язу, язма культура киң таралган булган. Шул чордан калган бик күп кабер ташларын XVII—XVIII йөзләрдә фанатик христиан миссионерлары юк иткәннәр; күпләгән язулы ташларны чиркәү-монастырь нигезләренә салганнар. Чөнки аларга татарларның бабаларыннан калган «изге» истәлекләрне халыкның күзеннән яшерергә кирәк булган: аларның бөтен максаты мөселман татарларны христиан диненә күчерү, аларны яңа хуҗаларга — христиан феодалларга ныграк буйсындыру булган. Бу — мәсьәләнең бер ягы. Ә менә Болгар җиренә ислам дине таралган чакта исә яңа формалашкан мөселман руханилары үзләре дә элеккерәк чорга караган сыннарны, язма истәлекләрне рәхимсез рәвештә бетерә барган, халык аңыннан элекке инануларын шулай чыгарып ташларга омтылган алар. Әле генә Монголиядәге төрки каганнарының һәйкәлләре ваттырылган булуын әйткән идем. Ә шул каганнар үзләре күпме тарихи истәлекләрне юк итүен беләбезме без? Алар төрле илләрне, шәһәрләрне яулап алганнар, сугыш вакытында бик күп кешеләр үтерелгән. Мәсәлән, атлы гаскәрләре белән дошман өстенә өермәдәй ташланган, кинәт һөҗүмнәр оештыруда дан казанган Күлтәгиннең кабере янына куелган балбаллар чылбыры дүрт ярым километрга сузыла! Шул кадәр халыкны кырган сугышчы дошманнарының изге әйберләрен кызганып торды микән?! Юк, билгеле. Һәрхәлдә, борынгы истәлекләрне җимерү кешеләрнең шәхси сыйфатларына гына бәйләнмәгән. Бу — сыйнфый җәмгыятьләрдә өзлексез дәвам иткән идеологик, политик көрәшләрнең аерылгысыз өлеше.

Ниһаять, иген игү, йорт салу кебек көндәлек ихтыяҗлардан чыгып та кешеләр шактый истәлекләрне бетергәннәр.

— Минемчә, борынгы культураларның юкка чы-

гуында күчмә тормышның да гаебе зур булса кирәк,— диде учакка карап сүзсез утырган Рафаэль.

— Алай ук берьяклы хөкем чыгарырга ярамас. Борынгы ыруг, кабиләләр тормышына чагыштырып караганда, күчмә терлекчелек хуҗалыгы, һичшиксез, алга таба бер зур адым. Моның шулай икәнлеген Үзәк Азиядә күчмә дәүләтләр, империяләр оешу факты раслый. Күчмә хуҗалык барлыкка килгәч кешеләр иркенрәк, мулрак яши башлаганнар. Терлек биреп торган үрчем исәбенә тормыш көтү мөмкинлеге туган. Тарихи чагыштырып караганда, бу, һичшиксез, шулай. Әмма шушы шарт үзе — җитештерүне мал-туарның табигый үрчүенә генә кайтарып калдыру, җир-табигать белән интенсив рәвештә көрәшү ихтыяҗының юклыгы тора-бара хуҗалыкта, тормышта торгынлыкка китергән. Нәтиҗәдә кайчандыр утрак халыклардан көчлерәк булган күчмә илләрдә иҗтимагый тормыш берничә гасыр элекке дәрәҗәсендә катып кала, тора-бара алар утрак халыкларга буйсынып, колониаль изүгә дучар ителә.

Рафаэль бәхәсне дәвам итәргә теләп:

— Ярар, шулай булсын. Ләкин урта гасырларда күчмәләрнең башка халыкларны яулап алуларын ничек бәяләргә: уңаймы, тискәреме? — диде.

— Әгәр борынгы яулап алуларны, кабилә-ыруг чорына һәм күчмә тормышка гына хас нәрсә дип билгеләсәк, соңгырак дәверләрдәге утрак халыкларның колониаль яулап алуларын, каршылык күрсәтүчеләрне кыруларын, рәхимсез изүләрен ничек бәяләргә? Утрак тормышның кимчелеге, аерым бер халыкның милли үзенчәлеге, ягъни кансызлыгы, вәхшилеге итеп бәяләргәме?!

— Юк билгеле...

— Алайса ни өчен урта гасырлардагы зур яулап алуларны да социаль шартларга, әйтик, күчмә халыкларда формалаша башлаган феодаль мөнәсәбәтләргә бәйләп карамаска?.. Узган тарихны өйрәнүдән, тарихи белемебезне үстерүдән максат — борынгы халыкларның берсен гаепләү, кимсетү, икенчесен аклау, мактау түгел, бәлки вакыйгаларның объектив сәбәпләрен ачыклау, узганны дөрес аңлау, дөрес аңлату.

Мәсьәлә катлаулы, вакыт шактый соң иде. Мин урынымнан тордым:

— Ярар, егетләр, ял итик, әңгәмәне иртәгә дәвам итәрбез. Иртәгә бит безне озын юл көтә.

Будда мәгарәсе янында

Иртәгесен, тәмамланмый калган әңгәмәбезгә кайтканчы, безгә ламалар эзе белән тагы бер кат очрашырга туры килде. Кызыл Маҗалык ягында булды бу очрашу. Ул якка барудан максат Кызыл Маҗалык шәһәреннән Хакасиягә таба юл тоту иде. Шуңа күрә Чадан шәһәреннән Хемчик елгасының башына карап юнәлдек.

Хемчик үзәне, тулаем алганда, коры сахра, ярымчүлдән гыйбарәт. Бары үзән уртасында гына бормаланып яшел тасма — бөдрә тугайлы зәңгәр елга сузыла. Ара-тирә аннан яшел үрентеләр «үсеп чыга»; болар зур елгага койган башка эреле-ваклы инешләр булыр. Шулай, яшеллек бу үзәннәрдә гел елга-инеш буйларында гына. Елгадан чак кына читкә киттеңме — коры сахра, хәтта вак ташлы чүл башлана. Ләкин нәкъ менә шул Хемчик үзәне борынгы дәвер Тува тарихында гаять зур роль уйнаган: халыкның төп өлеше шунда яшәп, хәзерге тувалыларның бабалары да нигездә шул тирәләрдә формалашкан. Җыеп әйткәндә, Хемчик буе Тува халкының, Тува культурасының тарихи үзәге, мәдәни учагы да ул.

Үзән буйлап барган чакта мин ирексездән былтыргы сәяхәтне дә искә төшердем. Узган ел белән чагыштырганда сизелерлек үзгәрешләр бар. Мәсәлән, элекке сәфәребездә Кызылдан чыгуга ук юл буйлап тезелгән югары вольтлы электр баганаларын очраткан идек, алар әле чыбыксыз-кабельсез иде. Быел исә әлеге корыч баһадирлар Чаданга килеп җиткән генә түгел, хәтта Кызыл Маҗалык, Ак Довурак якларына ук узып киткәннәр: Енисейдагы кодрәтле ГЭСлардан Тува җирләренә электр энергиясе — яктылык, җегәр, куәт китерә алар! Шулай, бихисап курганнар, таш сыннар өстеннән бөтен илне буеннан-буена кисеп югары вольтлы электр линиясе уза. Чал тарихлы борынгы өлкәнең яңаруы, яшәрүе галәмәте иде бу.

...Без эзләп бара торган авыл Биҗикти хая, ягъни Язулы кыя дип атала. Ул зур юлдан читтәрәк кечкенә генә сөзәк тауның култыгында урнашкан икән. Безгә кирәкле кыяга җитәр өчен шул авыл урамы аркылы узарга кирәк. Комлы кашлакка урнашкан авылның читеннән үк яшел чирәмле болын башлана. Көн кичкә авышкан, вакыт санаулы. Володя туры юл белән

китте, һәм яшел чирәм өстеннән йөз метр да бармадык, чын сазга кереп баттык.

Кешеләр җыела башлады. Бер урында пырылдап торучы машина тирәли әйләнеп чыктылар, елмайдылар, көлделәр, авыл аша коры юл була торып, саз аркылы китүебезгә гаҗәпләнделәр. Ләкин ни файда? Бил тиңентен генә бер кара малай моны беренче булып аңлады:

— Уюн-оол өендә, аны дәшеп килергә кирәк!

— Кем соң ул?

— Әнә, теге бензовозның шоферы, аның тәгәрмәчләре бик зур, дүрт көпчәге дә тарта.

Киттем. Уюн-оол ялындырып тормады. Җилтерәтеп килеп, безнең УАЗны арт ягыннан эләктереп алды да, бер-ике йолкынып, коры җиргә тартып чыгарды. Дөресен әйткәндә, безнең бөтен сәяхәт дәвамында машинадан күргән җәфабыз шушы бер батып алу гына булды.

Кыя төбенә җиткәч, барыбыз да сибелеп, сурәтләр, язулар эзли башладык. Озак эзләдек. Безгә шушы кыяларда борынгы монголча, тибетчә, кытайча язулар, шулай ук буддизм руханилары ясап калдырган сурәтләр бар дип әйткәннәр иде. Әллә алары да харап булып өлгергән инде?

Нишләргә белмичә аптырап йөргәндә, кап-кара өчдүрт малай килеп чыкты.

— Эки, малайлар!

— Эки, эки!

— Монда сурәтләр бар дип әйткәннәр иде безгә...

— Бар алар... Әйдәгез!

Алар безне кечкенә генә мәгарәгә — тау куышына алып килделәр дә соп-соры кыяларга күрсәттеләр. Бик җентекләп карый башлагач кына кара буяу белән беленер-беленмәс итеп ташка ясалган рәсемнең аерым сызыкларын шәйләдек. Малайларның берсе кыя төбендәге саздан учлап су китереп сипкән иде, рәсемнәр ачыграк күренә башлады. Без дә фляглардагы суны сипкәч, күренеш бөтенләй үзгәрде: баганалап язылган төрле телдәге язулар, буддизм дине сюжетларына ясалган рәсемнәр иде болар. Менә түгәрәк йөзле, нәфис иреннәре гел елмаеп тора торган, зур кыек күзле Будда. Тезләрен бөгеп утырган, кулларын югары күтәреп, кемнәргәдер мөрәҗәгать итәргә, сүз башлап җибәрергә җыена.

Буддизм дине, дөресрәге бу диннең ламаизм дип атала торган бер тармагы тувалылар арасында унсигезенче гасырда, Тува җире Кытай-Манжур империясе составына кертелгәч тарала башлый. Ләкин ул илнең, халыкның рухи культурасына бернинди файдалы яңалык кертә алмый. Әйтик, христиан дине таралу славяннарга, исламны кабул итү борынгы болгарларга яңа язу, язма әдәбият, әзме-күпме гыйлем традицияләре һәм гомумән грамота нигезләрен китергән булса, ламаизм тувалыларга моның берсен дә бирми. Аның каруы һәрбер дингә хас иҗтимагый буйсынучанлыкка, социаль күндәмлеккә өнди торган реакцион эчтәлеген артыгы белән алып килә. Күп санлы буддизм руханилары, ягъни лама дип атала торган монахлар армиясе барлыкка килеп, алар шәфкатьсез рәвештә халык җилкәсен кимерә башлый. Ламаларның кансызлыгы бу якларга сәяхәт ясаган буржуаз авторларда да протест хисе уята. Мәсәлән, 1910—1911 елларда Тува җирләрен аркылыга-буйга гизгән инглиз географы Д. Каррутерс болай яза: «Монда ламалар чикләнмәгән көчкә ия, халык тормышына гаять нык тәэсир ясый, һәм алар, үзләренең шундый хәлләренә таянып, болай да авыр салымнар астында ыңгырашкан ярлы көтүчеләрне тагы да зур рәхимсезлек белән талый, бөлдерә». Хәерчелек, йогышлы чирләр бөтен бер халыкны үлеп, кырылып бетү куркынычы алдына китереп куя.

Хәзер яңа шартларда туган сәламәт буын үсә. Әнә, безгә кыя сурәтләрен табарга ярдәм итүче, күзләрендә нур балкыган чая малайлар шулар инде!

Берсе үреләүреләташтагы аңлаешсыз язуның аерым хәрефләрен капшап карый, таныш түгел язуның серенә төшенгәндәй янындагы иптәшенә нидер әйтә.

— Укып буламы соң? — дип сорыйм.

Ул башын чайкый, кап-кара кысык күзләрендә елмаю, нур. Боларга карап мин бер халык башыннан кичкән «язу фаҗигасе» хакында уйлап алдым. Борынгы тувалыларның бабалары да, һичшиксез, руник язудан файдаланган. Енисей буенда вак-төяк эпиграфик истәлекләрнең башка төбәкләргә караганда күбрәк очравы моны артыгы белән дәлилли. Ләкин соңрак халык язуны бөтенләй оныта. Болай килеп чыгуга һич тә гаҗәпләнерлек түгел, чөнки феодализм чорында язуны бары хаким сыйныфлар гына белгән, гади халык исә югары культура җимешеннән мәхрүм

яшәгән. Шуңа күрә дәвамлы сугышлар чорында феодаль даирәдәге аз санлы язу таныган кешеләр кырылып бетеп, иске язуның тормыштагы әһәмияте кимегән, аның онытылуына бик яхшы җирлек туган. Диннәр алмашу, үз әдәбияты белән килгән яңа дин җиңеп чыгу да язу онытылуга булышлык иткән. Шулай да төп сәбәп халыкның укый-яза белмәвендә. Культура казанышлары чын мәгънәсендә халыклашкан чакта гына гомерле була ала. Борынгы руник язу, озак кына гамәлдә булуына карамастан, тар даирәләрдә генә кулланылган. Ә кыядагы ламалар язуы исә халыктан тагы да ерак торган. Шуның өчен искесе дә онытылган, яңасы да үзләшмәгән.

— Ничәнче класста укыйсыз? — дип сорыйм.

— Өченчедә!

— Бишенчедә!

— Ә син ничәнчедә?

— Ул быел бара мәктәпкә. Абыйсы алтынчыда укый инде.

— Укып бетергәч, кем булырга телисез? Йә, йә, әйтегез!

— Летчик!

— Агроном!

— Белмим...

— Шофер...— диде мәктәпкә быел барасы малай.

Үзем малайлар белән сөйләшәм, үзем Кызыл шәһәрендә булган бер очрашуны искә төшерәм. Тува дәүләт нәшриятының баш редакторы Юрий Кюзенгеш:

— Егерменче елларда безнең әдәби тел юк иде әле,— дигән иде әңгәмә ахырында.— Хәзер Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасын ана телебездә укыйбыз. Үз телебездә яңа повестьлар, романнар язылды. Ел саен тувача 100 дән артык китап басыла.

Кыяда ламалардан калган аңлаешсыз язулар, ә минем каршымда летчик, агроном, шофер булырга хыялланган малайлар...

— Сау булыгыз, малайлар!

— Байырлык!

— Байырлык!

Олы юл алга чакыра

Яр өстендәге чатыр янында якты учак яна. Бер якта куе әрәмәлек, икенче тарафта таштан ташка сикереп аккан мөлдерәмә сулы

Хемчик елгасы. Бу төшләрдә ул артык зур түгел, ни әйтсәң дә, елга башына якынрак. Менә нәкъ шунда, елга башына җитәр өчен чак-чак кына калганда, безнең сәяхәтебез тәмамлана. Бүген без Тува җирендә соңгы кичне кунабыз.

— Шулай, бабайларның җирен калдырып китәбез диген, ә? — диде Хәлим, кайнар чәй янында.

— Бабайлар ук микән? Әллә бабайларның якын кардәшләре генә микән?

— Кем ул? Кемне әйтәсез? — диде, кайнар куз өстендәге чәйнек белән мәш килеп, Хәлимнең сүзләрен ишетми калган Рафаэль.

— Борынгы чорларда шушы якларда яшәп, таш сыннар ясаган, балбаллар тезгән төрки халыкларны әйтәбез,— дидем мин.— «Баба» дигән сүз хәзер күп очракта тар мәгънәдә, бер нәселнең генә төп атасы дигән мәгънәдә кулланыла. Үзәк Азия кабиләләренә хәзерге төрки халыкларның берсе дә турыдан-туры тоташмый.

— Ничек инде алай? — дип, Тавил кырын яткан җиреннән күтәрелеп утырды.— Нәрсә, алар әллә бөтенләй юкка чыккан, яисә күккә ашып киткәннәрме?.. Кызык халык сез, тарихчылар! «Юк» та димисез, «әйе» дип кистереп тә әйтмисез.

— Әйтеп булмый шул. «Юк» дип өзәр идең дә бит, хәзерге барлык төрки милләтләрнең телләре шул борынгы төрки истәлекләр теленә әзме-күпме дәрәҗәдә якын. Шул ук вакытта бернинди төрки телне дә турыдан-туры аның дәвамы дип карарга мөмкин түгел. Арада нindидер ачылып җитмәгән күчеш, буын бар. Күрәсең, әлеге истәлекләр телендә сөйләшкән диалект вәкилләре соңрак төрле якка таралып, башка халыклар белән аралаша-аралаша үзгәреп беткән.

Болай үзгәрүнең мисалын үзебезнең тарихта да күрергә мөмкин. Мәгълүм булганча, беренче төрки кабиләләр Идел буена гуннар чорында килгән дип фараз кылына. Төрки каганлыклар дәверендә дә Идел буена яңа кабиләләр килгән. Җиденче йөздә Болгар дәүләте оеша. Аңа элек Төрек каганлыгы составына кергән халыклар нигез сала. Болгарлар элегрәк көньяк күршеләреннән хазар һәм угызлар, аннары күп санлы кыпчак кабиләләре белән тыгыз экономик, политик һәм культура мөнәсәбәтендә булган. Монгол яулап алуларыннан соң башкалар белән аралашу тагы да көчәйгән. XIII—XIV йөзләрдә бөтен Идел-Уралда

җирле сөйләшкә нигезләнгән бер әдәби тел барлыкка килә. Бу тел борынгы руник истәлекләрдән бөтенләй башка тел инде. Татар әдәби теленең «елга башы» шуңа барып тоташа. Халкыбызның этник нигезен тәшкил итүче болгарларда да бу вакытта нык үзгәрү барлыкка килә: алар элекке үз теленнән кыпчак теленә күчә. Бу бәхәссез факт. Ләкин ничек күчкәннәр? Үз телләрен онытып, күршенең телен «әҗәткә алыпмы?» Юк, билгеле. Тыгыз аралашу, кардәшлек нәтиҗәсендә генә бу тел алыштыру барлыкка килгән. Угыз һәм кыпчак кабиләләре белән шулай аралашудан тыш борынгы болгарлар җирле фин-угор халыклары, ягъни хәзерге удмурт, мари, мордваларның бабалары белән дә күрше-күлән, дус-иш, кода-кардәш булып яшәгән. Менә шуның өчен хәзерге башка төрки халыклардан, әйтик, тувалылар, казакълар, кыргызлардан бүгенге татарлар бер теле белән генә түгел, йөз-кыяфәте белән дә аерыла.

— Күрәсез, шундый аралашу, үзгәрүләр дәвамында барлыкка килгән соңгы дәвернең бер халкы белән борынгы төркиләр арасына тигезлек билгесе куеп, «әйе» дип кырт кисәргә дә мөмкин түгел икән. Шулай булгач, мәсьәлә бер тарихчыларның икеләнүендә генә түгел, бәлки, тарих чынбарлыгы дигән нәрсәнең катлаулы табигатенә кайтып кала. Тарихчылар гына түгел, тел белгечләре дә борынгы төрки истәлекләрне бер халыкка гына кайтарып калдырмыйлар, бәлки аларны хаклы рәвештә барлык төрки халыклар өчен дә уртак чыганак, уртак байлык дип исәплиләр.

Чәйнек икенче мәртәбә кайнап чыкты. Бүген дежур Фәрит булса да, чәйне, гадәттәгечә, Рафаэль пешерә: каты итеп, тәмле итеп, белеп пешерә ул. Бер мәлгә һәркайсыбыз үз хыялы белән кала.

Моңарчы бер читтә тыңлап кына утырган Володя:

— Әлеге таш сынны да калдырдык. Берәр язулы плитәне дә алып китәргә уйламадыгыз...

— Нигә моннан ташырга? Үзебездә табылуын телә, Владимир, үзебездә!

— Һи, анда табылырмыни! Бездә бит мондагыдай ташлар, кыялар юк!

Әйе, Володя беркадәре хаклы, безнең якларда, чыннан да, табигый таш архивлар юк шул. Ләкин аның каруы «җир китабы» бар, аны тизрәк, күбрәк укырга гына кирәк. Моңарчы Урал якларында табылган руник истәлекләрне археологлар җирдән — борын-

гы кешеләрнең каберләреннән казып алган. Дөрес, көмеш савыт-сабадагы бу язуларны Уралда түгел, бәлки кайдадыр Урта Азия якларында язылган дип уйлаучылар да бар. Мондый шөбһәләрне шул якларның үзендә табылган таш язулар гына ачыклый алыр иде. Соңгы елларда андый истәлек тә табылды. Мәсәлән, Урта Идел буенда археолог Альфред Халиков тапкан бер ташта кыска гына руник текст бар. Аны махсус тикшереп, мәкалә язган Мәскәү галиме Әдһәм Тенишев мондый нәтиҗә ясый: «Соңгы вакытларда төркичә руник язуның бик киң таралган булуы ачыклана килә. Әйтик, Якутия, Монголия, Тува, Хакасия, Алтай, Кыргызстан, Казагстан, Үзбәкстан, Дон, Кавказ, Венгрияләрне күрсәтергә мөмкин. Хәзер шушы «чылбырга» Урта Идел буе өстәлә. Әгәр яңа табышлар булса, бу нәтиҗә тагы да ныграк дәлилләнер иде».

Булырмы тагы андый табышлар? Кайчан?..

Төнге елга аерата матур. Әйтерсең лә, таштан ташка сикереп аккан су чылтырамый, ә елга төбендә тәгәрәгән йолдызлар чыңлый. Йолдызлар исәпсез-сансыз булудан, күп «чың»нар бергә кушылудан әйтеп бетергесез бер аһәң, башы-ахыры юк гөрелтеле моң барлыкка килгән. Мин ни өчендер тарихны һаман елгага, аккан суга охшатам. Халыклар тарихы да шулай бит! Сәяхәтебез башында, Саян тауларын узган чакта, яңгыр сулары, кечкенә чишмәләрдән инешләр барлыкка килүен, инешләрдән зур елгалар тулуын күргән идек. Зур халыкларның тарихы да кечкенә ыруглар, кабиләләр язмышыннан башлана. Икенче киңлекләрдә ул, яңа елгаларны кочагына алып, зур дәрьяларга әверелә, зур дәрьялар диңгез-океаннарга коя. Океан — хәзерге кешелек. Ләкин һәр елганың, һәр инешнең чыганагы, үз язмышы, үз юлы бар. Океаннарга җиткәнче олы юл уза ул. Кайсы гына халыкның тарихын белергә теләсәң дә, шул олы юлны узарга кирәк.

* * *

Бәрән сыртыдай бөдрә, яшел тугайлары, фирүзәдәй зәңгәр елгасы белән Хемчик үзәне артта калды. Тагы ялангач сөзәк тауларны аралап югарыга, биеккә менеп барабыз. Ә юлы!.. Мондый киң, мондый тигез, мондый төзек

юлларны күптән күргәнебез юк иде. Дөрес, бу кадәр борылышлары күп юлны да биек таулар арасында гына күрергә мөмкин. Тува җире гел менә шундый биек-биек, тәбәнәк, яссы таулардан һәм башы-ахыры күренмәс, бер киңәеп җәелгән, бераздан тараеп кысылган, кечерәйгән, тора-бара бөтенләй юкка чыккан үзәннәрдән, тарлавык-ерымнардан гыйбарәт. Мәгәр таулар күбрәк: бөтен ил территориясенең сиксән ике процентын таулар тәшкил итә. Димәк, гомумән алганда Тува — таулар иле. Ә тормыш — авыллар, шәһәрләр сибелеп утырган үзәннәрендә. Анда колхозлар, совхозлар, заводлар, шахталар. Шул үзәннәрдә коры далаларны, бөтен тереклекне, үсемлекләрне сугарып, зәңгәр елгалар ага. Бәс, бу ил бәрәкәтле үзәннәр иле дә икән.

Менә без Ыдыгей дигән киң үзәнне аркылыга кисеп узабыз. Яшел җәймә өстендә ап-ак тирмәләр, төркем-төркем көтүләр... Эреле-ваклы курганнар, аларны күзәткән таш сыннар, чарасыз калган балбаллар... Гүяки, моннан дистәләгән гасырлар элек бу үзәннәр ничек яшәгән, хәзер дә шундый ук хәлдә тора сыман. Ләкин бу тыштан гына шулай. Моңа без бара торган олы юл шаһит: вакыт-вакыт безне зур тәгәрмәчле, тиз йөрешле йөк машиналары узып китә. Нәкъ җырдагы шикелле: «Әнә килә автомобиль, төягәне ташкүмер», асбест, кургашын, күкерт, тимер, агач, йон, кыйммәтле җәнлек тиреләре...

Каршыга килүче машиналар терлекчеләр, игенчеләр, эшчеләр өчен көнкүреш кирәкләре ташыйлар. Күмәк хезмәт нәтиҗәсендә төзелгән бу олы юл яшь республиканың киләчәгенә символ шикелле: һаман биеккә, һаман югарыга таба омтыла!

Котлы булсын, Тува җире, бу якты, өметле киләчәккә чакыручы олы юлың!

Рәхмәт сиңа, юмарт Тува җире!..

Соңгы мәртәбә борылып Тува иленә карыйбыз. Гел сыртлар, гел таулар, гел үзәннәр, тарлавыклар, урманнар...

Гел таулар... Гел үзәннәр...

ЭЧТӘЛЕК

Сәфәр ерактан башланды 3
Саян таулары аша 6
Алтын мөгезләр 10
Изге курган серләре 14
Авыр юлның ахыры 21
Азия үзәгендә очрашу 24
Ике Миша, яки итек тотып аюга каршы . 34
Дәүләт чиге аша 43
Балбаллар үзәне 47
Саглыда танышу 57
Кыядагы могҗиза 65
Ламалардан калган эз 73
Будда мәгарәсе янында 79
Олы юл алга чакыра 82

УРТА ҺӘМ ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП
БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Усманов Миркасым Абдулахатович

ПУТЕШЕСТВИЕ В СТРАНУ ГОР И ДОЛИН

Путевые заметки

(На татарском языке)

Рецензенты Н. Фәттах
Редакторы С. Сибгатуллина
Художество редакторы Г. Трифонов
Техник редакторы Л. Тилк
Корректоры Р. Хәмидуллина

ИБ-533
Наборга бирелде 5/VIII-1976 ел. Басарга кул куелды 21/X-1976 ел. ПФ 03083. Типография кәгазе № 3, 84×108¹/₃₂. Учетн.-изд. табагы 4,63. Басма табагы 4,62. Заказ Е-665. Тираж 8000. Бәясе 15 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман. ур., 19.

15 тиен